PRESSA.RU

1926–1991 елларда АЗАТ ХАТЫН



2016 ИЮНЬ № 6

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

БАЛА-ӘНИ
зурлар уенының азагы

МӨҺАҖИРЛӘР
Пекин сәхнәсендә – татар язмышы

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ СЫЙЛЫЙ:
дусларга – парлама



Хәния САФИУЛЛИНА:

— ЭШКӘ ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫН КУШЫП...

PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...





ВЕЛОСИПЕДТА ҖИЛДЕРӘБЕЗ

Ратниковлар гаиләсе

Казан

Безнең гаиләдә бар да тизлек, хәрәкәт, спорт ярата. Иделдә, диңгезләрдә колач салып йөзәргә, кыш көне тау чаңгыларында биектән аска коштай очарга Ратниковларга куш инде! Студент елларында ук тау чаңгылары белән мавыккан ирем Володя мине дә чаңгыларга гашыйк итте. Тешләремне кысып, учымны йомарлап, үҗәтләнеп, тәки өйрәндем! Соңрак, бездән күреп, улыбыз Лёша да чаңгыларга басты. Кайсы гына тау чаңгылары курортларында булмадык! Кавказда да, Альпта да... Үзебезнең Казанда да менә дигән тау чаңгылары комплексы бар! Андагы рәхәтлек, азарт, драйв!.. Бергә чакта (әмма ул бик сирәк эләгә!) бакчабызда да күңелле безгә! Һәркемнең үз биләмәсе – түтәле. (Чәчәкләр, җиләкләр – Риммаңыкы, яшелчәләр – Володяныкы, борчаклар – Лёшаныкы!) Ә иң шәп ял – велосипедта җилдерү! Үзәк ял паркында да, Черек күл бакчасында да, Гаилә үзәге янында да менә дигән велосипед юллары бар! Безгә Казансу яры буенда велосипедта узышу аеруча ошый! Тирә-якта җанга ятышлы музыка яңгырый. Яшьләр, балалар... Казан, Кремль нинди матур күренә! Янәшәдә – кадерле кешеләрем!















Ә сез БЕРГӘ ЧАКТА ниләр эшлисез, сезнең гаиләнә нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Хәния Сафиуллина
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 10.06.2016 ел.
Заказ М-1414.
Тираж 6400.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU





Фото: Газинур Хафизов

Факил ӘМӘК

Июнь башы. Элегия.

Карлыгачның түшкәйләре
түбәгә тияр-тимәс.
Көннәре нинди ягымлы, җилләре нинди иләс!

Һәр минуты – кабатланмас,
гүзәл чаклары җәйнең.
Күңелемдә – Сабан туе сөлгесе канат җәйде.

Басу яклап печән исе – җанга килеп сарылды.
Дөньялары шундый иркен,
якты чагы җанымның.

Карлыгачның түшкәйләре
түбәгә тияр-тимәс.
Көннәре нинди ягымлы, җилләре нинди иләс!

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



16

КӘРАМ КЫЗЫ

М. Кашапова



ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8

БАЛА БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?

М. Авзалова



20

ЧЕБЕШ БИЗНЕСЫ

Л. Гәрәева



12

ЗУРЛАР УЕНЫ

Г. Хәсәншина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



«МИН ТАУНЫҢ БАШЫНДА БУЛЫРГА ТИЕШ!»

Э. Закирова

24

ДҮРТ МИНУТ

Г. Сафиуллина

28



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



36

ТАРТУ КӨЧЕ
Г. Әдһәм

ЯШӘЕШ 

40



ЮЛЛАР ЧАКЫРА...
А. Маликова



48

КЫТАЙДАГЫ БИШ ЭШЕМ
С. Гаффарова

ШУЛАЙ УК: 

32

КҮЗЛӘРЕҢ НИНДИ?
А. Юнысова

44

БӘХТИЯР
Л. Лерон

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58

ҖӘЙГӘ НӘФИС МУЕНСА

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

БӘХТИЯР.
КҮРӘЗӘЧЕЛӘР НИ ДИЛӘР?

«ЯРАТЫП ТУЙМЫЙЧА КИТӘБЕЗ...»
АТНАБАИ МӘХӘББӘТЕ.

«БЕР КЕШЕЛЕК КАМЕРАДА – 18 ЕЛ...»
АВСТРАЛИЯ ЮЛЪЯЗМАСЫННАН

ЯШЬ ЖЫРЧЫ
ГӨЛСИРИН АБДУЛЛИНА СЫЙЛЫЙ.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Волгоград өлкәсенең Городище районы Дмитриевка хуторына туганнар каберлеген зиярәт кылдык.

Электән үк әбием Әсмабикәдә абыем Сәлимҗан Әхтәмҗан улы Зәйнуллинның Сталинград өлкәсендә Бишкурган районында күмелгәнлеге турында хәбәр саклануын белә идем. Әнием Гәүһәрия үзе үләр алдыннан аны миңа бирде:

– Абыеңның кабеpенә үзебезнең туган җир туфрагын салып кайтырга тырыш, – дип әманәт әйтте. – Әби-бабаң белән гомер буе аның кабеpен барып күрергә хыялландык, булдыра алмадык, – диде.

Мәскәүгә Оборона министрлыгына хат язып, абыемның төгәл күмелгән урыны турында белешмә сорадым. Аннан: «Волгоград өлкәсе хәрби комиссариатына мөрәҗәгать итегез», – дигән хат килде. Алар каберлекнең Бишкурганнан Дмитриевка хуторына күчерелүе турында хәбәр иттеләр. Улым Илнур, оныгым Камилә белән 6 май көнне үз машинабызда юлга кузгалдык. Карповка авыл җирлеге башлыгы Александр Балабон белән аның урынбасары Ольга Расщупкина безне бик җылы каршыладылар. Уңайлы фатирга урнаштырдылар, озатып йөрүче билгеләделәр.

Шул ук көнне туганнар каберлегендә булдык. Анда күмелгән 1149 кешенең исеме алфавит буенча язылган. Арада татар егетләре дә күп. Абыемның исемен күрү мине нык хисләндерде. Чәчәкләр куйдык, туган җир туфрагын салдык. Җилкәдән авыр йөк төшкәндәй булды – рухи бер рәхәтлек кичердем.

Каберлекне Җиңү бәйрәменә әзерлиләр иде. Улым Илнур да рәшәткәләр буяшты. 8 майда «Хәтер көне»ндә катнаштык. 9 Май көнне каберлеккә веноклар салдык.

Сәфәрдән кайткач, үзебезнең Балык Бистәсе районы Зәңгәр Күл һәм күрше Колос авылларыннан яуга киткәннәр истәлегенә һәйкәл кую теләге уянды. Бу хыялны чынга ашыру өчен иң элек район хакимияте башлыгы Илһам Госман улы Вәлиевкә, район комиссариатына, Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы Альберт Тәлгать улы Сафинга яздым. Алар бу ниятемне хуплап, ярдәм кулы суздылар. Авылдашлар, читтә яшәүче якташлар да шактый гына матди ярдәм күрсәтте. Һәйкәлне ясау һәм урнаштыруда фермер Вазыйх Хәмидуллин, авылдашлар Рәфкать Сәйфуллин, Шамил Һадиев, туганнарым Наил Зәйнуллин, Гөлсинә Хәйруллина, Шәйхелислам Сафин, улым Илнур белән тормыш иптәшем Мирзаҗан Шиһаповлар зур көч куйдылар.

94 кешенең исеме язылган һәйкәлне авыл уртасына урнаштырдык. 10 май көнне район башлыгы, хәрби комиссариат вәкилләре, авыл җирлеге җитәкчеләре, барлык авылдашлар катнашында аны ачу тантанасы булды. Тантананы оештыруда Күгәрчен Мәдәният йорты, Юлсубино һәм Күгәрчен урта мәктәпләре коллективлары булышты, Рәйханә Иминева җитәкчелегендәге район балалар иҗат үзәге хезмәткәрләре матур концерт программасы белән бәйрәмгә ямь өстәде. Соңыннан барлык катнашучылар да солдат боткасы белән сыйланды.

Карповка авыл җирлеге белән хәзер дә элемтәдә торабыз. Абыемның җәсәде күмелгән туганнар каберлегенә безнең исемнән быел да венок салдылар. Каберлекне төзекләндерү өчен дә матди ярдәм күрсәттек.

Чыннан да, беркем дә онытылмый, бернәрсә дә истән чыкмый. 70 елдан артык вакыт узып китсә дә, хатирәләр яңарып тора. Безнең азатлык өчен көрәшкән каһарманнар даны буыннан-буынга күчеп, хәтерләрдә мәңге сакланыр. 71 ел аяз күк астында яшәвебез белән без аларга бурычлы.

Наилә ШИҺАПОВА.
Балык Бистәсе районы.



Сугыш афәте, без яшәгән төбәктән ерак узса да, бер генә гаиләне дә читләтеп үтмәде. Кубәк авылында яшәүче Канделкарәм гаиләсенә дә кагыла сугыш җилләре...

Дүрт баласын – Зәйтүнә, Хәния, Фәния һәм төпчекләре Индусны калдырып, әтиләре сугышның беренче көннәреннән үк фронтка чыгып китә. Озак та үтми, вафат булды дигән хәбәре килә. Әниләре Хәят апа, иң авыр эшләрдә эшләп, салкын тидерә һәм 1943 елда балаларны ятим калдырып үлеп китә. Бу вакытта олы апаларына – 12,

төпчекләре Индуска 3 яшь тә тулмаган була. Олы кызлар хәер сорашып, ел ярымлап үзләре генә яши. Фәния апа: «Әле ярый энебезне Мирзамөхәммәт абый үзләренә алды, исән калмаган булыр иде», – дип искә ала. 1945 елның мартында кызларны Ольгино балалар йортына алып китәләр. Алар анда да бер-берсен ташламый, ял көннәрендә авылдагы энекәшләре янына кайтып йөриләр. Балалар йортында биргән тәм-томнарны, үзләре ашамыйча җыеп, энеләренә алып кайталар. Бөек Җиңү бәйрәмен алар яшьле күзләр белән каршылый, чөнки, бәлки исәндер, дип көткән этиләре кайтмый... «Башкалар сөенгәндә, без приют тәрәзәсеннән карап, безне дә килеп алучы булмасмы, дип, тилмереп көттек. Күпме генә көтсәк тә, килүче булмады...» – ди Фәния апа.

Өч бертуганны балалар йортыннан Казанга ФЗӨгә җибәрәләр. Шул китүдән алар Казанда төпләнә. Туган авылларында калган энеләре Индус белән дә араны өзмиләр. Ләкин тормыш югалтуларсыз гына булмый шул... Апалары Зәйтүнә, энеләре Индус араларында юк инде... Хәния апа озак еллар төзелештә эшләде. Энеләре Индус та авылның хөрмәтле кешеләренең берсе иде. Гомере буе шофер булды. Фәния апа исә Казанның моторлар төзү заводында хезмәт куйды. Авылдашы Хәким абый белән гаилә корып, менә инде 54 ел бергә яшиләр. Хәким абыйның да гомере шушы ук берләшмәдә узды. Хәзер инде уллары Айдар да шунда эшли.

...Алдымда саргаеп беткән газеталар. Анда Фәния апаның төрле елларда төшкән фотолары, язмалар. Аларны укыйм да, менә кемнәрдән үрнәк алып эшләргә, яшәргә кирәк дип нәтиҗә ясыйм.

Фәридә ГОССАМОВА.
Чаллы шәһәре.

Дәү әбиемнең ут күршесе Шакирова Зәйнәп Гыймазетдин кызының күргәннәре берничә кешенең язмышына җитәрлек.

1912 елны элеккеге Чаллы (хәзер Зәй) районы Югары Пәнәче авылында туган Зәйнәп апага ике революцияне, гражданнар сугышын, ачлыкны, күмәкләшү елларын, Бөек Ватан сугышы мәхшәрен, сугыштан соң илне күтәрү авырлыкларын күрергә туры килә.

Гәүдәгә зур булмаса да, бик тәвәккәл була ул. Тәгәрмәчле тракторлар чыга башлагач, район үзәгендәге тракторчылар әзерләү курсына языла. 1934 елның язында башына кызыл яулык бәйләп, авылга трактор белән кайтып төшә. Утызынчы еллар ахырында сөйгән егете Шәмсетдин белән Галиция өлкәсенә (хәзерге Львов өлкәсенә кергән җирләр) күченеп китеп, никах укыталар. Беренче кызлары шунда туа. 1941 елның 22 июнендә аларны туп тавышы уята. Офицер-кавалерист Шәмсетдин шунда ук аңлап ала: «Бу – сугыш!» Үзе тиз генә җыена да, штабка чыгып чаба. Ярты сәгатьтән саубуллашу өчен кире кайта. «Зәйнәп, нык бул! Бу сугыш озакка. Монда кала күрмәгез, туган якка кайтыгыз. Юлын тап! Кызыбызны сакла!» Галициядән туган ягына кадәр төгәл ике ай кайта Зәйнәп апа. Кешеләр белән шыплап тулган вагоннарда, күкрәк баласын сытмасыннар өчен баш очына күтәреп; бомбалар яуганда гәүдәсе белән каплап; урманнарда, болыннарда качып ята-ята кайта. Ачлыктан сөте беткәч, баласына яңгыр суы эчертеп, кемдер биргән манныйны җылы суга туглап ашатып – ничек итсә итә, 1941 елның август ахырында Чаллы пристанена кайтып егыла. Моңа хәтле туган якка кайтып җитү уе гына көч биргәндерме, әллә баланы саклау инстинкты йөрткәндерме – Чаллы җиренә аяк басуга, хәле китеп җиргә ава. Чулман ярына ятып, үкси-үкси елый Зәйнәп апа. Менә шулай, мең газап белән исән калган ул кызы бүген үзе шәфкать иясе – гомерен кешеләрне дәвалауга багышлаган шәфкать туташы, Чаллы шәһәренең 4 нче шифаханәсендә эшләп лаеклы ялга чыккан Вәзилә апа.

Шәмсетдин абый да сугышның бөтен афәтен татый, Украина фронтында әсирлеккә эләгә, фашист лагерена озатыла. Бервакыт лагерьның мәетләр чокырыннан аңа берәү татарча үз исеме белән эндәшә. Ике якташ әнә шулай алман җирендә табыша. Сугыштан исән-сау кайткан Шәмсетдин абыйлар йортына көннәрдән бер көнне бер ир-ат килеп керә. Сугыш кичкән ике ир бер-берсен кочаклап, тын гына елый. «Үз икмәгеңне минем белән бүлешмәсәң, туган туфрагымны күрәсе кеше түгел идем бит мин!» – дип, Шәмсетдин абыйны кочаклап елаган ул кеше – безнең якташ, Шикмай авылыннан әдибебез Рабит Батулланың этисе Мөхлисулла була.

Бакчадагы алмагачларга да салым салган, көчләп облигацияләр алдырган, колхозда эшләгән өчен акча урынына «таяк» белән түләгән – кеше үз гаиләсен дә туендыра алмаган чорда Зәйнәп апа дүрт баласы белән ирен генә түгел, үзләренә күрше булып яшәүче туганнары Мәрьям апа белән Таибә әбине дә тәрбияли – су китерә, мичкә яга, бакчаларын утырта, ашарларына пешерә, кирләрен уа... Үзенең туган авылында яшәүче үзе ятим, үзе сукыр Нурикамал әбине дә Бура-Киртәгә алып кайтып, 16 ел бага. Менә шушы Зәйнәп апа – ачлыгын да, хәсрәтен дә күргән, трактор белән җирен дә сөргән, сугыш елларында үзен аямыйча эшләгән дә, кар-яңгырына карамыйча, чана тартып Кәшердән чәчүлек орлык та ташыган, Пермь ягына пароход белән барып, йомырка да саткан, Ижауга, җәяүләп, май сатарга йөргән, бакчасында үскән бәрәңгесен Әстерханга кадәр илткән Зәйнәп апа Бура-Киртәнең иң хөрмәтле кешесе булып гомер кичерде. Кешелеклелегенә, сабырлыгына сокланырлык аның.

Фәридә ӘХМӘТҖАНОВА.
Зәй районы, Бура-Киртә авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

БАЛА БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?

ЧЫНБАРЛЫКНЫ АЧЫП БИРҮ, БАЛАНЫ ҖӘБЕРЛӘҮ ОЧРАКЛАРЫ ХАКЫНДА ДӨНЬЯГА ИШЕТТЕРҮ, ЧАҢ КАГУ – ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ АППАРАТЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАСЫ. Ә БУ ПРОБЛЕМА БЕЛӘН КӨРӘШ – УРТАК ЭШ.

Мәдинә АВЗАЛОВА

Балаларга карата җәбер-золымны туктату өчен төрле илләр төрле чаралар кулланып карыйлар. Бөтен җәмгатьчелекне бу явыз күренешкә каршы көрәшкә чакырырга өндиләр. Тель-Авив шәһәренең Рабин мәйданында, ЭЛИ җәмгыяте, психологлар, социаль хезмәткәрләр һәм волонтерлар катнашында уздырылган золым күргән балаларның хәленә ишарә ясаучы курчаклар күргәзмәсе шуның бер мисалы.

«Иң яхшысы – балаларга!» дип яшәгән «коммунизм» чоры инде күптән артта калды. Балаларны кимсетү-җәберләү дигән нәрсә ул заманда да булгандыр. Бу хакта без генә белмәгәнбездер. Ачы хакыйкатьне таныйрга теләмәгәнбездер. Әйтергә ярамый иде бит. Без бит «коммунизм таңы күренә» дип яшәүчеләр идек. Ә коммунизмда, үзегез беләсез инде, җинаять тә, бигрәк тә «тормыш чәчәге» булган балаларны җәберләү гомумән була алмый. Шулай уйлый торган идек. Шулай уйлавы безгә уңай-рәхәт иде. Көннәрдән бер көнне күңелләребезгә сеңдерелгән шушы фикернең безне саташтырганын аңладык. Баксаң, бездә балага, яшүсмергә карата мөнәсәбәт Татарстан Дәүләт Советының югары мөнбәреннән торып чаң кагарлык дәрәҗәдә кискен хәлдә икән. Әгәр дә вәкаләтле вәкил: «Сабыйларыбызны җәберлиләр, балаларыбызны көчлиләр, ятимнәребезнең хокукларын кысалар...» – дип өзгәләнә икән, димәк, залда утыручы депутатлар, бала язмышына карата аз гына булса да кагылышы булган министрлар, төрле ведомство һәм иҗтимагый оешма вәкилләре ишетсен өчен әйтә. Ишетсен һәм кичекмәстән чара күрсен дип инәлә. Чыгыштан алынган җан өшеткеч кайбер саннарга гына күз салыйк әле. Хәлне аңлау өчен шулары да бик җитә.

Узган ел Татарстанда балаларга карата 1968 җәберзолым кылынган. Шуның 1100 е – кыйнау, ирексезләүләр белән бәйле. 2014 ел белән чагыштырганда, быелтыр бу күрсәткеч, хәтта 70 процент чикләрен үткән?! (2013 елны мондый җинаятьләрнең саны 709 булса, 2014 елны 650 тәшкил иткән.) Ә иң куркынычы, тетрәндергәне – 723 бала җенси һөҗүмгә дучар ителгән, ягъни балигъ булмаган балаларга карата сексуаль характердагы җинаятьләр ике мәртәбә арткан. Моны ишеткәч, чәчләр үрә тора. Башыбызга килгән беренче сорау: опека һәм иганәчелек органнары, урыннардагы балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссияләре хезмәткәрләре, инде дә килеп, хатын-кызлар оешмалары, гаилә, мәктәп ни караган? Иң мөһиме: бу хакта тиешле органнарга җиткерергә... Калганы тикшерү органнары, прокуратура, суд эше. Шулай дип кыза башлыйм да, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина сүземне бүлеп, ачыклык кертәсе итә: «Сексуаль характердагы җинаятьләр күбесе гаиләләрдә генә очрый, дип ялгышмагыз, – ди омбудсман, – ул бар яктан җитеш, читтән караганда бик әйбәт сыман күренгән гаиләләрдә дә еш очрый. Шуңа да опека хезмәткәрләре аларның өйләренә баруны башларына да китереп карамый. Хәлне белмәгәнгә күрә, бала еллар дәвамында җинаять корбаны булып яшәргә мәҗбүр».

Адәм актыклары

Баласын шуның ише җәзага тарткан адәм актыкларына карата шәхсән мин үзем иң каты җәзаны кулланыр идем. Кызганыч, бездә «высшая мера» юк. Алар төрмәдә утырыр да чыгар: ун елмы ул, унбиш елмы... Ә баланың психикасы гомергә шушы коточкыч күренешләр белән бәйләнеп калыр. Әйткәнебезчә, сексуаль характердагы 723 җинаятьнең 8 е – әти-әниләре; 96 сы – үги әтисе; 120 се гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан кылынган?!

– Мамадышта булган фаҗигане генә карагыз инде, – дип әрнеп сөйли вәкаләтле вәкил. – Әтисе белән әнисе икәүләшеп 14 яшьлек кызларын көчлиләр: башта берсе, аннары икенчесе... Бу эш судка җибәрелгәннән бирле безнең игътибар үзәгендә булды. Нәтиҗәдә, ирен – 14 ел да 11 айга, хатынын 10 елга хөкем иттеләр.

> *Бала хокуклары өчен көрәш дәүләт һәм җирле үзидарә хезмәткәрләре, эчке эшләр органнары, прокуратура һәм иҗтимагый оешмалар бергәләп эшләгәндә генә уңай нәтиҗә бирәчәк.*

Саный китсәң, моның ише чиркандыргыч мисаллар җитәрлек: Яшел Үзән районында яшәүче берәү (дәү әтиләре дип әйтәсе дә килми) алты һәм җиде яшьлек кызларга карата сексуаль җинаять кыла. Кыланмышларын видеокамерага да төшереп ала әле. Хәзер бозык картның эше судта. Ул да тиешле җәзасын алачак. Һичшиксез алачак. Бер генә җинаятьнең дә җәзасыз калмаячагын истән чыгармаска кирәк. Ул мөртәтләрнең кайчан да бер иң Югары Суд каршына – Аллаһы Тәгалә хөкеменә куеласы көннәре дә бар бит әле.

Тагын бер коточкыч вакыйга турында әйтмичә кала алмыйм: Зәй районында яшәүче хатынның 5 яшьлек малае озак вакытлар йортка кергән ирдән мыскылланып яши. Әнисе баланы аягыннан тотып тора, ә теге ерткычы баланы көчли. Бу хәлләр бала хастаханәгә килеп эләккәч кенә мәгълүм була. «Бик катлаулы эш булды ул, – ди Гүзәл Удачина. – Бала кечкенә, үзе белән ни булганын аңламый. Тыңламаган өчен аны шулай итеп җәзага тарталар дип уйлый. Ирне – 18 елга, хатынны 16 елга хөкем иткәннәр иде. Эшне Россия Федерациясенең Югары Судына җибәрделәр дә, ул аннан кире әйләнеп кайтты. 5 яшьлек баладан тагын сораштыра башладылар. Ул вакыйгаларны тагын бер кат күңел аша үткәрү, искә алу җиңел эшмени?! Бигрәк тә бала өчен. Янә бала белән психологлар эшли башлады. Мин нәкъ шул вакытларда Россия Федерациясендә Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Павел Астахов белән очраштым. Җае да чыгып кына тора иде. Барын да сөйләп бирдем. Шуннан соң

PRESSA.RU

гына бу адәм актыкларына карата тиешле җәза бирелде.

Гадәттә, без җәмәгатьчелекне, хокук саклау органнарын гаилә эшләренә тыкшынмаска чакырабыз. Инде карагыз: тыкшынмый йөрүебез дә юньлегә китерми икән. Шулай да каян билгеле була бу фактлар? Бер уйлаганда, өйдә кылынган җинаятьне ачыклау гаҗәеп катлаулы, авыр эш бит.

Син дә, мин дә... һәркайсыбыз

Әйе, баланы кансыз ата-аналардан саклап калу – һәркайсыбызның изге бурычы. Әйтер идем, намусы. Биредә иң беренче чиратта мәктәп, дәвалау учреждениеләре сагаерга тиеш. Һәрдаим мәсхәрә күргән, җәберләнеп яшәгән бала бөтенләй икенче була. Игътибарлы укытучы баладагы үзгәрешләрне шундук күреп алыр, сораштырыр, сөйләштерер, психологка алып барыр. Менә шул чагында ачыла инде сабыйның, йә булмаса, яшүсмернең теле. Укытучысы белән серләшмичә, тагын кем белән серләшсен ул? Чит кешегә сөйләп йөри торган сүз дә түгел бит әле ул. Бала өчен бу – хурлык, гарьлек.

Былтыр балаларга карата кылынган җинаятьләрнең 56 проценты – көчләү, җәберләүләрдән гыйбарәт.

– Бездә балага мөнәсәбәт башкачарак корылган, – дип дәвам итә сүзен әңгәмәдәшем. – Бервакыт без Чикагога форумга бардык. Психологларның бала белән ата-ана арасындагы проблеманы йөрәкләренә шул дәрәҗәдә тирән кабул итүләренә нык гаҗәпләнгән идек шул чагында. Гаиләдә әти кеше әнигә тузына, әшәке сүзләр белән кычкыра башлый икән, бу алар өчен инде бик зур проблема... Шундук баланы «куркыныч яный» торган төркемгә кертәләр һәм аның белән эшли башлыйлар. Психологлар әлеге төркемгә кертелгән дүрт баланы мисал итеп китерделәр. Алар әйтүенчә, аның берсе, үсә төшкәч, фахишә була. Икенчесе төрмәгә эләгә. Өченчесе үз-үзенә кул сала. Дүртенчесе беркайчан да гаилә кормый. Без исә ата-ананың ызгышларын санга да сукмыйбыз, ә нәтиҗәсе, күрәсезме, нинди?

Күңеле җәрәхәтле бала үзе белән булган куркыныч хәлләр турында беркайчан да онытмый. Онытмый гына түгел, ул гел аның уенда... Күңеле түренә кереп урнашкан да, тиешле мизгелне көтә. Үч алу сәгате сукканны көтә. Йә ул әти-әнисенә, йә әйләнә-тирәдәгеләргә юнәлтелгән булыр. Монысы инде мөһим түгел. Ул читтән караганда гына тынычланган, барын да оныткан шикелле. Ә чынында, алай түгел. Безгә каршы эшли торган тагын бер яман гадәтебез: балаларыбызны психологларга алып барырга куркабыз. Кеше ни дип әйтер, янәсе. Наданлык инде монысы. Ә бит белгеч бик күп нәрсәгә күзләребезне ачар иде. Ә бәлкем, буласы җинаять тә кылынмый калыр иде. Әле дә хәтердә, узган ел балалар суициды темасына материал әзерләп йөрим. Психолог янына аңлатма алырга баргач, аның: «Әйттем мин әнисенә, алып кил баланы, сөйләшик...» – дидем – алып килмәде. Бүген шалтырата. Малае тәрәзәдән ташланган. 14 кенә яшь иде әле аңа», – дип сызланып-әрнеп сөйләве хәтердә. Суицидларны кимеде, дисәк тә, бер дә тынычлана алмыйбыз. Аның шул 84 очрагы да (2013 елны 137 булган) бик җиткән безгә. Күпме яшәп бетерелмәгән гомер! Һәркайсы – аерым бер бала язмышы!

Кисәтү эшләре тиешенчә алып барылганда, дәүләт һәм муниципаль органнар, балалар белән эшләүче төрле оешмалар, Татарстанда уңышлы гына эшен башлап җибәргән балалар оешмалары Советы бу җитди проблема белән якыннан шөгыльләнгәндә, фаҗигане булдырмый калырга да була бит. Дөресен әйткәндә, күп кенә министрлыклар, гәрчә бу эшләр алар ведомствосына турыдан-туры кагылса да, балалар арасында мондый үлем-китемнәрнең санын белмиләр дә. Чөнки рәсми статистика мәгълүматлары вакытында алып барылмый. Татарстан Сәламәтлек саклау, Мәгариф һәм фән, Эчке эшләр, Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыклары әлеге мәсьәләдә аеруча сизгер һәм җаваплы булырга тиешлеген әйтеп тору кирәкме икән?!

Җәмәгатьчелек ярдәмчеләре

Башка бер генә регионда да юк алар. Бары бездә – Татарстанда гына! Җәмәгать ярдәмчеләрен һәр районнан, яшүсмерләр арасыннан конкурс нигезендә сайлап алалар. «Балалар җәмәгатьчелек кабул итү бүлмәсе»нә барлыгы 53 әгъза кергән. Аларга «җәмәгатьчелек ярдәмчеләре» дигән таныкнамә бирелгән. Әледән-әле алар белән бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау темасына укуларның үткәрелеп торуы, Юстиция министрлыгы идарәсе, Тикшерү комитеты һәм башка җитәкчеләр белән очрашулар оештырылуы үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Җәмәгатьчелек ярдәмчеләре – Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең ярдәмчеләре. Омбудсман алар аша җирлекләрдә барган яңалыклар, балалар хәле белән танышып тора. Бу – аның шәхси инициативасы. «Балалар турында балаларның үзләреннән дә яхшырак белүче булмас, – дип аңлата ул. – Минем ярдәмчеләр проблемаларны бик тиз күреп алалар, шундук миңа хәбәр итәләр. Наркотикларның кайда сатылуын да миңа алар хәбәр итте. «Башка беркемгә дә әйтмәгез, – дидем. – Хәбәрегезне тиешле кешесенә үзем җиткерермен». Алардагы идеяләрне сөйли башласаңмы?! Куркынычсыз селфи, «тату» турында да беренче мәртәбә алардан ишеттем. Түбән Камадан бер яшүс-

мер кыз үзенә кул салгач: «Интернеттан карагыз, суицидка каршы нишләп була?» – дим. Берсе шул арада миңа хат яза: «Үләр алдыннан ул «Үз-үземә кул салырга 50 көн кала» дип исемләнгән китап укыган, – ди. Димәк, бала үлеменә әзерләнгән булып чыга. Ә якыннары, туганнары, дус-ишләре берни күрмәгән дә, белмәгән дә. Менә бит ничек?

«Баланың видеопаспорты»

Сүз ятимнәр һәм караучысыз калган балалар хакында бара. 2011 елдан бирле эшләп килгән бу проект нәтиҗәсендә күп кенә ятимнәр гаиләгә алынды, әти-әниле булды. Гаиләгә, яңа ата-анага күнегә алмаган, дөресрәге, ата-ана күңеленә хуш килмәгән балаларны кире кайтару очраклары кабатланмасын өчен уйлап табылган яңалык бу. Һәм ул үзен аклый. Һәр бала турында 40 минутлык фильм эшләнә. Балалар йортларыннан бала алырга теләгән әти белән әни башта шул фильмны карый. Аннан соң гына балага якын килергәме-юкмы икәнлеген хәл итә. Боларның барысы да ятимне тагын бер кат ятим итмәс өчен, баланың күңелен җәрәхәтләмәс өчен эшләнә.

Проект гамәлгә кергән биш ел эчендә барлыгы 256 видеопаспорт эшләнде. Бүгенге көндә шуның нәтиҗәсендә 186 ятим әти-әниле булды.

Җавапсыз карыйлар

– Бервакыт Биектау районында гражданнарны кабул итү бара, – дип искә ала Гүзәл Удачина. – Ата-аналар комитеты исеменнән бер төркем хатын-кыз килеп керде. Бер баладан зарланалар. «Әтисез бала, чыбыркылап торыр кешесе юк, мәктәптән китсен, балаларга укырга комачаулый», – диләр. Тыңлап-тыңлап тордым да, сорыйм әнинең берсеннән: «Сезнең балагызның әтисе бармы?» «Бар», – ди. «Улыгыз белән балыкка йөриме?» Ханым бик гаҗәпсенде. «Йөри», – ди. Алайса шул малайны да ияртеп балыкка барсыннар. Сөйләшерләр, аралашырлар. Әтисез балага күрсәткән игелегегез әрәмгә китмәс. Баланы тәртипсез булганы өчен генә мәктәптән алырга ярамый бит, дим. Килештеләр тагын үзләре.

Гомумән, арынасы килгән бала мәсьәләсен, теләмәгән эшне ата-аналар комитеты исеменнән хәл итәргә остарган мәктәпләр күбәеп китте. Мондый күренешләрдән сакланырга, кайда һәм кем булып эшләгәнеңне азга гына да исеңнән чыгармаска кирәк. Бу хәлдән соң хакимият башлыгы белән дә сөйләшеп алдым. Шундый вак мәсьәләне үзара да хәл итә алалар бит. Зурга җибәрмичә генә дип әйтүем.

Казанда озак еллар эшләп килгән яшүсмерләр тәрбия колониясе турында ишеткәнегез бардыр инде. Шул колонияне яптылар да, безнең яшүсмерләрнең барысын да Пермь шәһәрендәге колониягә күчерделәр, – дип дәвам итә сүзен вәкаләтле вәкил. – Аларны озатыр алдыннан яннарында булдым. Һәркайсына Пермь шәһәре вәкаләтле вәкиленең телефон номерын бирдем. «Аңа миңа ышангандай ышаныгыз, ул әйбәт кеше», – дидем. Урынга барып җитүгә үк мин биргән номерны шундук алганнар алардан.

...Май башларында гадәттән тыш хәл булып ала. Колониядән азат ителгән яшүсмер Казанга кайтып китә. Һәм кайтып җитә алмый. Югала. Закон буенча яшүсмерне озата кайтучы булырга тиеш. Ә аны ялгызын җибәрәләр. Соңыннан ул табыла табылуын. Җавапсызлык аркасында күпме тавыш чыга, күпме эзләү төркеме эшкә җигелә. Ул арада шул ук колониядә утырган тагын бер ятим – безнең ятим кинәттән вафат була. «Йөрәк өянәге», диләр. 18 яшьлек егеттә нинди йөрәк өянәге инде? Аңарчы ул медицина күзәтүе дә үткән була.

Балага карата кылынган җинаять беркайчан да җәзасыз калмый.

– 15-16 мартта шул колониядә булдым. Анда тәрбияләнүчеләрнең яшәү шартлары белән кызыксындым, үзебезнең егетләр белән сөйләштем. Барын әйтергә дә куркалар. Әмма вафат булган малай турында: «Кыйнаганнар», – диделәр. «Монда безне кыйныйлар», – дип тә ычкындырдылар. Казанга кайткач, бу фактлар буенча Россия Федерациясенең Генераль Прокуратурасына мөрәҗәгать иттем. Тикшереп, чара күрергә сүз бирделәр.

Гүзәл Удачина бу эшнең дә тәмам ачыкланачагына икеләнми. Чөнки холкы шундый аның: бер эшкә алындымы, төбенә төшмичә, йомгакның очына чыкмыйча туктамый. Эш бүлмәсендәге төрле дәрәҗәдәге Мактау кәгазьләре, Россия Президенты Владимир Путинның кулыннан алган Дипломнар, Россия Федерациясе Тикшерү комитеты биргән медаль дә шул хакта сөйли. Узган ел гына да ул 1664 мөрәҗәгать кабул иткән. Соңгы еллар белән чагыштырганда, үсеш 35,2 процент тәшкил итә. Уйласаң, ис китәрлек саннар бит бу. «Аның һәркайсында – кеше язмышлары. Бер генә мөрәҗәгатьне дә игътибарсыз калдырмыйм», – дип сөйләгән вәка-ләтле вәкилнең эше аннан башка да җитәрлек. Мөрәҗәгатьләр белән эшләү – ул йөзләгән төр эшенең бер өлеше генә. Ә шулай да иң мөһиме – БМОның «Бала хокуклары турында»гы конвенциясендә күрсәтелгәннәрне үтәү: бу, әйткәнебезчә, баланы җәбер-золымнан саклау да, аның сәламәт яшәү рәвешен тәэмин итү дә, балага гаиләдә тәрбияләнү мөмкинлекләре тудыру да, белем алу хокукларын яклау да, ятимнәрне торак белән тәэмин итү дә... бетмәс-төкәнмәс проблемалар, катлаулы, әмма бик теләгәндә һәркайсын хәл итеп була.каләтле вәкил шулай ди.

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

ЗУРЛАР УЕНЫ



Гөлнур ХӘСӘНШИНА

– Әни, мин бала көтәм...

Соңгы вакытта нигәдер гел боегып йөргән, сулып-сулыгып калган яшүсмер кызыгыз өстәл янына ашарга килеп утырган җирдән кинәт шундый хәбәр җиткерсә? Бик азга гына шушы хәлне һәм бу яңалыкны ишеткән мизгелдә үзегезнең ниләр кичерүегезне күз алдына китереп карагыз әле. (Ә сез, малай үстерүче әниләр: «Ярый әле, кызым юк!» – дип уйларга ашыкмагыз. Туачак бала сезгә дә онык лабаса!) Аптырау, югалып калу, аңламау, аңларга теләмәү, ышанмау, ачу, ярсу, нәфрәт, күралмау, үпкә, рәнҗү, чарасызлык... Исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкиндер. Күз яшьләре, тал чыбыгы, каеш... Туктагыз, туктагыз, ә хәзер боларның барысын онытып, үзегезне каршыгызда утырган кызыгыз урынына куегыз. Ул нинди утларда яна икән? «Бала көтәм» дип сезне өнсез калдырса да, ул бит әле үзе дә бала гына! Ялгышы язмышка әйләнгән яшь әни кем ул? Аны тормышта нинди сынаулар көтә? Кайдан ярдәм өмет итәргә, кемнәргә таянырга аңа? Без бүген бу хакта Кайбыч районының социаль яклау бүлеге башлыгы Чулпан КАМАЛИЕВА белән сөйләшәбез. Балигълык яшенә җитмәгән яшь әниләр аларда күп булганга түгел, Кайбыч – кечкенә район, монда һәр гаилә күз уңында.

Кадерсез балалар... Нигә алар бар, нигә ул исемлек гел өстәлеп тора? Безгә, шушы өлкәдә эшләүчеләргә, бу сорауның тынгылык бирмәве табигый. Кызларның 16-17 яшьтә үк әни булуы – әлеге күренешнең бер сәбәбе. Бер елны без аларны түгәрәк өстәлгә җыйдык. Иртә әни булган кызлар, гадәттә, балаларын тәрбияләүне әти-әниләренә тапшыра: очрашуга шундый оныкларын үстерүче дәү әни-дәү әтиләрне дә чакырдык. Һәммәсе дә бик теләп килде дия алмыйм. Мондый хәлне гаиләләрнең күбесе, бигрәк тә авыл җирендә, оят, хурлык дип кабул итә һәм, баланы кулга алгач, капканы ачып урам якка мөмкин булган кадәр сирәгрәк чыгарга тырыша, үз эченә бикләнә. «Дөнья моның белән бетми, яшәргә кирәк» – безнең иң беренче киңәшебез шул аларга. (Үземнең танышым гаиләсендә нәкъ шундый хәл булган иде. Беренче курста укыган кызлары, кышкы каникулдан китүгә бала тапты. Өйдә киң халаттан йөргән кызында әнисе бернинди үзгәреш сизмәде ул чакта. Классташлары җыелып тудыру йортыннан барып алган, бәбигә беренче бирнәне юнәткән, яшь әтине чакырткан... Моңарчы яшәгән фатирны бушатырга кирәк булгач кына сер чишелде. «Яңа кеше туу – хәсрәт була алмый. Кабул итмәсәң, икесен дә югалтасың. Кызың турында уйла, ул да бит әле бала гына», – дип тынычландырдык без ябь-яшь дәү әнине. Шул оныгын яратып туймый ул бүген!)

Кызлар бу хәбәрне әниләренә ничек җиткергән? Кемдер үзе әйткән, кемдер берәр туганы аша ирештергән. Яшереп йөрдем, төшертергә җыендым, үҗәтлегем белән генә саклап калдым, баланы үзем генә үстерәчәгемне белдем диючеләр булды. (Әмма берсе дә тапканына үкенү белгертмәде!) Кичә генә курчагына күлмәк тегеп уйнаган кызыңнан шундый хәбәр ишетү... Аңлашу булган гаиләләрдә, әни белән кызның сере килешкән очракларда сынауны җиңелрәк кабул иткәннәр. Әмма әниләрнең берсе дә туачак оныкларына әти эзләп кемнеңдер өенә барып йөрмәгән. Беренчедән, ул «әти»ләр күп очракта тормышка әзер булмаган шундый ук балалар. Икенчедән, кызлары белән булган бу хәлне әниләрнең күбесе үз гаепләре дип тә кабул итә.

Балаларын карында килеш юк итмичә, дөньяга китерүләре өчен рәхмәт әйттек башта кызларга. Шундый зур сынау алдында япа-ялгыз калган кыз баланың хәлен аңлау авыр түгел. Әйе, ул ялгышты... Әмма ул бит болай булыр дип күз алдына китермәгән иде! Янындагы егете шунда ук юкка чыга. Димәк, ярату, мәхәббәт дигәннәре дә чын түгел?! Боларга тиздән, көмәне беленә башлауга, классташлары, укытучыларының кырын каравы өстәләчәк. Инде



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы.

Үзбәкстан, Таҗикстан якларында кызларның 14-16 яшьтә әни булуы гадәти күренеш санала. Әгәр ул сабыен никах укытып, кияүгә чыгып дөньяга китерә икән, моны дөрес түгел дип әйтә алмыйбыз. Әмма бездә бу балалар, гадәттә, зинадан, уйнаштан туа. Ә бу – бик зур гөнаһ. Һәм бу гөнаһ иртә әни булган кызларның үзләренә генә түгел, балаларына да төшәчәк, аларның тәрбиясенә, сәламәтлегенә тәэсир итәчәк. Әти-әни өстендә дә җаваплылык зур: кызлары зина кыла, димәк, алар дөрес тәрбия бирмәгән. Балалары кылган бу гөнаһ әти-әнигә дә төшәчәк.

Чынлыкта, проблема монда тагын да тирәнрәк. Без хәзер күбрәк бу яшьтә бала табарга иртә, дип кенә сөйлибез, ә дөреслектә, яшүсмерләргә никахсыз җенси мөнәсәбәтләргә керергә ярамаганы турында аңлатырга тиешбез.

Дәү әни-дәү әтиләр онmarkларын башта – сынау, аннары гаиләгә бүләк дип кабул итә.

ДӨНЬЯ ХӘЛЕ

■ 1939 елны Перуда Лина Медина исемле алты яшь ярымлык кыз 2,7 килограммлы сау-сәламәт бала таба. Әниләре аны табибка: «Эчендә нидер үсә», – дип алып килә. Тикшерә башлагач, кызның җиде айлык корсаклы икәне ачыклана... Гиннесс рекордлар китабына ул «дөньядагы иң яшь әни» дип теркәлгән. Баласын ярып алалар. Ничек, кемнән балага узган – Лина бу хакта беркайчан да әйтми. Улы белән алар апалы-энеле кебек үсәләр. Үзенең чын әнисе кем икәнен малай 10 яшькә җиткәч кенә белә.

■ «Ромео һәм Джульетта»ларга беркайчан да җиңел түгел. «Пусть говорят» тапшыруында сөйләнгән очрак: Добрянка шәһәрендә яшәүче Даша Юневич 14 яшендә балага уза. Булачак әти – 18 яшьлек Анатолий Шолгин – шунда ук: «Өйләнешәбез!» – ди. Әмма «язылышу турындагы таныклык» урынына егетне «балигъ булмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә кергәне өчен» хөкем итәләр. Артык борчылганнан, суд вакытында Дашаның баласы төшә.

■ Иртә балага узуларның 70 проценты аборт белән тәгәлләнә. 15 процент очракта – төрле сәбәпләр аркасында бала төшә. Яшүсмер кызларның 15 проценты гына «баланы табам» дигән карар кабул итә.

■ Яшь әнинең көмәненнән котылырга теләве, аборт турында уйлавы, моны эшләмәсә дә, эзсез узмый, диләр. Андый әнидән туган балалар, үскәч, күңел төшенкелеге, депрессиягә ныграк бирешә, үзүзләренә кул салу очраклары алар арасында ешрак була.

■ Сораштырулар күрсәткәнчә, Россия халкының 60 проценты әле 20 яшьтә дә бала табарга иртә дип саный.

■ 13 яшьләр тирәсендә үк җенси тормыш белән яши башлаган кызларның 53 проценты соңыннан бу адымы өчен үкенә.

PRESSA.RU



Наилә ГАЙНАНОВА, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш белгече, акушер-гинеколог.

Тугыз ай буе бала күтәрү, бала табу хатын-кыз өчен зур сынау. Ә яшүсмер организмы өчен – бигрәк тә. 14-16 яшьлек кызларының бала көткәнен, гадәттә, әти-әни шактый соң белә. Бу вакытта баланы төшерү, аборт ясату кыз бала организмы өчен шактый катлаулы операция санала. Без, табиблар, баланы тудырырга киңәш итәбез. Әмма яшүсмернең гәүдәсе, тәне бала тудырырга әле әзер түгел, шуңа күрә аның үзе өчен дә, баласы өчен дә ахыры бик күңелсез тәмамланырга мөмкин булган авыр процесс ул. Әни яшьрәк булган саен, баласының үле туу ихтималы да арта. 16 яшьтән дә яшьрәк әниләрдә бала тапканнан соң кан китүләр, депрессияләр, психик тайпылышлар ешрак күзәтелә. Аларның балалары вакытыннан алда, кечкенә булып туа, сулыш алу органнары белән бәйле проблемалар күбрәк очрый.

нишләргә? Баланы табаргамы, юкмы – ул моны бары тик берүзе һәм бик тиз хәл итәргә тиеш. Аннан аборт ясатудан ул әле бала табудан да күбрәк курка. Яшерен серен әнисе белгән очракта да җиңел түгел бит кызга. «Табасың, бергә үстерербез», – дип шунда ук кайсы әйтә? Беренчесен төшерсә, кабат балага уза алмас дигән курку-шикләнү генә туктата кайбер әниләрне.

Баланы – бала түгел, ана тәрбияләргә тиеш, ә алар әле ана булып җитешмәгән.

Газизләрдән-газиз кешеләре – үз әниләре дә кабул итеп бетермәгән «бала-әни»ләргә җәмгыятьнең кырын каравы аңлашыла: алар бит бөтен кешегә комачаулык кына тудыра...

– Кызларның күбесе социаль яктан тотрыксыз гаиләләрдә үскән балалар. Шуңа күрә азгынлык димәс идем бу адымнарын. Эчкече әти-әни янында җылылык җитми аларга. Читтән кемнәндер якын итү, игътибар күрүгә, алар шуңа сыена һәм... алдана.

Әйе, мәктәпләр ак алъяпкыч астында инде җан кергән баласы булган укучыдан тизрәк котылу ягында. Аларны гаепләргә теләмим. Аннан, уку кайгысы калмаган кыз үзе дә мәктәпкә барырга бик атлыгып тормый. Бу минутта киләчәк турында уйламый әле ул: 9 нчы сыйныфны да тәмамламыйча мәктәптән китә дә бара. Менә бер мисал. Алиянең (исемнәр үзгәртелде. – *Ред.*) бала көткәне уку елы башлангач беленде. Октябрь ахырында ул инде бәбиләде. Әнисенә: «Оныгыңны яздыр үзеңә, аны барыбер син карыйсы, Алияң укысын әле», – дип әйтеп карадым. Ризалашмады. Кызы инде үсте, балалар бакчасына китте – Алиянең алдагы көне турында уйларга кирәк. Күбесе, әйткәнемчә, мәктәпне тәмамларга өлгерми, шуңа күрә «бала-әни»ләр югары белем турында хыяллана да алмый. Берәр һөнәр алыгыз, дип, бу кызларны, гадәттә, Апас һөнәр училищесына урнаштырырга тырышабыз.

«Бала-әни»ләр өчен җаваплылыкны җәмгыять үз өстенә алырга, нинди чыгымнарга барырга бик ашкынып тормаса да, бүген алар проблемалары белән япа-ялгыз түгел. Ярый, баланы тапты, ди, ул. Инде аны багасы бар бит: ашатасы, коендырасы, йоклатасы... Ә кызлар әле үзләре бала... Нәни төенчеген күтәреп: «Бүген ничек баш төзәтим икән?» – дип хәсрәтләнүдән башканы белмәгән әти-әнисе янына да кайтып керсә... Балага туу турындагы таныклыкны кайдан алырга икәнен дә күз алдына китерми ул. Үзенә пособие тиеш икәнлектән дә хәбәрдар түгел. Сөт кухнясына юлны да белми. «Өмет» үзәгенең Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге (җитәкчесе – Гүзәл Галиуллина) хезмәткәрләре кызлар өчен боларның барысын да үзләре эшли. Балигълык яшенә җитмәгән әниләргә Республика матди ярдәм күрсәтү үзәге филиалы 2016 елның гыйнварыннан башлап, бала туган көннән алып аңа яшь ярым булганчы 2 мең 908 сум күләмендә пособие түли хәзер. (Чагыштыру өчен: Европаның бик күп илләрендә мондый әниләр ай саен 600 евро күләмендә пособие ала. – *Ред.)* Балалар бакчасы өчен түләүдә бернинди дә ташламалар юк. Ә мәктәптә, район Башкарма комитетының карары белән, аларның балалары да бушлай ашый.

Яшь әни белән әти бергә булган очракта, бу гаилә яшәп китсен, аякка бассын өчен барыбыз бергәләп тырышабыз. Тик тырышлыкның җилгә очкан чаклары да бар. Менә Лена белән Ирек. Лена тәрбиягә алган гаиләдә, тырыш, тәртипле әти-әни янында үсте. Үз әнисе эчкече. Кызның 15 яшьтә балага узганы билгеле булды. Аннан 2 яшькә генә олы Ирек – социаль яктан тотрыксыз гаиләдән. (Районның икесе ике читендәге авылда, ике җирдә яшәп яткан шундый балаларның бер-берсен ничек эзләп табуы миңа һәрвакыт табышмак. Язмыш кыерсыткан җаннар бер-берсенә тартыламы соң шулай?! Табышалар, кавышалар һәм... дөньяга үзләре кебек үк бәхетсез балалар тудыралар. Ике арада мәхәббәт бөтенләй юк, дия алмыйм, ләкин ул, гадәттә, җитлекмәгән мәхәббәт була.) Ленаны тәрбиягә алган гаилә яшьләргә никах укытты, үзләренә сыендырды. Бераздан район җитәкчелеге аларга бүлмә бирде, Иректне эшкә урнаштырды. Кызларына 2 яшь булганда, ниһаять, Лена да үсеп җитте! Чибәр, ир-атның күзе төшәрлек булып. Чыгып китеп югала, баланы бакчадан алмый, өйдә үзен генә калдыра башлады... Хатынын бик яратса да, Ирек тә аны үз янында тотып кала алмады – кызларын бүген Ленаны тәрбиягә алган әти-әни үстерә. Геннарны гаепләргә генә кала...

Әйе, яшүсмер өчен балага узу һәлакәткә тиң: еш кына аның үз язмышы да, туачак сабыеныкы да җимерелә.

– Әйбәт кенә гаиләләргә килен булып төшеп, яшәп киткән кызлар бар. Алсуны менә кайнаналары якын

итеп кабул итте: оныкны алар карады, яшь әни укыды. Чыгып югалып йөрүенә дә түзделәр, аннан Алсу да басылды шикелле.

Тик мондыйлар сирәк шул. Бала кулдан төшүгә, 18-19 яшьтә, кызлар ялгышларын төзәтергә ашыга (үз-үзләренә, тирә-юньдәгеләргә: «Мин гаилә корып та яши алам!» – дип исбатларга теләү бугай бу), һәм… күбесе кабат ялгыша. Мондый очракта инде алар тормышка ышанычларын да югалта. Икенче тапкыр әтисез бала тапканнар да бар. Нығымаган, сынауларга каршы торырга көчсез әле алар. Тагын бер мисал китерәм. Гөлназлар гаиләдә дүрт бала, ул – олысы. Әти-әнисе айнымый эчә. Мин үземнең кызга 18 тулганын да, Гөлназның балигъ булганын көткән кадәр көтмәдем… Шушы гаиләгә бала алып кайтты ул. «Улыңны «Балалар йорты»на илтеп торыйк, тернәкләнсен. Син укуыңны тәмамла, эшкә урнаш, монда бала үстерә алмыйсың», – дидем. «Юк», – дип баш тартты. Атна саен барып йөрдек, балага кирәкле кием-салымны табыштырдык. (Безнең хезмәткәрләрнең бала киемнәре шкафында гел тәртип: артык, кечерәйгән кием-салым юк. Мохтаҗ гаиләләрдәге балаларга кирәк күлмәк-чалбар аларда гел табыла. Балаларны лагерьга, санаторийга җыйганда – бигрәк тә.) Никадәр ярдәм итәргә тырышсак та, кызганыч, Гөлназ үзе дә эчүгә сабышты: алты айдан соң улын алырга туры килде.

Күп вакыт баланы 2-3 яшькә кадәр үстергәч, яшь әни, сабыен туган нигездә калдырып китеп бара. Дәү әни-дәү әти янында начар түгел оныкка: аны яраталар, кимсенмәсен дип, ни теләсә, шуны алып бирәләр. Тик дәү әни барыбер әни түгел… Мондый баланың күңеле гел китек. Әнисе кияүгә чыккан очракта, ул аның яңа гаиләсенә сыямы әле? Бик сирәк гаиләдә генә баланың иярчен икәнен белмисең.

Сабыйлыктан чыгып җитмәгән кызның әни булуы, әлбәттә, дөрес түгел. Әмма һәлакәт тә түгел. Балаларыбызда әдәп-әхлак, сафлык кимеп баруга без – өлкәннәр гаепле икәнен аңламасак, менә шул чакта һәлакәтнең тагын да зурраги килер.



Айгөл ГАБДРАХМАНОВА, «Сәләт» клубы президенты, «Сәләт» яшьләр үзәге директоры урынбасары.

Безнең оешма 1994 елда эшли башлады, быел – 23 нче сезоныбыз. Шул вакыт эчендә безнең аша 70 меңнән артык сәлкеш узды. Әниләр кызларын «Сәләт» аланнарына җибәрергә икеләнәдер дип уйламыйм. Бездә мохит башка, сәлкешләрне тирә-юнь тәрбияли. Балаларга сез әйткән мәсьәлә турында сүз дә кузгатканыбыз юк. Берничә төп принцип бар «Сәләт»тә, шуның берсе – без яхшылыкка омтылабыз. Начарның – начар икәнен искә төшермичә, яхшының нинди булырга тиешлеген генә күрсәтәбез.



Айсылу НӘГЫЙМОВА, психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы.

Балигъ булмаган кыз баланың йөккә узуы гаиләдә бик авыр кабул ителә, тавыш-гауга чыга, хәтта көч куллануга кадәр барып җитәләр… Иң беренче киңәшем – җәнҗал кузгатмагыз: хәл бит инде орышудан узган! Әшне утырып сөйләшүдән башларга киңәш итәр идем: ни сәбәпле килеп чыккан бу хәл? Бәлки, кыз бала көчләү яки куркыту корбаныдыр? Әгәр инде ул җенси якынлыкка үз теләге белән барган икән – сәбәбе нидә? Нәрсә эзләгән ул әлеге якынлыктан: гаиләдә ала алмаган ярату хисенме, яклау эзләп сыенганмы, ә бәлки бу әхлак, тәрбия җитенкерәмәү нәтиҗәседер? Боларны белү әти-әнигә дә киләчәктә үзенең тәрбия юнәлешен дөресләү өчен бик мөһим. Сөйләшү вакытында кичерешләрегезне яшермәгез, шул ук вакытта гаепләү тактикасы да сайламагыз – ул балагызның тагын да үз эченә бикләнүенә китерәчәк. Ситуацияне анализлап, кызыгызның кайда ялгыш адым ясавын, аның сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен күзаллагыз. Алга таба ничек яшәү, булачак бала турында, аны үстереп, кеше итүнең никадәрле җаваплы һәм әһәмиятле булуы турында искәртегез. Шул ук вакытта бу сөйләшүне артык озынга сузарга ярамый: адым саен кызыгызны битәрләп торуның да файдасы юк.

Киресенчә, балагызга, бәлки, моңа кадәр биреп җиткермәгән мәхәббәтегезне бирергә, аны аңларга, гафу итәргә сәләтле икәнлегегезне күрсәтергә тырышыгыз. Бер ялгыш адым – гомерлеккә сугылган тамга түгел бит әле ул. Бу ялгышны балагызның җаваплылык хисен арттыру өчен кулланыгыз, шул ук вакытта ярдәмгә әзер икәнегезне сиздереп торыгыз. Баланы тәрбияләүдә әни кешенең роле нидән гыйбарәт булачак? Әлбәттә, монда булачак әнинең үзенә ничә яшь булуы, аның йорт эшләрен алып бару, балалар белән аралашу күнекмәләре булу-булмавы әһәмиятле. Бала туу сәбәпле, мәктәптә укуга зыян килү куркынычы барлыкка килә – уку белән бала тәрбияләүне бергә алып бару мөмкинлекләрен уйларга кирәк. Яшь әнине тормышка җайлаштыру шулай ук әти-әни өстендә кала – мөмкин булганча, аңа укуын дәвам итү өчен мөмкинлекләр тудырырга, профессия үзләштерергә ярдәм итәргә кирәк. Туачак баласына карата кызыгызда җылылык, ярату хисләре тәрбияләргә тырышыгыз: нәкъ менә әни мәхәббәтенең бик тә кирәк икәнен аңлатыгыз. Аның шәхси тормышын да бөтенләе белән сызып ташлау дөрес түгел. Тик хәзер инде тагын ялгышларны кабатламау, дус һәм партнер сайлауда талымлырак булырга кирәклеген искәртеп тору да комачауламас.

Ничек кенә булса да, туачак бала – сезнең оныгыгыз, дәвамыгыз. Шуны аңлап эш итсәгез иде. Ул сабыйны тәрбияләп кеше итү, һичшиксез, сезнең дә бурыч.

PRESSA.RU



КӘРАМ КЫЗЫ

БЕЗ СӨЙЛӘШКӘН АРАДА ГЫНА ДА АНЫҢ БҮЛМӘСЕНӘ ДИСТӘЛӘГӘН КЕШЕ КЕРЕП ЧЫКТЫ ИНДЕ.



Мәдинә
КАШАПОВА

Берөзлексез телефон шалтырады. Бүген ул – монда, иртәгә – Мәскәүдә... аннары аның ерак океаннар, диңгезләр артына китеп баруы да ихтимал. Эш аны дөнья буйлап шулай йөртә дә йөртә...

Минә шундый «продвинутый» кеше булып чыкты әңгәмәдәшем. Күпне күргән, күпне белгән, күп сәяхәт иткән кеше белән гәп куертуы бер яктан кызыклы һәм мавыктыргыч, ә икенче яктан... бер дә җиңел түгел, дип әйтер идем. Андый кешенең чәчелергә-түгелергә торган фикерләрен җыеп алу, күңелгә сеңдерә бару өчен аның белән бер сулышта булу, ә кайчак аны ярты сүздән аңлау кирәк.

«КАМАЗ» акционерлык җәмгыятенең менә инде дистәләгән еллар рәсми дилеры саналган «РариТЭК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять генераль директорының урынбасары, финанс эшләре директоры... Хәния Кәрам кызы САФИУЛЛИНАны бүгенге көндә коллективның брендына, мактанычына, горурлыгына әйләнгән КАМАЗ йөк автомобильләре өчен төрле запас частьлар җитештерү, йә булмаса, автомобильләрне газга көйләү мәсьәләләре генә түгел, бәлки барысы да борчый.

Шуңа да ул, онытканчы әйтеп калыйм дипме, сүзне бер проблемадан башлап икенчесе белән тәмамлый. Кайчандыр, моннан утыз еллар чамасы элек, хезмәт юлын КАМАЗның пресс-рам заводында гап-гади кисүче һөнәреннән башлаган унтугыз яшьлек кызны, бер ел да үтми, аның телгә осталыгын, оештыру сәләтен күреп-ме, заводның иң мөһим һәм җаваплы участогына – комсомолга (үзе моны ул чагында киң таралган БКД – боевая комсомольская дружиналарның актив эшчәнлеге белән аңлата) – авыр хәлгә юлыккан балигъ булмаган яшүсмерләр белән эшләүгә күчерүләреме, кыенлыкта яшәүче шул балаларның язмышы белән якыннан кызыксыну шулай иткәндерме, әңгәмәдәшем еракта калган ул елларга әйләнеп кайта да, һич көтмәгәндә балаларын әтисез үстерүче әниләр, сабыйлар хакында ачынып сөйли башлый. «Бик күп бит андый ярым-йорты гаиләләр, – ди ул, – әтисез үсү бик авырдыр аларга». Сүз үзеннән-үзе Түбән Кама, Алабуга шәһәр-ләрендә уңышлы эшли башлаган «Әтиләр клубы»на барып тоташа. Хәния Кәрамовна шул клубның эшчән-леге белән дә таныш икән.

Бераздан сөйләшү янә көтелмәгән борылыш ала. Февраль аенда ул АКШта – Калифорния штатында яшәүче татарлар янында булып кайткан икән. Шунда алган тәэсирләр ап-ачык булып күз алдына килеп баса. Чөнки ул шулай мавыктыргыч итеп сөйли-аңлата белә. Хезмәттәшләрен дә нәкъ менә шушы сыйфаты белән үзенә каратуын мин әле соңыннан аңлармын. Америкада яшәүче татарлар татарча сөйләшә, балалары Габдулла Тукай әсәрләрен яттан белә, гаиләдә татар көе, татар моңы... «Алар безнең гореф-гадәтләрне күз карасыдай саклый. Ялгыш русча сүз кыстырсаң, гаҗәпләнеп карап торалар. Уңайсыз булып китә», – ди ул, үзе дә күргәннәреннән хәйран калып.

«Аягымны да басмыйм, дигән идем...»

«Дөньяның мин булмаган почмагы калмагандыр», дип сөйләгән әңгәмәдәшем турында гел ял итеп, арка кыздырып кына йөргән икән дип уйлап ялгышмагыз. Аның илләр гизүе күп вакыт эше, вазыйфасы белән бәйле була.

– Ул чагында әле миңа 19 яшьләр тирәсе генә иде, – дип искә ала башлый Хәния Сафиуллина. – КАМАЗдан эш белән Якутиягә җибәрделәр. Барыр алдыннан анда яшәүче танышларга шалтыратам: «Күчтәнәчкә нәрсә алып килим?» – дим. Бәрәңге сорыйлар миннән. Бәрәңге алып килергә кушалар. Чөнки анда бәрәңге кытлыгы. Каз ите белән бер чиләк бәрәңге күтәреп килеп төштем Себергә. Август ае иде. Өстемдә җиңелчә генә кием. Ә анда инде бөтен дөнья ап-ак карда. Ул якларны күп таптадым. Төмәндә дә булдым. Беренче баруымда: «Бүтән аяк та басмыйм, борылып та кара-мыйм», – дип кайткан идем. Кая ул?! Бүгенге көнгәчә шул яклардан аерылганым юк. Хәзер безнең анда үзебезнең сервис үзәкләре бар. Кендекләр бәйләнгән, кыскасы.

Авылдан чыгып җитәргә дә өлгермәгән яшь-яшь кызның, бер уйласаң, дөнья читенә кадәр барып җитүе үзе үк батырлык.

– Тәвәккәл, үткен булган инде ул. Шулай булмаса, ике институт тәмамламас иде. Тормыш максаты итеп алга ул чагында әле буй җитмәс хыял шикелле тоелган биеклекләр яулауны куймас иде. Әгәр ул бүгенге көндә Татарстанның атказанган машина төзүчесе, бик күп Мактау кәгазьләренә лаек булган танылган, күренекле шәхес икән, бу уңышларны, әлбәттә инде, иң беренче чиратта, аның күргән бер яңалыкны бара-барышлый, йөгерә-йөгерешли тотып алу сәләте белән аңлатырга кирәктер. Ул үзе турында сөйләргә яратмый. Күбрәк дөнья гаме анда. Шулай да без үзебезгә кирәкле булган мәгълүматны алу җаен таптык. Булдыклылыгы, уңганлыгы ягыннан сеңлесеннән бер дә калышмаса булма-ган – Казанда яшәүче апасы Хәнифә Кәрам кызы Зәйнуллина туганы турында безгә бик яратып сөйләде.

Гомерен яраткан хезмәтенә багышлаган кешеләр сирәк алар. Ул – шундыйларның берсе. Үзенә дә җиңел булмаган шундый карарга килгәндә, аңа әле нибары 33 кенә яшь була.

«Әтинең исеме Мамай курганында язылган»

Аның сүзне әтисеннән башлавы тикмәгә түгел. Сталинград янындагы канкоешларда сәламәтлеген калдырып, туган авылына – Сарман районының Ләшәү Тамак авылына кайтып төшкәндә солдат егеткә 20 яшьләр тирәсе генә булгандыр. Туган илгә кайтыш-лый документларын югалта. Шул чагында аның инва-лидлык таныкнамәсе дә юкка чыга. Хәер, егетнең моңа бер дә исе китми. Нинди инвалид булып йөрүләр әле аңа?! Яшь ич әле ул?! Фронттан кайтуга башта хисапчы, аннары мал табибы булып эшли. Һәм... авылдагы иң чибәр, булган кызларның берсенә өйләнеп җибәрә.

– Гомер буе бер-берсен саннап, яратышып тордылар, – ди Хәнифә ханым. – Без гаиләдә җиде бала идек. Әни авылдагы урта мәктәптә рус теле укытты. Әти әнигә бик булыша торган иде. Ашарга пешереп, эштән кайтуын көтә, мал-туар карый. Әни безгә гел: «Хәнияне кулдан ычкындырмагыз, карагыз», – дип кушып китә. Аның әле ике-өч яшьлек чагын хәтерлим. Гел яныбызда булгангадыр инде, базны ачып, бәрәңгегә төшсәк, безнең арттан базга егылып төшә. Ярый имгән-мәгән шул чагында... Без аны бер дә үзебездән калдыр-мый торган идек. Бервакыт, июнь ае иде, ахрысы, әни эшкә киткәндә безгә бәрәңге бакчасын утарга кушты. «Карагыз аны, Хәнияне калдырасы булмагыз», – дип тә кисәтте. Кая инде калдыру? Без аны зур күн сумкага

PRESSA.RU





Ул таләпчән, төгәл, принципиаль. Әйтсә, сүзен кистереп-өзеп әйтә. Аңа каршы әйтү мөмкин түгел. Коллегалары аның хакында шулай диләр.

утырттык та бакча башына төшеп киттек. Чүп утап бетергәч, елга кырыена юнәлдек. Авыл башыннан гына Минзәлә елгасы ага безнең. Берзаман сумкабыз агып китмәсенме... Көчкә тотып калдык. Менә шулай... суга агып китә язды төпчегебез.

Истәлекләр, истәлекләр... Хәнияне әнисе Хәдичә апа, бик соңлап, 42 яшендә генә тапкан. Авырга узуын үзе дә белми калган. Эче үсә башлагач, әллә инде начар авыруы икән дип курыккан да әле. Ял итәргә, санаторийга баргач кына белеп кайткан йөкле икәнен. «Төшертәм, бу яшьтә кем бала таба?» Кәрам абзый шул чагында бер генә сүз әйткән: «Табасың!» Хәния Кәрамовнаның сүзләре искә төшеп куя: «Мине әти кызы дип йөртәләр иде». Чыннан да, шулай булган бит! Әти кызы!

– Безнең бер генә ир тугыныбыз бар иде, – дип дәвам итә Хәнифә ханым. – Иде дим, чөнки ул вафат инде. Апабыз Хәлимә дә вафат, калганнарыбыз – Халидә, Халисә, мин, Хәмидә һәм шушы төпчегебез Хәния, шөкер исән-саулар. Әти-әни дә мәңгелек дөньяда. Сугыш галәмәте булгандыр инде, әти иртә китеп барды. Аның исеме Мамай курганында – сугышта вафат булган солдатларга куелган һәйкәлгә язылган. Әни 86 яшен тутырып үлде. Дөньяның рәхәтен күрә алды, ичмасам. Бик акыллы, зирәк карчык иде.

– Үкенерлеге калмаган алайса.

– Юк, калды, – ди ул, офтангандай итеп. – Үлгәнче үкенде, дисәм дә, хата булмас. Хәния, Чаллыга киткәч, бер рус егетенә гашыйк булды. Шактый гына вакыт йөргәннән соң, кайтып, кияүгә чыгасын әнигә әйткән. Әни шул вакытта гомер буе үкенерлек гамәл кылып ташлаган: «Рус кешесенә кияүгә чыкмыйсың. Чыгасың икән, нигезне онытасың», – дип кырт кискән. Безнең әнинең шундый гадәте бар иде: әйтсә, өздереп әйтә, аңа каршы берәү дә бара алмый. Аның белән хәтта әти мәрхүм дә бәхәсләшми иде. Сөйләшү шуның белән тәмам булган. Апаем (Сарман якларында кече туганга, яратып, шулай дип дәшәләр) бу хакта башка сүз кузгатмады. Без – нәселдән килгән «однолюб»лар. Күзебез бер төшә – берәгәйле төшә. Хәния дә шундый булды. Ул башка берәү белән дә йөрмәде дә, кызыксынмады да... Әни миңа гел әйтә килде: «Малайларың өйләнәм дисәләр, юк димә. Шундук ризалык бир. Минем кебек ялгышма». Тагын кабатларга яраткан бер сүзе: «Пар булып яшәгез. Ирнең урыны табын түрендә булырга тиешлеген онытмагыз!» Тәмам үзәгенә үткән, күрәсең. Аның каруы, Хәния нигезне онытмый. Туган йортны карап, барлап, ныгытып торучы ул безнең. Бу җөмләдән янә Хәния Кәрамовнаның әйткәне искә төшеп куя: «33 яшемдә аңлы рәвештә катгый карарга килдем: тормышымны карьера ясауга багышлыйм, дидем!»

Хәния гел «5»ле билгеләренә генә укыган. Әнисе Хәдичә апаның кызын табиб итәсе килгән. Әмма кыз үз юлын үзе тапкан. Ул бүген Сәүдә институты тәмамлаган белгеч буларак, алыш-биреш мәсьәләләрен дә, КДУның юридик факультетында укыган кеше буларак, юридик мәсьәләләрне дә бик яхшы белә. Хезмәттәшләренең әйтүенә караганда, аның белән сүз көрәштерү файдасыз. Бу яктан ул гел әнисе инде.

Әле дә син бар...

Хәния Сафиуллинаның сыйныфташы Илсөяр Хәмзә кызы Кәлимуллина җан дусты турындагы фикерен шигъри юлларга салып аңлата. «Әле дә син бар әле дөньяда», дип әйтәм инде мин аңа, – ди. Бер сыйныфта, бер парта артында утырган дусларның, очрашканда, сөйләшеп сүзләре бетми. – Рәхәт аның белән, – ди Илсөяр ханым. – Аңа сер дә сыя, ул үпкәли дә белми. Сүз йөртүне өнәми, гайбәтне зурга җибәрми, шундук туктата. Аның янында теләсә нәрсә һәм теләсә кем турында сөйләшеп утыра алмыйсың. Авызыңны яба да куя. Мин беркайчан да аның киңәшеннән чыкмыйм. Ул ничек әйтә, шулай була. Гомумән, бөтен кызлары шундый аларның. Төпле нәсел, дип әйтәсе килә.
Алар барысы да әниләренә охшаган. Хәдичә апа минем белән – үзе укыткан укучысы белән дә якын дусты, сердәше сыман сөйләшә торган иде. Соңгы көненәчә шундый булды. Яратып, үз итеп әйтә торган бер сүзе бар иде аның: «парин» дип дәшә иде ул сөйләшкәндә. Шуны һич онытмыйм. Аннары Хәния турында сүз чыкканда, гел бер сүзне кабатлады: «Риза буласы калган...»

Истә калганы: Хәния гел китап укый торган иде. Дәрестә ул бер китап укып чыгарга да, сорауларга җавап бирергә дә өлгерә торган иде. Ул әллә нинди журналлар укый иде. Аның олы апасы Халидә Германиядә яшәде. Безгә шул вакытларда кызыклы-кызыклы журналлар җибәрә торган иде. Гаҗәп, алар рус телендә булыр иде. Мин ул журналларның рәсеменә мөкиббән китеп утырам, ә Хәния йотлыга-йотлыга эчтәлеген укый. Шуңа да бәләкәйдән күпне белә иде. Белмәгән нәрсәсе юк иде. Германиядән җибәрелгән зәңгәр галстук тагып йөргәнне дә хәтерлим әле. Аннан аларның кешедә булмаган пластинкалары бар иде. Без менә шул көйләрне тыңлап, хисләнеп йөргән кешеләр инде.
Ну язуы мәгәр начар иде. Укытучылар аны: «Бернәрсәңне аңлап булмый», – дип орышалар иде. Күпне белгән кешегә почерк та мишәйт итми әнә. Хәния ул төгәл кеше: мин шул вакытка кайтам дип әйтә икән, кайта. Шуны эшлим, моны эшлим ди икән, эшли. Ул авылда үз нигезен генә карап томый, авылга да зур ярдәм күрсәтә, хәйрия ярдәме диюем. Балалар бакчасына, мәктәпкә, мәчеткә ремонт вакытларында беркайчан да читтә калмый ул, кулыннан килгәнчә булыша».
Шуңа авыл кешесе аларны хөрмәт итәдер дә, олылапзурлап «Кәрам кызлары», дип йөртәдер дә.

...Ул әнә тагын ашыга-ашыга Мәскәүгә җыена. Аны анда җаваплы очрашулар, җитди сөйләшүләр көтә. Ул җитәкләгән җәмгыять вәкилләрен һәркайда теләп каршы алалар. Ник дисәң, бүген алар дөнья базарына юл алган, партнерлык өлкәсендә көндәшләреннән нык алга киткән дәрәҗәле компанияләрнең берсенә әверелделәр. Елына 12 миллиард сумнан артык продукция җитештерүче, илнең дистәләгән төбәкләрендә үзләренең үзкләрен булдыручы, Кытай, Германия, Төркия ише халыкара компанияләр белән дустанә һәм эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруга ирешә алучы коллектив турында аның җитәкчеләренә карап фикер йөртергә генә кала...



Ринат ХӘЙРУЛЛИН,
җәмәгатьчелек белән эшләү буенча баш белгеч.

■ «РариТЭК» компаниясе менә инде дистә еллар Якутиягә, Краснодар өлкәсенә һәм Татарстанга КАМАЗ техникасын һәм аңа кирәкле запас частьларны күпләп сату белән шөгыльләнә. Моннан тыш, бездәге НЕФАЗ автобусы илнең төрле почмакларына тарала. Завод белгечләре, үз эшләренең осталары, сатып җибәрер алдыннан, һәр автомобильне тикшереп чыгалар. Клиент теләге белән машиналарга өстәмә җиһазлар куела.

■ «РариТЭК» заводы беренчеләрдән булып КАМАЗ йөк машиналарын һәм НЕФАЗ автобусларын газга көйли башлады. Бүген без илнең барлык регионнарына газ ягулыгына көйләнгән меңнәрчә машина сатабыз. Ягулыкка зур акча тотылмый. Моннан предприятие ота гына.

■ Безнең предприятие йөк машиналарын, пассажир автобусларын һәм махсус техниканы сыйфатлы итеп үзе ремонтлый. Чөнки бездә профессионаллар эшли.

■ Компаниянең тагын бер юнәлеше – «РариТЭК-сервис» җәмгыяте хезмәт күрсәтү техникасы өчен корылма рәвешендә кулланыла торган төрле күләмдәге каркас-тент конструкцияләре эшләп чыгара башлады. Алар спорт комплекслары, теннис кортлары, стадион трибуналары, Сабантуйлар вакытында мәйданнар кору өчен дә кулланыла.

■ 2013 елны, Казанда Универсиада үткәрелгән көннәрдә, «РариТЭК» заводында тент һәм металлдан җитештерелгән корылмалар бөтен шәһәр буенча кулланылды. Барысы заманча 159 корылма куелды.

■ 2015 елда исә су спорты төрләре буенча XYI Дөнья чемпионатын үткәрү өчен «РариТЭК-сервис» көче белән «Казан-Арена» стадионында тентлы асылмалар урнаштырылды. Һәм бу әле компания эшләгәннәрнең бик азы гына.

■ Компания хезмәткәрләрен һәрвакыт республика, үзебезнең шәһәр һәм районыбыз авыллары тормышы кызыксындыра килде. Без аларга булдыра алганча матди ярдәм күрсәтергә тырышабыз. Һәртөрле чараларда бик теләп катнашабыз, төрле оешмаларга, балалар бакчаларына, мәктәпләргә, интернат йортларына һәм хастаханәләргә әледән-әле иганәчелек ярдәме күрсәтеп торабыз. Һәрдаим игътибарга мохтаҗ булган ветераннарыбыз турында да онытмыйбыз.
2010–2015 елларда компаниянең хәйрия эшләренә тотылган матди ярдәме 14,3 миллион сум тәшкил итте.

■ Һәр елны «РариТЭК» компаниясе милли бәйрәмебез – Сабантуйны оештырырга булыша.

■ Татарстанның рухи мирасын яңартуга һәм саклауга да зур игътибар бирелә. «РариТЭК» торгызуга, яңартуга мохтаҗ булган мәчетләргә, чиркәүләргә ярдәм кулы суза.
Яңа елда «РариТЭК-сервис» компаниясе белгечләре тарафыннан куелган 21 метр озынлыктагы чыршы «Районның иң матур бизәлгән Яңа ел чыршысы» бәйгесендә беренче урынны алды.

PRESSA.RU


Фото: Ксения Богданова

ЧЕБЕШ БИЗНЕСЫ

Лилия
ГӘРӘЕВА

«АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТӨПСЕЗ КОЕ КЕБЕК. АҢА КЕРТКӘН АКЧА КОМГА СУ СИБҮГӘ ТИҢ», – ДИСӘЛӘР ДӘ, ТЫРЫШ, ТӘВӘККӘЛ КЕШЕЛӘР БҮГЕН АВЫЛДА ДА НАЧАР ЯШӘМИ.

Колхозлар юкка чыккан, авыллар дачага гына әйләнеп барган заманда, үз эшләрен ачып, гаиләләре белән бергәләшеп эшләүчеләр сокландыра да, кызыктыра да. Тырыш кешеләрне күреп, менә бит, булдыралар бит, дип бар дөньяга ишеттерәсе килә.

Аксубай

Бөтен кеше шәһәргә китәргә тырышканда, алар авылга кайта. Чаллыдагы бер дигән эшләрен, шәп фатирларын калдырып бит әле. Пенсиягә чыккач, авыл һавасы сулап, бакчада казынырга гына дип кайтмый шул алар, эшләргә кайта.

Аксубайга – Зөлфия һәм Вәлит Гатиннар хуҗалыгына барырга көздән үк килешеп куйган идек. «Яз килерсез, бәбкәләр чыккач. Яз көне бездә бик күңелле була», – диделәр. Бәбкәләр чыккан чакны чамалап, юлга кузгалдык.

«Пип! Пип! Пип!» Аксубай инкубаторында безне бәбкәләр хоры каршы алды. Әйтерсең лә, концерт программасы әзерләп көткәннәр! «Болары бер атналыклары. Әнә тегеләре үрдәкнеке, болары – каз бәбкәләре. Күркәләр дә бар...»

Зөлфия апага ияреп, инкубаторга керәбез. Коридор буйлап шкафлар тезелгән. Анда – йомыркалар. Шкафлар – Вәлит абый биләмәсе. Бер көнгә түгел, бер сәгатькә дә ялгыз калдырмый ул аларны. «Февраль аенда ачып керәбез, 19 июньгә кадәр, инкубаторны япканчы шушында куна-төнә эшлибез. Төрле хәлләр булырга мөмкин, ут сүнәргә, шкафлар кызарга... Шуңа күрә бе-

ребез гел кизүдә. Төнлә дә чиратлап йоклыйбыз», – ди хуҗалар. Вәлит абый гомере буе шушы өлкәдә эшләгән кеше – тәҗрибәсе җитәрлек.

2003 елда ачып җибәргән алар үз эшләрен. Беренче елны Яңа Аксубайдагы элеккеге колхоз инкубаторын арендага алып эшләп караганнар. Эш башлау өчен акча кирәк – фатирларын, бакчаларын сатканнар. Яңа Аксубай кош-корт үстерү өчен кулай җир булган булуын, тик менә юллары гына... Язын машина белән керермен димә. Чыккан чебешләрне сатарга кирәк, ә сатып алучылар авылга керә алмый. Икенче елны инде Аксубайның үзенә күченгәннәр, элеккеге котельня бинасын төзекләндереп, инкубаторны шунда көйләгәннәр. Эшләү дә шунда, яшәү дә... «Уңайлы фатирыңны ташлап, чебиләр арасында яшә инде син, ә!» Зөлфия апа ул чактагы авырлыкларны искә алып, баш чайкап куя.

Безгә монда бар да кызык. Менә бу шкафта чебешләр борынлый башлаган. Тагын бер шкафта – үрдәк бәбкәләре. Йомыркадан чыгып, әле кибәргә дә өлгермәгәннәр. Боларны күрүгә, хәтер балачакка, авылга – дәү әни янына «йөгерә». Бәбкәләр борынлаган көнне дүрт күз белән көтә идек без. Ул бәбкәләрне дәү әни алъяпкычына салып өйгә алып керә. Бабайдан калган иске бүректә ярты көнләп кибә әле алар. Шулкадәр матур, шулкадәр хуш иселәр! Инкубаторда бүрекләр юк, билгеле, бәбкәләр «выводной» шкафта гына кибә. Аннары инде кайсы кая озатыла. Авылда хәзер йорт казы тотучылар сирәк. Күп кеше бәбкәләрне инкубатордан сатып алуны хуп күрә. Халыкның иң күпләп алганы – бройлер чебеше икән. Зөлфия апалар «КОББ 500» токымлысы белән сату итә. Алар тиз һәм зур булып үсә. Элегрәк «Конкурент», «Смена» токымнарын да сатканнар, алары беразваграк. Май ахырына «Гатина» крестьян-фермерлык хуҗалыгы 15 мең бройлер чебеше үстереп саткан инде. Чебеш чыга торган шкафларга йомырканы атнага бер тезәләр. Казларныкын – 10 көн саен, үрдәкне – йомыркага карап. Йомырка табу, чыккан чеби-бәбкәләрне сату – Зөлфия апа өстендә. Йомырка сатучылар белән килешүне көздән үк төзиләр. Бройлер йомыркасы Чехиядән кайта, үрдәкнекен Башкортстанга барып алалар, «Линда» токымлы казныкын – Мари Иленнән... Беренче елларда 5-6 сумга алган йомыркаларның бәясе бүген инде 5-7 тапкыр арткан. Йомырка кыйммәт булгач, чебешләргә дә бәя арта. Бройлер чебеше, каз-үрдәктән тыш, монда әле кызыл тавык, күркә, күркә-үрдәк (индоутка) һәм мулард чебешләре дә чыгарыла.

Инкубатор белән бер кат танышып чыккач, Зөлфия апага ияреп, Шәрбән авылына юнәләбез. Аксубай белән Шәрбән арасы ерак түгел, 15 чакрымлап булыр. Колхозның дүрт стенасы гына утырып калган иске гаражын алып, анда кош-корт үстерер өчен ферма төзегәннәр. Болары инде уллары Марат белән киленнәре Илнара биләмәсе. Моңарчы әти-әниләре белән уртакка эшләгән булсалар, быелдан үзбаш тотынганнар. «Яшьләргә ирек кирәк. Үзләренә үзләре хуҗа булгач, тырышыбрак эшләргә стимул була ул», – ди Зөлфия апа. Аерым, дисәләр дә, бергә инде алар. Яшәүләре дә бер йортта. Июнь аенда инкубаторда соңгы чебешне чыгарып, шкафларны юып чистарткач, Зөлфия апалар Шәрбәнгә күчә. «Кичә кичке унда килеп тә бәбкәләрен барлап киттем әле», – ди ул.

Ашату-эчертү барысы да автоматка көйләнгән. Кошларга дигән комбиазыкны да үзләре әзерли. Үз басуларында үскән арпа-бодайны үз тегермәннәрендә тарттыралар. Узган ел 100 гектар чәчү чәчкән булганнар. Ишегалдында – комбайн, тракторлар... Ашлык амбарында әрҗәле КАМАЗ тора. Сатудан артып калган бәбкәләрне ноябрьгә кадәр үстерәләр дә ярминкәгә алып чыгалар. «Каз йолкырга авылдан бер-ике апаны да чакырабыз. Казларны башта кайнар су белән пешеклибез. Аннары мамыгын кечкенә капчыкларга салып, кер машинасында юабыз. Кирәк кешегә мендәрләр тутырып та сатабыз», – ди Зөлфия апа. Шәрбәндә Илнараны «тота» алсак та, Маратны күреп булмады. Иртән Казанга чыгып киткән. Чәчү вакыты – запчасть кирәк.

Чиста, якты залларда айлап түгел, көнләп үсә кош-корт.

Авырлыклар турында сүз кузгатырга яратмыйлар монда. «Булды инде, беренче елларда шактый нужаландык», – диләр дә, бетерәләр. Шулай да бер очракны искә төшереп алды әле Зөлфия апа. Зур бер фабрика белән күркә йомыркасына килешү төзегән булганнар. Халык алдан ук чиратка язылган, акчасын түләгән. Йомыркалар борынлар көн килеп җиткән, ә алар-









PRESSA.RU

ның бөтенесе диярлек чәберчек булып чыккан! Ничек итсәләр итеп, башка фабрикалардан үзләре сатканнан кыйммәткәрәк хакка булса да алып, халыкның ышанычын аклаганнар ул чакта.

Зөлфия апаның телефоны бер дә тынмый – халык чеби сорый, каз кирәк ди, үрдәк белешә. Яз көне авыл җирендә иң кирәкле тауар ул.

Арча

«Нигъмәтуллина» крестьян-фермерлык хуҗалыгы җитәкчесе Гөлшат апа озак еллар мәктәптә математика укыткан. Инкубатор эшенә ире Марат белән уйламаган җирдән генә керешеп киткәннәр. Яз җитсә, кайдан чебеш алырга, кайдан бәбкә табарга дип, хәсрәтләнәсе юк хәзер район халкының. Инкубатор иртә яздан җәй уртасына кадәр гөрләп эшләп тора.

Каз-тавык үстерүнең беренче сере – яхшы җим.

«Башкалар янында без әле өйрәнчек кенә, – ди Гөлшат апа. – Беренче елны аз гына чыгарып карадык. (Аз дигәне – 7 меңнән артык!) Тәҗрибә булмагач, йомырканы күбрәк алганбыз, ә халык әле безне белми. Шулай да чебешләрнең барысын да сатып бетердек. Халыкка безнең продукция ошады. Икенче елны тагын килделәр...»

Бүген алар каз-үрдәк, бройлер, күркә, мулард чебеше белән сату итә. Чебешләрне бер ай үстереп сату өчен уңайлы цех булдырганнар. Арчадагы инкубатор районга өстәмә эш урыннары да биргән – унлап хезмәткәр эшли: Гөлчәчәк, Гөлнара, Илдар, Рәшит абыйлар, Флера апалар монда беренче генә елын түгел инде. Гөлшат апа йомырка белешә, чыккан чебешләрне урнаштыра. Әниләре барып белешкән йомыркаларны уллары Ленар төяп алып кайта. Моның өчен ишегалларында термослы махсус машина тора. Әтиләренең исә үз бизнесы – ул машиналарны газ ягулыгына көйләү белән шөгыльләнә. Аннан – финанс кайгыртуы һәм төпле киңәш.

«Алган бәбкәләр нык булсын, тиз үссен өчен ниләр эшләргә кирәк?» – дип, серен белешмәк булабыз. Алай беркемнән дә яшерен сере юк икән. Беренче көннәрне антибиотик эчерәләр, аннары витаминнар бирәләр. «Хәзер кош-корт үстерү җайлы, – ди Гөлшат апа. – Дарулары да бар, витаминнары да... Баштарак мин ул даруларны бушка да биреп җибәргәләдем. Бездән алган кошлары үссен, кешеләр канәгать калсын дип тырышабыз. Җимнең дә тегенди-мондые ярамый. Халыкка да аңлатабыз – шулкадәр акча түләп алгансыз икән бәбкәләрне, кимендә бер-ике атналык булганчы, махсус җим ашатыгыз, дибез. Бәрәңге ашап та үсә ул, диләр кайберәүләр. «Ник үзегез гел бәрәңге генә ашамыйсыз соң?» – дим. Кошларга да төрле азык кирәк. Хәзерге җимнәрдә аларга кирәкле барлык витаминнар да бар. Яшь чебеш-бәбкәләргә зур кошларга ашата торган азык бирергә ярамый. Күркә азыгы аерым, казныкы – үзенә. Без үзебез дә җимне сатып алып ашатабыз. Һәр кош-кортның җәһәт үсеп китә торган үз чоры була, шул чорда аңа тиешле җим кирәк. Хәзер инде моны сатып алучылар да аңлады. Соңыннан килеп рәхмәт әйтәләр».

Гөлшат апалар күбесенчә күмәртәләп сатып алучылар белән эш итә. Без килгән көнне дә ишегаллары машина паркын хәтерләтә иде. Берсе килә, берсе китә... Галина белән Илдар Хәкимуллиннар әнә Ижаудан ук килгәннәр. Кичә дә 300 күркә алып киткән булганнар, бүген алары сатылып беткән. Арчага кадәр, иртән-иртүк Әлмәттән бер рейс ясаганнар инде. Университет тәмамлаган Галина элек радиожурналист булып эшләгән. Балалар да укыткан. Моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән бу эшкә тотынуларына – 15 ел. «Баштарак кошларга антибиотиклар эчерәсен дә, витаминнар бирәсен дә белмәгәнбез. Бәбкәләребезнең яртысыннан артыгы үлә иде. Безнең якларда инкубаторлар юк. Халык бездән бик рәхәтләнеп сатып ала. Монда чыккан чебешләр дә, бәбкәләр дә бик нык була. Тиз үсәләр. Әле мулардлар бетеп киткән, иртәгә аларын алырга барабыз», – ди Галина.

Мулард бәбкәләрен өй шартларында үстерү өчен гаять җайлы кош дип, монда килгәнче дә ишеткән идек. Бишәр килограммга кадәр үсәләр икән. Тавыш-тыны да юк, зур сулык та кирәкми. Күркә кебек, теләсә кая кунып та интектерми.

Гөлшат апаның бәбкәләреннән дә, бәяләреннән дә канәгать клиентлар кайтыр юлга кузгала. Йокы күрми, ял күрми көненә меңнәрчә чакрым юл үтү шулкадәр табышлы микәнни дип аптыраган идем – табышлы икән. «Ярты елга миллион сум акча эшлибез», – ди Галина. Моның өчен тырышсаң да була шул.









Фото: Лилия Гарәева

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Германиядә эш визиты барышында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Дрездендагы «Германия–Россия мәдәният институты» иҗтимагый оешмасы залында Г. Тукайның 130 еллыгына багышланган әдәбимузыкаль кичәдә катнашты. «Татарлар Дойчланд» мәдәниятара интеграцион үзәк вәкилләре Тукай шигырьләрен укыдылар. Әлеге үзәк Германиядә Сабантуйлар үткәрә, төрле мәдәни чаралар оештыра. Польша, Чехия, Бельгия, Франция, Люксембург, Балтыйк илләрендә яшәүче милләттәшләр дә теләп килә ул чараларга.

■ Чит илләрдә ял итү чикләнү сәбәпле, эчке туризм үсеше, шул исәптән елга круизлары популярлыгы арта. Татарстан территориясендә туристларның озаккарак калуы күзәтелә. Алар, Казаннан тыш, Алабуга, Чистай, Болгар, Зөя, Тәтешкә сәфәр кылалар. Татарстанлыларга исә Төркия һәм Мисыр урынына Татарстан буенча автосәфәр һәм санаторийларда ял тәкъдим итәләр.

■ 2016 елның икенче яртыеллыгына матбугатка яздыру буенча «Әтиәниеңне язды! Якыннарыңны язды!» акциясен республиканың танылган кешеләре, депутатлар, министрлар, зур оешма җитәкчеләре, артистлар хуплап алды. Алар өлкәннәр һәм инвалидлар интернатларында, балалар йортларында тәрбияләнүчеләргә, мәктәп-лицейларда укучыларга газета-журналлар яздырып бүләк итте.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ ТР Президенты Указы белән матур әдәбиятны үстерүгә шәхсән өлеш керткәне өчен Лена Шакирҗановага «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде. Шагыйрәгә таныклык туган көнендә – 4 июньдә тапшырылды.



КАЗАН

■ Татарстан башкаласында «Кунакчыл Казан» проекты старт алды. Шәһәрнең иң күп йөрелә торган өч урынында волонтерлар туристларга шәһәрдә ориентлашырга ярдәм итәчәк һәм Казанның истәлекле урыннары турында иң кызыклы мәгълүматларны җиткерәчәк. Проектта студентлар да катнаша.

■ Казан шәһәре тарихында беренче тапкыр башкала Сабан туе алдыннан урамнарга атлар җигеп чыгып, гармуннар уйнатып, җиңүчеләргә сөлгеләр һәм бүләкләр җыеп йөрделәр. Җигүле атлар Г. Камал театры яныннан узганда артистлар бүләккә колгага танылган «зәңгәр шәл»не бәйләде. «Мирный» бистәсендәге Каенлыкта узган Казан Сабан туен исә 50 меңнән артык кеше тамаша кылды.

МӘДӘНИЯТ

■ РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев «Кызыл мәйдан» китап фестивалендә булып, Татарстан китап нәшрияты күргәзмәсендәге китаплар белән танышканнан соң, нәшрият эшчәнлегенә югары бәя бирде. Муса Җәлилнең тууына – 110 ел уңаеннан, нәшрият герой-шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре»н һәм төрле елларда басылып чыккан башка китапларын да тәкъдим итте. Чарада Муса Җәлилнең кызы Чулпан Җәлилова да катнашты.

■ Мәскәүдә яшәп иҗат итүче якташыбыз Гүзәл Яхинаның «Зулейха открывает глаза» романын язучы Флёра Тарханова татарчага тәрҗемә итте. «Зөләйха күзләрен ача» китабы рәссам Ринат Хәсәншин бизәлешендә Татарстан китап нәшриятында нәшер ителеп дөнья күрде. Тәкъдим итү кичәсе Тукай залында узды.



БАЛАЛАР

■ Балаларны Халыкара яклау көнендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда республикадагы иң зур шәхси балалар бакчасын ачу тантанасына килде. 7 мең квадрат мәйданга сузылып, 18 төркемгә берләшүче 486 сабыйга исәпләнгән әлеге балалар шәһәрчеге «Имәнлек» экопаркында урнашкан. Яңа ачылган бакчаның үзенчәлеге шунда: сабыйлар дөньяны берьюлы дүрт телдә – татарча, русча, кытайча, инглизчә танып беләчәк.

■ Казандагы 179 нчы мәктәп укучысы Амалия Садыйкова музыка мәктәбенә йөри, гимнастика белән шөгыльләнә. Ул матурлык һәм талант буенча уздырылган республика балалар бәйгесендә катнашып, «Матурым» номинациясендә Мини-мисс титулына ия булды.



PRESSA.RU



Казанда Универсиада уздыру идеясен иң беренче булып ул уйлап таба! Марат Бариев диюгә – шундук Универсиада, Универсиада диюгә, әлбәттә инде, Марат Бариев искә төшә. 5642 метр биеклеккә күтәрелеп, Эльбрусны яулаучы да ул! Республиканың иң беренче Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры! «Татарстан яшьләре», «Татарстан балалары» программалары, «Созвездие-Йолдызлык», «Алтын каләм» фестивальләре, «Сәләт» хәрәкәте... Казанда спорт төрләре буенча үткәрелгән Европа, Дөнья чемпионатлары... Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү, талантлы яшьләрне үстерү, яшьләр мәнфәгатьләрен, бала хокукларын яклау буенча кабул ителгән закон һәм программалар... Барысы да – аның эшчәнлеге. Бүген Марат Мансур улы БАРИЕВ – Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты, Россия Олимпия Башкарма комитеты әгъзасы, Дәүләт Думасында физик культура, спорт һәм яшьләр эшләре буенча комитет рәисенең беренче урынбасары.



Эльмира ЗАКИРОВА

«МИН ТАУНЫҢ БАШЫНДА БУЛЫРГА ТИЕШ!»



ТАМЫРЛАР Әти-әнием – Балтач ягынныкылар. Әнием Люция Чутай авылыннан, ә әтием Мансур Кукмара районында туган, бераздан гаиләләре белән Чепьяга күчеп килгәннәр. Шул вакытларда әниләр дә Чепьяда яшәгән, Гайшә әбием Чепья мәктәбендә укыткан. Әти белән әни бер класста укыган. (Бездә шундый традиция: әти белән әни дә, хатыным белән мин дә, сеңлем Әлфия белән аның ире дә – классташлар!) Әнием пединституттан соң үзе дә Чепья мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта башлый. Чутай бабам Сөләйманов Нургаян да, Чепья бабам Шәфигуллин Бари да – сугыш ветераннары. Мин 5 нче сыйныфта укыганда әти үлеп китте. Күп тәрбияне Чутай бабам бирде. Шуңа якын һәм кадерле ул миңа. 9 Май көнне Казанда, Нургаян бабам портретын күтәреп, «Үлемсез полк» сафында атладым. Фин сугышында, Бөек Ватан сугышында катнашкан, Смоленск янында

яраланган бабам белән горурланам. Әтием спортны, музыканы бик ярата иде. Җиңел атлетика, гимнастика, бокс, чаңгы, марафон йөгерүләре – барысы да аныкы. Барлык музыка коралларында уйный белә. 60 нчы елларда Ленин исемендәге мәдәният сараенда баянда уйнап йөри. Магнитофоннар юк чак, аны төрле мәҗлесләргә, туйларга чакыралар. Хәтерлим: мин 3 нче класста укыганда әти белән әни пианино алып кайтты. Северный бистәсенең иң читенә урнашкан өебезгә бөтен урам килеп тулды карарга. Пианино күргән кеше юк. Күбесе авылдан күчеп килгән: кайсы 16 нчы, кайсы 22 нче заводта эшләүчеләр. Әти пианиноны ачты да, уйный да башлады. Мине дә музыка мәктәбенә бирделәр. «Пианинода уйныйсым килми, аккордеонда уйнар идем», – дип көйсезләнгәнем истә. Әти «унөченче» зарплатага алам дигән иде – гыйнварда үлеп китте. Шулай итеп, мин аккордеонда уйный алмый калдым..



БАЛАЧАК Без үскәндә, Северныйга Мадияровлар күчеп килде. Танылган самбистлар. Башка барыр җир юк иде. Без, малайлар, Химиклар мәдәният сараена самбога йөри башладык. Мәктәпкә чаңгычы абый тренер булып килде – шулай итеп спортка кереп киттем. Тәртибем аркасында әнине мәктәпкә чакыртканнары истә. Оят булды инде! Бөтен билгеләрем «биш»ле, ә тәртипкә «неуд» чыга синең дип куркыталар. Бер әйтмәдем, икенче әйтмәдем әнигә... Ял көнне таныш тавышка уянып китсәм – класс җитәкчесе әнигә миннән зарланып утыра! Тиз генә тәрәзәдән чыгып качтым! Әни мине аңлады. Малайлар шуклыгы гына бит инде... Авылны бик ярата идем! 28 майларда уку бетә, икенче көнне үк сызам Чутайга! Анда кайту бик мәшәкатьле иде. Казаннан Малмыжга ПАЗик автобусында, аннан ничек туры килсә шулай – авылга... Казанга 30-31 августларда гына елый-елый кире килам. 6-7 нче сыйныфларда укыганда авыл хуҗалыгы институтына керәм дип йөри идем. Авыл бик күп нәрсәгә өйрәтте: татарча сөйләшергә дә, хезмәткә дә, гореф-гадәтләргә дә... Ә менә Казанда, кызганычка каршы, башкачарак иде. Безнең Северныйда җыенысы татар югыйсә. Ә мине ник татарча сөйләшәсең, дип орышалар. Күрше апалар керә дә, әнигә: «Ник Маратың безнең балалар белән татарча сөйләшә? Үзе русча әйбәт белә ул! Безнекеләргә дә өйрәнергә кирәк бит», – диләр.



МӘКТӘП Аттестатта инглиз теленнән генә «дүрт»ле чыкты. Яраткан дәресләрем математика, физика, физкультура, югары классларда тарих ошый башлады. Әдәбиятны дәрескә дә чутламыйм. Көне-төне китаплар укыйм. Бүлмәмнең ишеге пыяла иде, утны сүндермәсәм – күренә, ник йокламыйсың, дип әни ачулана. Шуңа күрә юрган астында фонарь яндырып укый башладым. Мажаралы китаплар ярата идем. Джек Лондон, Майн Рид, Дюмаларны... Ә җәй көне Чутайда татарча китаплар укыйм. Авыл китапханәсендә миңа ышанып бирәләр. Анда миннән алты яшькә өлкәнрәк Наил абыем бар иде. Ул да гел китаплар укый. Аңа карап мин дә. Аның дәреслекләрен дә укыштыра идем әле. «Кайсы вузга керүе кыен – шунда барам!» – дигән Наил абый мин мәктәп бетергән елны КАИны тәмамлады. Ә мин КАИга укырга кердем. Әлбәттә инде, Наил абыйның да йогынтысы зур булды.



УҢЫШ Фән белән дә кызыксына идем. Авиация, аэродинамика, конструкторлау ошый иде. Институтта өч ел эшләгән проект та бар. Диплом темам: «Глубоководный автономный подводный аппарат на глубину 7 тысяч метров Тихого океана». Аэродинамика белән гидродинамиканың эшләү принциплары охшаш. Тегендә һава, монда су... Кызыксынып, яратып эшләдем. Фәнни консультантым космонавт Демин... Шуның белән бик горурланып йөри идем.
Институт тәмамлагач, Горбунов исемендәге Казан авиация берләшмәсенә юллама белән инженер-конструктор булып эшкә килдем. Бераздан комсомол комитетына чакыра башладылар. Әле бер эшкә, әле икенчесенә җәлеп итәләр, миңа кызык: катнашам. Ләкин күчәсе килми. Аннары мине, күчсәң, фатир мәсьәләсен хәл итәбез, дип кызыктырдылар. Чөнки гаиләм, балам бар иде инде. Юллама белән эшкә килүем дә кызыклы. Казанныкыларга барыбер фатир бирмиләр дип, Иркутск, Ташкент кебек шәһәрләрне сайлап торганда, авиация берләшмәсе генераль директоры урынбасары: «Нишләп безгә түгел?! Әйбәт белгечләр безгә дә кирәк!» – ди. Гомер күрелмәгән хәл: юлламага «фатир белән тәэмин итәргә» дип тә язып, мине Казанда калдырдылар. Ләкин эшкә чакырган ул кеше озак та тормый пенсиягә китеп барды, фатирга өметләнәсе дә юк. Үзем дә, өйдәгеләр дә көтә идек инде. Мин-минлегемә тиде бу. Ә мин җиңәргә күнеккән! Гел беренче булырга! Конструкторлык бүлегеннән комсомол комитетына килеп урнаштым. Аннары ВЛКСМның Ленин районы комитетына: башта – икенче, аннары беренче секретарь итеп билгеләделәр. 80 нче елларда бу. Хәбәрдарлык, үзгәртеп кору чорлары. Яңа җилләр исә. Без курыкмый идек, фикерне әйтәбез, мәйданнарга чыгабыз, яңа эшләр уйлап табабыз. «Яшьләр фонды» оештырып җибәрдек, «Яшьләр турында» закон кирәк дип йөри башладык. Закон да кабул ителде. Ләкин дәүләт тарафыннан бернинди ярдәм юк, бернәрсә оештырылмый. Инде тормышта үз урыныңны табарга кирәктер, дим. Бер зур җыелышта ялкынлы саубуллашу чыгышы ясадым. Кызларга, егетләргә бик күп еллар бергә эшләгән өчен рәхмәт белдердем. Дәүләт үзе ярдәм итмәгәч, дәүләткә яшьләр кирәк булмагач, без үзебез генә җиңеп чыга алмыйбыз кебегрәк сүзләр дә әйттем. Икенче көнне район башлыгы чакыра: «Син анда кичә нәрсә сөйләдең?» – ди. Аннары ник чакыруын әйтте: иртәгә мине Кремльдә көтәләр икән. Менә шунда Минтимер Шәрипович миңа республикада яшьләр эшләре буенча дәүләт комитетын оештырырга тәкъдим итте. Эшли башлау белән, Мәскәүгә киттем, иң алдынгы төбәкләрне карап, өйрәнеп, йөреп чыктык. Яшьләр оешмаларын оештырып, аларга ярдәм иттек. Яшь гаиләләрне тораклы итү өчен закон һәм программалар керттек. Бик авыр иде. Аңламыйлар. Яшьләргә без ничек акча бирик? Егермешәр ел чиратта торабыз. Дөрес түгел бу, диләр. «Шунсыз яшьләр гаилә кора алмый, балалары булмый. Хәзер тормыш бөтенләй башка-

PRESSA.RU

ча», – дип аңлаттым. Тәки җиңеп чыктык – 1997 елда «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме турында» республика программасы кабул иттек. Аннары без пионер лагерьларының 90 процентын саклап кала алдык. Ташландык хәлдә иде алар. Мәгариф министрлыгы да, Социаль яклау министрлыгы да алырга теләми. «Әйдәгез, мин алам», – дип чыктым.

Бервакыт Минтимер Шәрипович сорый, яшьләр оешмасын спорт белән берләштерүгә ничек карыйсың, ди. «Бу алым әйбәт, спорт белән кызыксынучылар да шул ук яшьләр. Ләкин спорт инфраструктурасы бик зур, ә без әле кечкенә, кушсак, ул аны йотачак, вакыт кирәк», – дим. Берничә ел узгач, Президент тагын шул сорауга әйләнеп кайта: «Ә хәзер ничек?» – ди. «Хәзер була!» – дим. 2001 елда республикада яңа министрлык – Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы оешты... Халыкны ничек спортка җәлеп итәргә, нинди зур спорт чаралары үткәреп була, имиджны ничек яхшыртырга – шулар турында уйлана башладык. Менә шул чагында Универсиада үткәрү идеясе башка килде дә инде! Әлбәттә, Олимпиаданы үткәрергә рөхсәт бирмәсләр, Россиягә дә бирмиләр әле, дибез. Россиядә бернинди чемпионат та узганы юк иде. Чөнки бөтен традицияләрне 90 нчы елларда югалтып бетердек... Үзем Универсиада белән гел кызыксынып тордым. Минем бер иптәш малай КАИда укыганда Универсиадада катнашты да әле. Аны гел күзәтеп бара идем. Ул вакытта Универсиаданы бик белүче дә юк. Якын кешеләремне җыеп, шул Универсиада турында сүз кузгаттым, ә нишләп әле үткәрмәскә дип, тәвәккәлләп тотындык. Универсиада турындагы идеябезне ул вакыттагы Премьер-министр Рөстәм Миңнехановка әйтергә бардым башта. Кызыксынып тыңлады. Президентка барырга кушты. Киттем Минтимер Шәриповичка. Универсиаданың Казан, Татарстан, яшьләр өчен нинди өстенлекләр бирәсен, башкалабыз ничек үзгәрәсен сөйләп күрсәттем. Игътибар белән тыңлады. Ярар, уйлармын ди. Бер атна үткәч, чакыра: «Әйдә, ниятләп куйыйк инде», – ди. Әнә шуннан китте инде безнең Мәскәүдәге хәрәкәтләр. Бик күп документлар җыярга кирәк, министрлыкларның һәм, әлбәттә, Президент Путинның ризалыкларын алырга... Владимир Владимирович хәзер дә искә төшерә ул сөйләшүне: «Я помню, Минтимер Шарипович говорил, Вы только дайте добро, остальное мы все сами сделаем...» Башкалар гаҗәпләнә: Ничек сезнең республика шулай бар яктан алдынгы, ничек сез бөтенесен булдырасыз, дип. Күп нәрсәнең сере ышанычка, җаваплылыкка барып тоташа. Ялгыш та шик белдермәделәр, ышанып карадылар. Президент та: «Әйдә, шөгыльлән, Путин исеменә хат яз, мин барам», – диде шундук. Андый ышанычны аклар өчен ни генә эшләмәссең! Безнең бөтен нәрсә ныклап уйланылган иде. Эшне Рөстәм Нургалиевич алып бара иде бит. Ул гарант иде безнең өчен. Берәр нәрсә килеп чыкмый торган булса да, Рөстәм Нургалиевич барыбер берәр юлын табачак дия идек.

2003 елда Казанда мәктәп укучыларының беренче Бөтенроссия спартакиадасы узды. Ул Мәскәүдә үтәргә тиеш иде. Спорт министры Вячеслав Фетисов Лужков белән уртак тел таба алмаган: башкала мэры үткәрүдән баш тарткан. Шуннан алар безгә чыктылар. Ни база юк, ни кунакханәләр... 6 мең бала килде. Спорт белгечләре, җитәкчеләр күпме иде!.. Бу чара безгә зур сабак булды! Булдырганыбызны да күрделәр инде! Зур эшләр башкардык без! Абруебыз үсә башлады. Ә менә Универсиадага заявка бирәбез дигән сүз чыккач, Мәскәүләр кызып китә: без бирәбез, ди башлый. Федераль дәрәҗәдәге оешмаларда йөргәндә: «Сез нәрсә, Казан кайда да, Универсиада кайда?! Онытыгыз!» – диләр. Ләкин без әкренләп барыбер үзебезнекен иттек. Фетисов безнең якта булды, Илдар Гыйльметдинов Дәүләт Думасында депутатлар арасында эшләде... Заявканы тәки ясадык! FISUга җибәрдек! Һәм безнең арттан ук Мәскәүдән дә китә заявка! Аптырыйлар инде, руслар үзара килешә алмыйлар микәнни дип. Казаннымы, Мәскәүнеме сайларга? Мәскәү Мәскәү инде, ә Казанны белгән кеше дә юк! Шунысы бар: безнең заявка – Россия студентларының спорт берлегеннән, ә Мәскәүнеке мэр Лужков имзасы белән киткән. Мәскәү заявка бирә алмый, бу кагыйдәләргә туры килми, диләр. Әзерлек бара әкренләп. Без Универсиаданы Казанда уздыру өчен көрәшәбез. 2008 елда хоккей буенча яшьләр арасында Дөнья чемпионаты уздырдык. 2006 елда шуңа әзерлекне карарга Халыкара Хоккей федерациясе президенты Рене Фазель килде. Таныштык, аралаштык. Мин Универсиада буенча каядыр чит илгә очам, ул үзенә кайтып бара, самолетта аңа Универсиада уздырырга әзерләнәбез дип аңлатам. «Казанда үткәрү катлаулы бит. Әмма сез молодцы! Кыю идея! Сезгә кыюлыгыгыз өчен генә дә булышырлык!» – ди. Дөнья чемпионатында аңа ошады. «Мин – синең якта! Миңа таяна аласың!» – диде. Менә шулай үзебезнең тарафдарларны җыя башладык. 2007 елда Шамил Тарпищевка Халыкара Теннис федерациясе президенты Риччи Битти сөйләгән. Кайсыдыр Америка шәһәрендә МОК (Халыкара Олимпия комитеты) Конгрессына җыелганнар. Чирәмдәге хоккей Халыкара федерациясе Президенты Элван Бреда Вриесман Казаннан туп-туры шунда китеп барган иде. Хәл-әхвәл сорашканнар. «Мин Россиядә, Казанда булдым», – дигән ул. Тегесе: «Ә мин иртәгә очам Казанга!» – ди икән. «Марат, Казан дөньяның спорт үзәгенә әйләнә!» – диде Тарпищев. Бу бик югары бәя иде! 2008 елда инде Казанны рәсми төстә Универсиада-2013 башкаласы дип игълан иттеләр! Брюссель, андагы хәлиткеч мизгелләр, FISU президенты Джордж Киллианның, конвертны ачып, «Казан» дип игълан итүе, безнең шатлыкның шартлап ярылуы... Бу искиткеч иде!

2010 елны Россия командасы Канаданың Ванкуверында Олимпия уеннарында хурлыклы чыгыш ясады: өч кенә алтын медаль яулап, 11 нче урынга калды. Гомергә булганы юк иде мондый хәлнең! Федерацияләрдә, Олимпия комитетларында җитәкчеләрне җибәрә башладылар. Россия хөкүмәте вице-премьеры

Александр Жуковны Олимпия комитеты президенты итеп сайларга булдылар. Рөстәм Нургалиевич: «Жуков сине директор итеп эшкә чакыра, әйдә, бар. Татарстан кешесе Россия Олимпия комитеты директоры булса, безнең өчен дә дәрәҗә, мөмкинлекләр арта», – ди. Мин шунда эшли башладым..



ДУСЛАР Дуслар күп булмый ул. Минем шулай килеп чыкты: дусларым күршеләр дә, классташлар да иде. Төрле якка таралышып беттек. Еллар буе күрешмәсәк тә, авыр чакларда бер-беребезгә таяныч була аласыбызны алар да, мин дә беләм. Институттан берничә дустым калды. Заводта, комсомолда бергә эшләгән дуслар бар… Дамир Закиров, мәсәлән. Безнең дуслыкка 30 еллап инде. Хәзер ул минем штаб җитәкчесе. Күрәшчә үзе. СССР спорт мастеры. Юрист. Комсомолның өлкә комитетында эшләде. Компрессорлар заводында генераль директор урынбасары булды. Олимпия комитетына киткәч, аны да үз яныма чакырдым. Тагын бер дустым – Владимир Новиков. Хәзер Мәскәүдә ВСМ (Югары тизлекле магистраль) төзелешендә. Классташым Рафаэль Шәрәфиев – рәссам, ул салон кешесе, кыскасы… Виталий Хашев. Безнең койма аша гына иде өйләре. Журналист иде башта, хәзер йортлар төзеп йөри.



МӘХӘББӘТ Күзләр төшкән кызлар бар иде инде ул. Мәктәптә дә, спорт белән шөгыльләнгәндә дә чибәр, матур кызлар якынтирәдә күп иде. Авыр сулап, чәчәкләр эзләп йөргән чаклар булды. Ә Резеда безнең 9 нчы сыйныфка Киров районыннан күчеп килде. Ике ел бергә укыдык. Башта бернәрсә дә юк иде. Мәктәпне тәмамлап, имтиханнар тапшырып йөргәндә… нәрсәдер булды инде! Очкын кабынды! Ул күзгә ташлана торган кыз иде. Аны каратыр өченниләр генә эшләп бетмәдек. Мин Чутайдан бер кочак кыр чәчәкләре, ромашкалар җыеп килеп тә бүләк иттем әле! Тартып алдың, дип, үпкә белдерүчеләр дә булды. Очраша башладык. Ул – финанс-икътисад институтына, мин КАИга укырга кердем. Свердловск өлкәсенә стройотряд белән киткәч, Резедадан көн саен хатлар алам. Ул хатлар әле дә саклана миндә… Өйләнештек. Алай иртә өйләнмиләр инде, озакка түгел, диючеләр дә булды. Соңрак өйләнгәннәр инде аерылышып бетте, ә без 30 елдан артык инде бергә!



КУРКУ Курыккан бардыр, нишләп булмасын! Мин дә тере кеше ич! Кайвакыт төштә дә куркып уянасың әле! Бервакыт кызыбыз Лилия бик каты авырып китте. 4 яшь иде аңа. Куркып, үземне кая куярга белми бәргәләнеп йөргәнем әле дә исемдә. Иң беренче чиратта якыннарың, аларның сәламәтлеге өчен борчыласың, бәла-каза килмәгәе дип куркасың. Бөтен кеше шундыйдыр инде.

Юк, Эльбруска менгәндә курыкмадым анысы. Алдан ук әйтеп киттем: «Егетләр, ничек менгерәсез, анысы сезнең эш, ләкин мин тау башында булырга тиеш!» Ләкин ник ризалык бирдем икән дигән уйлар да килде. Кабардин-Балкар Республикасыннан коллегалар Сабантуйга килгән иде. «Үзен чын ир-егет санаган кеше Эльбруска менәргә тиеш», – дип инандырдылар. Кызып китеп, тәкъдимнәренә мин дә кушылдым. Мин – спорт, яшьләр эшләре министры – ничек инде чын ир-егет булмыйм, ди! Тауга күтәрелгәндә үкендем инде үкенүен, чөнки 11 сәгать буе тауга менеп төшү бер дә җиңел түгел иде. Ләкин чигенеп булмый! 16 кеше чыгып киткән идек, өчәү генә менеп җиттек. Берсе – заманында Эверестны буйсындырган югары дәрәҗәдәге профессионал инструктор, икенчесе – Эльбрус буе районы башлыгы һәм мин. Район башлыгының да беренче генә менүе икән!



АКЧА Бик күп акча булса-а-а?!.. Бик күп акча булса – якыннарыма бирер идем. Аннары үземнең берничә проектым, хыялларым бар. Шуларны тормышка ашырыр идем. Эш белән бәйле алар. Иҗади хыяллар да бар… Тагын…Ике әйбер эшләр идем. Беркөн генә уйлап утырдым әле… Яшь гаиләләргә фатир төзү программасы оештырыр идем. Шуңа акча кертер идем. Ул аннары үзе җитештерә, үзе өлгертә торган программа булыр иде. Чөнки дәүләт акча бирми аңа, кредит алып булмый… Авыру, ятим балалар бик күп. Шуларга булышыр идем.



БАЛАЛАР Бердәнбер кызыбыз Лилия – горурлыгыбыз. 90 нчы елларда татар гимназияләре ачыла башлады. 4 нче класста аны 2 нче татар гимназиясенә укырга җибәрдек. Инглиз телен тирәнтен үзләштерү өчен 9 нчы класста Лобачевский исемендәге лицейга укырга керде. Әнисе белән анкеталарның нәтиҗәләрен белешергә баргач, «Тормышта кумирың кем?» – дип сораганнар. Күбесе танылган артистларны, спортчыларны атый икән. Ә Лилия: «Әти!» – дип җавап биргән. Резеданың бик күңеле булган инде! Күзләре яшьләнеп кайтып керде! Лилия Казан университетының юрфагын тәмамлады. Универсиада эпопеясе башланган чорлар. Шунда мин 2008 елда Казаннан Брюссельгә студентлар марафонын уйлап чыгардым. Бөтен җирдә сөйлим, аңлатам. Хуплыйлар. Ләкин беркем дә оештырырга алынмый. Чөнки тәҗрибә юк. Ил чикләрен узарга, студентларны урнаштырырга, митинглар үткәрергә, Казанны таныттырга кирәк. Бер кешегә тапшырып карыйм, икенчесенә… Чит илләр белән андый элемтәләр юк, диләр. Шуннан Лилиягә тапшырдым бу эшне. Чөнки ул бик актив, үзсүзле, үҗәт, җаваплы, мин-минлек юк аңарда… Флешмобны ул оештырды! Волонтерлар департаментын оештыручы да, аның беренче директоры да – ул. Аннары укыту үзәген җитәкләде. Ә инде Универсиада вакытында FISU аны үзенә эшкә чакырды. Хәзер дә FISUда эшли, Лозаннада…



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Күптөрле планнар, идеяләр бар башта – шуларны тормышка ашырасы, оныкларны күреп, аларны үстерешәсе килә. Нинди кеше икәнемне башкалар әйтер. Минем белән җиңел түгел. Катлаулы дип тә әйтә алмыйм үземне. Һәрхәлдә, уртак тел табып була минем белән.

PRESSA.RU













Реклама хокукында

ДҮРТ МИНУТ

– СЕЗ УЛ ДҮРТ МИНУТНЫҢ НИЧЕК ОЗАК ИКӘНЕН БЕЛСӘГЕЗ ИДЕ?!

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Алинаның болай әйтүенә башта аптырап калам. Белмим, дүрт минутны күп дию... Хәер, секундлар хәл иткәндә бит бу!

– Алышта безгә шуның кадәр вакыт бирелә. Чиста вакыт. Хөкемдарның теге яки бу сәбәп белән, сыбызгы сызгыртып безне көрәштән туктатмаган чагын кертмичә. Шуңа кайчак дүрт минут шактый озакка сузыла ул. Алҗыта! Келәмне ташлап чыгасы һәм авасы килә, әмма түзәсең, ахырга кадәр көрәшәсең.

Алинәнең кәефе юк. Аның, гомумән, минем белән сөйләшәсе килми. «Бүгенге җиңелү – иң авыр җиңелү булды...» – ди ул. Аңлыйм, алышның башыннан гел җиңеп килгән кызны, иң ахыргы минутта көндәше аркага салды бит. Шулай, келәмдә чакта барысын да секундлар хәл итә... «Үзем гаепле, – дип сүзен дәвам итә Алинә Смирнова. – Җиңүгә бер генә адым калды дип, сизгерлегемне югалттым. Көндәшем көчле кыз иде...» «Республика буенча икенче урынны алу – әйбәт нәтиҗә!» – дип юатуымны ул ишетми дә.

Келәмдә – кызлар... Бу күренеш, яшермим, минем үземә сәеррәк тоела. Мәйдан, көрәш – ир-атлар өчен дип күнегелгән. Билбау көрәше – бөтен дөнья халыкларының көрәш элементларын үзенә туплаган. Аны үзара «мишәр көрәше» дип тә атыйлар. Татарча көрәштән аермалы буларак, анда хәтта аяк белән көрәшү дә рөхсәт ителә. Көндәшеңне ничек телисең шулай – аяк чалып, күтәреп, ябышып егып аркага салырга ярый. Аяктан егу – чиста җиңү булып санала. Һәм менә ни гаҗәп – кызлар көрәшнең шушы төрен үз иткән! «Көрәшү – кызлар эшемени?!» диючеләрдә эшләре юк!

Билбау көрәше буенча республика беренчелеге өчен Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында узган ярышта да кызлар байтак иде. Йөз дә ун катнашучының – утызы! Әлки, Алексеевский, Нурлат, Түбән Кама, Чаллы кызлары келәмгә чыгарга чират көтә... Күренеп тора: ярышка очраклы гына эләгүчеләр юк монда, барысы да әзерлекле. Матурлык бәйгесеннән шактый аерыла бу чират: беренчесендә кызлар өстендә озын затлы күлмәкләр булса, мондагылар ак чалбар, зәңгәр яки яшел төстәге кыска киң күлмәк кигәннәр, келәмгә чыгар алдыннан шул күлмәк өстеннән билбау бәйлиләр. Бу бәйге-ярышта кызларның ихтыяр көче, чыдамлыгы, көч-куәте сынала. Гәүдә авырлыгын алар башкалардан өстенлек дип тә санамыймы икән әле?! Ә шулай да... Кыз баланың матур, нәфис, сылу, зифа булырга теләмәгәне юктыр инде аның. Билбау көрәшен яшәү рәвеше итеп алган бу кызларны келәмгә нәрсә тарта? «Җаны телəгән – җылан ите ашаган», ди безнең халык. Бу да шул очракмы?

Алар Татарстанны данлый



Хәбир ХӘБИБУЛЛИН.
Билбау көрәше буенча Халыкара федерациянең генераль секретаре, Татарстанның билбау көрәше федерациясе башкарма директоры.

– Билбау көрәшендә кызлар әле күптән түгел генә катнаша башлады. Мамадыш кызлары бик көчле бүген, чаллылар, зәйләр... Әлки кызлары бик матур көрәшә башлады. Әле яңа гына Рязаньнан, Россия беренчелегенә уздырылган ярыштан, Регина Нуретдинова – беренче, Регина Нуриәхмәтова – икенче, Нурия Шаһиева өченче урынны алып кайтты.

Традицияләр күп нәрсәне билгеле бер кысаларга куя. Мәсәлән, тормышта хатын-кызның ролен дә. Ул аш-су тирәсендә кайнашырга, бала табарга, бала тәрбияләргә тиеш дибез без. Кемдер бу чикне чыкса, аны тәнкыйтьлибез, бу адымын ошатмаган булабыз. Ә кеше яңалыкка омтылса, үзен башка өлкәдә сынап карарга теләсә? Егетләрнең аш-су пешерүен, чәч кисүче булып эшләвен гайре табигый күренеш дип санамыйбыз лабаса. Ә нигә бокска яки көрәшкә кереп киткән кызларга шулай карыйбыз? Чынлыкта, алар бик күп тә түгел бит. Берничә дистә кызның чынлап торып көрәш белән шөгыльләнүе генофондыбызга да, халкыбызның гореф-гадәтләренә дә зур тәэсир ясамас. Шуңа күрә бу күренешкә шикләнеп карарга кирәкми дип уйлыйм. Табигатьләре шуны сорый икән, көчләреннән килә икән, нигә без кызларны тыярга тиеш?! Җиңүләре белән алар да Татарстанның данын күтәрә, шулай булгач, нигә андый мөмкинлек бирмәскә? Әйе, келәмдә имгәнүләр булып тора, әмма кызлар моны белеп бара бу адымга. Аннан әллә көрәшмәгән хатын-кызның умыртка баганасы, тезләре аз авыртамы?

Билбау көрәше буенча Дөнья чемпионатларында алтын пьедесталга татарстанлылар 34 мәртәбә күтәрелде. Шуларның бишесе – кызлар. Екатерина Гыйниятуллина, Регина Салихова, Елена Михайлова... Алена Калугина Дөнья чемпионы исеменә күптән түгел лаек булды. Зәмирә Әхмәдованың әтисе хәрби кеше, алар бер шәһәрдән икенчесенә күченеп йөргәннән соң, Чаллыга кайтып урнаштылар. Зәмирә балачактан көрәште. Дөнья чемпионы исемен ул үткән ел алды.

Билбау көрәше буенча Дөнья чемпионаты быел Татарстанда, Чаллы шәһәрендә узачак. 27-30 октябрь көннәрендә Чаллы үзендә өч йөздән артык көрәшчене кабул итәчәк. Әзерләнәбез! Көрәшче кызлар алтын пьедесталга күтәрелүчеләр арасында да булыр!

Кызларга келәмдә шул ук таләпләр куела, җиңеллекләр каралмаган. Ләкин алар бит ир-атлар белән түгел, үзара көрәшә. Вакыт та аларга шуның кадәр бирелә – дүрт минут. Шул ук алымнарны кулланалар. Егетләрдән бөтенләй аерылмыйлар, дисәм... Исемә төште әле, бер көрәшче кыз, келәмгә чыккач, нигәдер, көндәшенең гел колагын тешли иде.

Бер булганнан бар да була



Эльвира ФӘТТАХОВА.
Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумы директоры.

– Көрәшче кызлар башкалардан җитди булулары, холыкларының ныклыгы белән аерылып тора. Әйтик, менә безнең Альбина Шәмсетдинова. Ветеринарлар төркемендә укый ул. Чаллы кызы. «Бишле»дән түбән билге алганы юк. Узган ел рус теле буенча республика олимпиадасында беренче урынны яулады. Кулыннан китап төшми. Саксофонда уйный. Җәен үзләрендә ипподромда эшли, атлар бик ярата. Смирнова Алинаны исә көрәш белән шөгыльләнә димәссең дә, шундый йомшак басып йөри... Техникумны кызыл диплом белән тәмамлар дип көтәбез. Җырлый, техникумда узган чараларны алып бара.

PRESSA.RU

Тормыш – көрәш...



Рәмзил БӘДРИЕВ,
Минзәлә авыл хуҗалыгы
техникумы укытучысы, тренер.

– Билбау көрәше белән безнең Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында 40-50 бала шөгыльләнә. Кызлар да байтак йөри. Арада йә әтисе, йә әнисе булмаган ятимнәр шактый. Ни гаҗәп, андыйлар уңышка күбрәк ирешә. Тормышта сынауны күп узарга туры киләчәк әле аларга. Киләчәктә үзләрен тагын кайда күрсәтә алырлар, билгесез. Ә монда алар дөнья күләмендә беренче урыннарны яулый. Горурлык бит: Татарстанда көн саен кемдер чемпион булып тормый!

Атнасына биш көн буе спортзалда киләм җәелгән безнең. Мин шактый кырыс, таләпчән тренер: һәрберсенә максат куям – ким дигәндә районда чемпион калырга, республикада – призер. Әмма моңа ирешү өчен башта өч-дүрт ел шөгыльләнергә кирәк әле, аннары гына ниндидер нәтиҗәләргә ирешә башлыйсың.

Кыз бала – кыз бала инде. Мин алар белән педагог кына түгел, психолог та булырга тиеш. Җиңел димәс идем... Малайларга кычкырган кебек, кызларга тавыш күтәрә алмыйсың. Үпкәлиләр! (Дөрес, үҗәтләнеп көрәшеп китсен өчен кемгәдер махсус кычкырган чаклар да булгалый.) Үпкәләү – бер хәл, уза, әмма баланы кимсетергә ярамый – моны ул гафу итми, залга башка килми.

Киләмдә һәркемгә берүк таләпләр куела. Күнегүләр вакытында кызларга малайлар белән дә көрәшергә туры килә. «Үзеннән көчсезрәкне кем дә җиңә, тырышыгыз», – дим. Югыйсә йә бер урында туктап каласың, йә түбән төшәсең. «Билбау көрәше белән шөгыльләнергә телим», – дип килгән кызларның берсен дә кире бормыйбыз. 18 яшьләре тулгач, алга таба шөгыльләнергәме-юкмы икәнен дә алар үзләре хәл итә: кызларның кияүгә чыгасылары, бала табып, әни буласылары бар. Ә монда имгәнү куркынычы – адым саен.

Көрәштән китәргә җыенмыйм



Регина САЛИХОВА,
ике тапкыр Дөнья чемпионы.

– Билбау көрәше белән сигезенче класста укыганда, ундүрт яшемдә шөгыльләнә башладым. Тренерым әтием Равил булды. Мине ул тәрбияләде. Безнең гаиләдә барыбыз да спорт белән дус дисәм дә була. Энем дә бүген тренер булып эшли. Мин дә югары белемне физкультура буенча алдым – спорт мәктәбендә секция алып барам.

Кызларның күбесе, кияүгә чыккач, көрәштән китә, мин исә, утызга җитеп килсәм дә, андый уем юк. Ирем Илшат белән күршеләр булып үстек. Ул көрәшче түгел. Ләкин өйләнешкәннән соң да ярышларга йөрүемә сүз әйткәне юк. Күнегүләр вакытында теземне бик нык имгәтеп, операцияләр ясатырга туры килде. Аннан бала таптым. Шул тирәдә генә көрәшмичә тордым. Илшат көлеп: «Кара аны, аяксыз калсаң, өйгә кертмим!» – ди хәзер. Мин ярышларга киткәндә, кызымны әни алып кала. Шунысы гына авыр – андый вакытта Динәне бик сагынам... Аны тапкач: «Кызымны көрәштермәячәкмен!» – дигән идем. Нәфис гимнастикага бирермен дип хыялланып йөрдем. Хәзер карыйм: нинди гимнастика – аның гәүдә төзелешенә кадәр көрәшченеке! Минем белән тренировкага йөри, укучыларым арасында йөгереп, уйнап үсә.

Киләмдә көрәшкәндә төшкән фотоларым юк дисәм дә була. Ярыш барганда үземне фотога төшерүләрен, гомумән, яратмыйм, аны начар фалга юрыйм.

Алма агачыннан ерак төшми



Екатерина ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,
Дөнья чемпионы.

– Билбаулы көрәш белән шактый соң – 12 яшемдә генә мавыгып киттем. Ләкин аңарчы да спорттан ерак кеше түгел идем: Казанның Дәрвишләр бистәсендәге «Ракета» стадионында самбо белән шөгыльләндем. Билбаулы көрәшкә күчкәч, ике-өч ай күнегүләр ясауга, тренерыбыз безне ярышка алып китте. Беренче уңышлар күңелгә канат куйды. Дөнья чемпионы исемен мин Африкадан, Того дәүләтенең Ломе шәһәреннән алып кайттым. Көндәшем – Испаниядән килгән кыз иде.

Ирем Илдар белән дә безне көрәш таныштырды. (Көрәшче кызларның, гомумән, күбесе тормыш иптәшләрен көрәшчеләр арасында таба. Ахирәтләрем арасында да шактый андый очраклар.) Илдар Казанда узган Универсиадада билбаулы көрәш буенча чемпион калды. Ике балабыз үсә – Жасмин белән Эльдар. Алма агачыннан ничек ерак тәгәрәсен – улыбыз да, кызыбыз да инде бүген үк көрәшкә тартылалар.

Көрәш миңа нәрсә бирдеме? Холкыма ныклыктыр. Бүгенге көндә Теләчедә тикшерүче булып эшлим.

Көрәш – үзеңә ышанычны арттыра



Алина СМИРНОВА,
Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумының IV курс студенты, спорт мастерлыгына кандидат.

– Көрәш түгәрәгенә үземнән ике яшькә кечерәк энемне алып бардым башта. Өченче сыйныфта гына укый идем әле. Аларның шөгыльләнгәнен карап торып, үзем дә кызыксынып киттем. Түгәрәккә малайлар гына йөргәч, ике ел буе гел Аделнең дуслары белән көрәштем. Классташ малайлар ялгыш та кыерсытмады: куркалар иде миннән. Беренче тапкыр ярышта тренерым Рәмзил абый Бәдриев 5 нче класста укыганда гына катнаштырды. Ул чакта әни дә исән иде әле... Әби һәм бабай белән генә калгач: «Кызлар эше түгел бу!» – дип, алар мине көрәштән тыйды. Аркамны да имгәткән чак иде, китәргә туры килде. Техникумга укырга кергәч, күнегүләрне яңадан башладым. Әби хәзер дә бик риза түгел, әмма урыннар ала башлагач, азрак тынычландылар. Өйдә капчык белән нидер күтәрергә кирәк булган чакларда, миңа әйтәләр хәзер.

Көрәштә иң авыры нәрсәме? Әлбәттә, җиңелү... Үземне куркытмас өчен, келәмдәге кызларның ничек көрәшкәнен ярыш барганда карамаска тырышам. Билбауга тотынуга көндәшеңнең көчен болай да шунда ук сизәсең ул. Яраса да, беркайчан да көрәшкәндә аяк чалганым юк. Әмма үземне дә бер тапкыр да чалып ектырганым юк – тренер безне аякны качырып йөртергә өйрәтеп бетерде.

Тренировка вакытында тренер сине кем белән куя, шуның белән көрәшәсең. Малайлар, әлбәттә, безгә караганда көчлерәк. Рәмзил абый көчлеләр белән көрәшү – өйрәнер өчен кирәк ди. Ул безгә әти кебек тә. Кем белән дус икәнебезгә кадәр белеп тора, киңәш бирергә, ул егетнең сиңа пармы-түгелме икәнен дә әйтергә мөмкин.

Кызлар көрәштән төрлечә китә: кемдер имгәнә, авырый башлый (башны бәрүне санамасаң, зур имгәнүләр алганым юк үземнең), кемдер кияүгә чыга – ире рөхсәт итми. Егетләре: «Көрәшмә! – дип әйтүчеләр дә бар. Миңа да шулай дигәннәр иде... Спорт мастеры исемен алганчы көрәшәсем килә әле.

...Дүрт минут. Бер ярыш белән икенчесе, бер дүрт минут белән киләсесе арасында һәр көн саен берничә сәгатькә сузылган күнегүләр, бәрелү-имгәнүләр, күз яшьләре... Ярышка алып килгән юллар. Кабат дүрт минут һәм... җиңү шатлыгы! Кызларыбызга җиңүләр генә юлдаш булсын!

САБАНТУЙДА – ИСКЕ КУЛАТКЫДА...

Авыл Сабан туе нинди була? Тирәсендә халык түгәрәк рәвешендә тезелеп утырган мәйдан, яллары төсле тасмалар белән бизәп җигелгән атлар, үзе пешергән чәкчәк белән сыйлап йөрүче апалар, гармунга кушылып җыр сузучы абзыйлар, агач атка утырып ярышка чыккан малай-шалай... Иске Кулаткыда да нәкъ шулай ук булды, тик масштабы гына бер ун тапкырга зуррак иде. Бөтенроссия авыл Сабан туе булсын да! Колхоз рәисе урынына рәсми сүзне өлкә губернаторы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Сергей Морозов әйтте. Бәйрәмне уздырыруда ярдәм күрсәткәне өчен Татарстанга рәхмәт сүзләре җиткерде ул. Күрше авыл Сабан туенда бу урында колхоз рәисе алдынгы кыр эшчеләрен бүләкләгән булыр иде, ә Иске Кулаткыда бүләкләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзе тапшырды. Кемгә – Рәхмәт хаты, кемгә – медаль, ә җирле татар милли-мәдәни мохтариятенә исә микроавтобус эләкте. «Автобус бик кирәк иде, балаларыбыз да, өлкәннәребез дә төрле чараларга йөреп тора бит», – дип, шатлыгы белән уртаклашты мохтарият рәисе Наилә Рамазанова.

Күрше авыл Сабан туенда түбәтәй кигән танылган хоккейчы, РФ Дәүләт Думасы депутаты Владислав Третьякны, чып-чын никах туен уздырган парны, мәйдан уртасында ягылган мунчаны күрә алу икеле. Ә менә Иске Кулаткыда болар барысы да бар иде. Ягылган мунча дигәне үзебезнең Нурлат районы әзерләгән бүләк икән. «Бүрәнәләрне Нурлаттан китерттек, мунчаны һәм башка корылмаларны осталар бер айда салып чыкты. Иртәгә Сабан туе дигән көнне ягып, кереп тә чыктык. Шәп булган! Бүген дә яктык менә, кунаклар шаккатты, кереп тә карадылар», – дип сөйләде Нурлатлар.

Иске Кулаткы егете Илнур Сәйфуллин туй эчендә туй ясады: сөйгәне Юлия белән никах туен Бөтенроссия авыл Сабан туе көнне уздырды. Тагын кемнең гаилә кору бәйрәменә шушының кадәр кунак килгәне бар икән әле?!

Сабан туеның бизәге – көрәш. Пәһлеваннарның бил алышыр чагы җиткәч, халык, башка шөгылен куеп торып, мәйдан тирәсенәрәк елышты. Көрәшчеләргә көч биреп торыр, үзем чыккан булсаммы дип уфтанып алыр, соңыннан, Сабан туеның бөтен ямен күрдем, дип сөйләп йөрер өчен! Баш батырны тәкә генә түгел, Татарстан Президенты бүләк итеп биргән «Лада-Гранта» машинасы да көтеп тора бит әле! Менә хәлиткеч мизгел... һәм... Димитровград егете Сергей Павлик көндәшен аркасына сала. Ул – баш батыр! Тәкә дә, машина да Ульяновскида кала.

Мәйдан әкренләп таралыша. Киләсе елга кадәр, дип хушлашабыз. Киләсе елда Бөтенроссия авыл Сабан туе Пенза өлкәсенең Әләзән авылында үтәчәк. Очрашу урыны үзгәрсә дә, милли бәйрәмебезнең йөзе шул ук калачак.

Фәнзилә МОСТАФИНА



Фото: Алисә Сабирова

PRESSA.RU



Быелгы май ае ак чәчәкләр белән бергә Камал театрындагы премьера белән дә сөендерде. «Көтәм сине...» Пьесаның авторы Илгиз Зәйниев. Сәхнәгә куйган режиссеры да Илгиз Зәйниев! Автор һәм режиссер берлегендә үк интрига бар.

Асия ЮНЫСОВА









КҮЗЛӘРЕҢ НИНДИ?

Бардым, карадым, олы ләззәт алдым. Мин генә дә түгел, бәлки шыгрым тулы залдагы тамашачы да олы бер кинәнү, рәхәтлек, канәгатьлек кичерде. «Булган бу!», «Ниһаять!», «Туфан абый бар чагындагыча булып китте». Мин өзек-өзек ишетеп калган фикер төймәләре бу. Аларны тезсәң, бу премьера турында бербөтен дисбе хасил булыр иде.

Башта ук әйтеп куям: түгел!!! «Әниләр һәм бәбиләр» түгел бу! Ни кадәр генә сагынсагыз да, бу юлы Туфан Миңнуллинга сыенмагыз. Әйе, тема бер! Һәм шул гына. Туфан Миңнуллинның якты истәлегенә багышлап язылган бу әсәр һич тә «Әниләр һәм бәбиләр» түгел. «Әниләр һәм бәбиләр». «Ана! Нинди бөек исем. Нәрсә җитә ана булуга! шигарен алга куеп язылган гимн ул. Әсәрнең сюжеты исә бишек җырларына ай нурларын үреп тукылган гаҗәеп гүзәл тукыма. Анда Ана белән Бала бәйләнешләрына ир-ат халкы фәкать виртуаль рәвештә генә (сәхнә, бәлки, тәрәзә артында гына дияргәдер) якынайтыла. Ул спектакльдә Ана да, Бала да – изге. Һәм бу хакта бәрәү дә бәхәсләшми. Ә менә «Көтәм сине...» спектаклендә Ана белән Бала бәйләнешләрында нинди дер каршылыклар бар. Карындагы балалар бу дөньяга туарга ашыкмыйлар. Теләмиләр! Нигә, нилектән бу? Автор һәм режиссер бу хәлнең сәбәпләрен эзли. Дөрес җавапны табу, Анадан бигрәк, җәмгыять өчен кирәк. Чөнки балалар шушы җәмгыятькә, шушы Җир йөзенә, шушы Җиһанга туасылар бит!

Югыйсә спектакль бик тә лирик башланып китә. Сәхнә күгеннән тамашачылар хозурына шагыйранә сүзләр коела тора. «Күзкәйләрең синең нинди төстә икән...» дип хыяллана-хыяллана, Аналар бала көтә. Дөресрәге, алар бу дөньяга әллә туып тормаска микән дип, икеләнеп карында яткан җимешләрен ничек тә яшәтергә иде дигән уртак теләк утында яналар. Биш караватта – биш язмыш. Ике пәрдәле спектакльдә шул язмышларны «йөреп чыгарга» да, нәтиҗә ясап өлгерергә дә кирәк бит әле. Илгиз Зәйниев әсәрен «мелодраматик уйланулар» дип атаган. Ул язуга күзем төшкәнче мин дә аны үземчә «фәлсәфи драма» дип атаган идем. Чыннан да, спектакльдә фәлсәфә күп. Җиргә кеше булып туган кеше уйланырга тиеш инде ул. Бу Җиргә нигә килгәнеңне дә белмичә ничек китмәк кирәк!

Гинекология бүлегендә «сохранениедә» ятучы көмәнле хатыннарга, сабыйларын сакларга тырышудан кала, автор йөкләгән тагын бер бурычлары бар. Аларның

һәркайсы без яшәгән җәмгыятьнең бер җитмәгән җирен фаш итәргә бурычлы. Әлбәттә, япа-ялгыз гына түгел. Бәлки дөньяга туачак баланы бергә-бергә үстерергә тиешле «яртылары» белән... Монда мин «бергәләп» дип язып куярга тиеш идем. Тик әнә шул «бергәләп» дигән сүзнең мең дә бер төсмере бар.

Кызык та бу дөнья, кызык түгел дә. Әйе, спектакль каһарманнары барысы да парлы. Ләкин бу шартлы парлылык! Үз дуэтларын менә дигән итеп «яшәгән» Зәйнәп (Алсу Каюмова) белән Ирхан (Фәнис Сафин) гаиләсе өчен җан тыныч. Болар юк-бар белән баш катырмыйча гына, әрепләшә-килешә балаларын табарлар да, үстереп тә җиткерерләр. Үзенең «аңгыра» булуы белән юри генә килешкән Ирхан да «аңгыра башны» борып йөртерлек акылы булган «муен» Зәйнәп тә, җәмгыятькә бернинди дәгъва белдермичә, гади бәхеткә канәгатьләнеп яшәү әмәлен табарлар. Зәйнәп үзе әйтмешли, «аның токсикозы ерунда гына».

Аллаһы Тәгалә белән тату Саҗидә өчен дә борчылası юк. Ходайның һәр гамәленә риза ул. Бала төшү ачысын әүвәл нәкъ менә Саҗидә татыса да, аның иман ныклыгы, алдагы көненә ышанычы тамашачыга да йога.
Ләйсән Фәйзуллина тәкъдим иткән Саҗидә образы спектакльне җылытып, яктыртып торды бугай әле ул. Шатлыгын да, кайгысын да күтәрә белә торган Саҗидәне яратты тамашачы.

Фәлсәфи уйланулар үзәгендә калган Әминә (Гөлчәчәк Хәмәдинурова) – үзе бер табышмак. Аның пары Аяз (Эмиль Талипов) исә табышмак кына түгел, бәлки шул табышмакларны иҗат итеп торучы да. Бу икәүне авыртмаган башка тимер тарак эзләүчеләр дисәң дә дөрестер. Йә ни җитми боларга? Никахлы гаиләдә балалары туарга тора, мәхәббәтләре бар... Бар, әмма ышанычлары юк икән. Алар бер-берләренә һәм үз-үзләренә ышанмыйлар. Хәтта яралгыга җан иңдергән мәхәббәтләрен һаман саен шикләнү белән диңкетәләр. Яратам-яратмыйм! Кит! Ташлама! Шундый каршылыклар уртасында калган сабый яралгы нишләсен? Әлбәттә, бала төшә. Димәк, ышанмау, шикләнү, мәхәббәтне генә түгел, туасы җанны да һәлак итә. Автор эти булырга җыенган Аязны акыллы дивана итеп сурәтләгән. Машиналар юучы булып эшләүче фәлсәфә укытучысын Эмиль Талипов искиткеч итеп гәүдәләндерә алды. Күрегез әле сез аның тәгәрмәчле сумканы ялтыратып сөртеп, хатыны алдына тәгәрәтеп китерүен! Минут саен туфлиләрен ялтыратуын! Өендә сыңар оегын таба алмый йөдәгән ир димәссең. Педант! Һәм шул югары белемле философ күңеле уйнап торган, халәтенә күрә көйсезләнгән йөкле хатыны ишетергә теләгән бер җөмләне – «мин сиңа һичкайчан хыянәт итмәм», дигән гап-гади сүзләрне әйтә, ягъни үзенең тормыш принципларына каршы бара алмый. Бу очракта да педант! Әйтер ул кирәкле сүзләрне. Ләкин эш узган булыр. Үзләрен китапча тәгълиматлар үрнәгендә «ясаган» күпме адәмнәр бәхәсле принциплары хакына бәхетләреннән коры калалар.

Автор, гомумән, Аяз образына артыграк бурыч йөкләгән. Мәсәлән, гөнаһ теориясен дәлилләү өчен күгәрчен балалары белән булган рәхимсез эпизод та җитәр иде. «Манара – кое» фәлсәфәсен икенче бер әсәрдә файдалана алыр иде әле. Әйтик, Туфан Миңнуллинның «Сөяркә»сендәге кебегрәк итеп. Болай... фәлсәфә артык күпкә киткән, һәм монолог та озын булып чыккан.

Фәлсәфәне һәр уңайдан кора башласаң... Җәмгыять тәмам сырхау безнең. Хәтта без ул сырхау-чирләргә ияләшеп тә беткәнбез инде. Фахишә хатын Зәлидәнең (Нәфисә Хәйруллина) үзен шактый кыю тотуы берәүнең дә ачуын китерми. Аны гаепләргә тырышып караган бердәнбер кешенең – бишенче караватиясе Адиләнең дә «үз бүреге яна» булып чыкты. «Аның «фахишәләрне ник кертәләр бирегә?» дигән репликасына җавап көтелгәннән кискенрәк яңгырады. «Фахишәләрне генә түгел, бала сатып акча эшләүчеләрне дә кертәләр әле бирегә!»

Адилә – кыралак ана – коелып төште дип уйласагыз, ялгышасыз. Ул оялмый, һәм аның җавабы әзер. Ипотекага фатир алыр өчен, армиядән калыр өчен, җир кишәрлеге эләктерер өчен һәм тагын әлләниләр бәрабәренә бала тапкан хатыннардан бер ягы да ким түгел икән ләбаса аның! Ярый әле Зәйнәпнең талканы коры: «Алар үз балаларын үзләре үстерәләр!»

Кечкенә күләмле язмада бу олы фикерле спектакль уяткан, күңелне айкаган фикерләрне бәян итеп бетерү мөмкин түгел.

«Караватлар» тирәсендә генә йөреп, күрше урология бүлегеннән кергәли торган «кунак» – Арслан (Алмаз Сабирҗанов) читтә калмасын тагын. Менә кем ул чын философ! Сукырга суд юк дигәндәй, авторга үз әсәрен үзе куярга мәҗбүр иткән «крамола» фикерләр барысы да аның авызыннан әйтелә. Балаларның бу дөньяга нигә туарга теләмәвенең «сере» шул – игълан ителмәгән Өченче Бөтендөнья сугышының корбаны Арслан авызыннан ишетәбез. Бәгырь җимешләренең табутларда кайтканын күргән, ачы хәсрәт кичергән аналар берләшә калсалар, «нарожают еще!» дигән генералларның кикриге бик тиз шиңәр иде. Аналар балаларын бәхет өчен таба. Ә ул бәхеткә имин көннәр кирәк. Имин яшәеш урнашмый торып, пычранып беткән Җиребез нәҗестән арынмый торып, балалар туарга ашыкмас әле.

Спектакль үзе, гомумән, авторның гына түгел, композитор Эльмир Низамовның да, сәхнәгә куючы рәссам Геннадий Скомороховның да уңышы. Һәр караватөстенә эленгән карын-бишек символикасы гына да ни тора! Фантазиягә бай тамашачы дүрт караватка турыланган керү-чыгу порталларын да балаларның дөньяга килү юллары сыман фаразлады. Спектакльдә Эльмира Кәлимуллина җырлавыннан ләззәтләнергә теләгән идек. Күрәсең, җырларны спектакль барышында әледән-әле ишетелеп торган шигырьләр алыштыргандыр.

PRESSA.RU

Аның шигырьләреннән хисләр, фәлсәфә, дөньяны хатын-кыз булып кабул итү, яктылык, җылылык, гадилек саркыла. Кыска шигырьләренә тирән мәгънә салынган. Аларда – көтелмәгән чагыштырулар, яшендәй ялтырап киткән фикерләр, төсле җырлар... («Җанымдагы барлык каралыкны шигырь белән юып төшерәм», «Алсу күңел, әйдә, түгел!», «Фәлсәфә... Бар дөньясы әллә рәшә?!»)
Рәзинә Мөхияр иҗаты бу... Студентларының яраткан остазы, хезмәттәшләренең зирәк һәм акыллы сердәше, Чаллы дәүләт педагогика университеты доценты, филология фәннәре кандидаты Рәзинә Хәйбрахман кызы бу көннәрдә үзенең гомер бәйрәмен уздыра. Аның дөньясында бүген чәчәкләр, җыр, шигырь тантана итә.

Рәзинә МӨХИЯР

КҮҢЕЛ ТӘРӘЗӘМНЕ АЧТЫМ...

Гомер-елга

Ә гомерләр шундый кыска!
Алып булмый бит бурычка.

Үткән көннәр кире кайтмый,
Гомер-елга кире акмый.

Хәтер-сандык нидер саклый,
Күңел-вөждан үзен аклый.

Кайтыр идем бала чакка!
Язар идем аны акка...

* * *

Ак күлмәкле ромашкалар
Тирбәлә аланнарда.
Ромашкалар бер юаныч
Адашып калганнарга.

Аланнарны ап-ак иткән
Актан-ак ромашкалар.
Һәрберсенең күзләрендә
Кечкенә кояшкайлар.

Аклыкларны, пакьлекләрне
Ромашкалар яклыйлар.
Әйтерсең лә каралыктан
Бу дөньяны саклыйлар.

Ромашкаларга карыйм да
Җаннарымны агартам.
Әллә нигә, әллә нигә
Аклыкларны яратам.

Күңел тәрәзәсе

Күңел тәрәзәмне ачтым
Сак кына.
Күңел тәрәзәмне ачтым
Чак кына.
Тутырыплар ачсам, кунар
Тап кына.
Күңел түремдәге чәчәк
Ак кына.
Изге, серле уйлар белән
Бак кына.

Җәй башы

Табигатьтә
Җәйләр башы...
Җәйнең шулдыр
Йөзек кашы.

Җәй башында
Дөнья ямьле.
Чишмәләрнең
Суы тәмле.

Ямь-яшелдән
Урман-кырлар.
Күреклеләр,
Нык горурлар.

Ягымлырак
Кояш, Ай да.
Җан рәхәте
Җәйге айда.

«Кайда минем
Җәй башым?» – дип,
Кемдер кинәт
Уйлап куя.

Җәйге чиллә

Җәйге чиллә. Кызган бөтен дөнья:
Җире, ташы, агач, кояшы.
Бәргәләнә кеше бу тәмугта –
Әллә яңгыр булып коясы?!
Бу теләкне ничек тыясы?!
Яңгыр булып явыйм, тыймачы!

Үзем беләм

Бу язмышым
Миңа язган.
Авыр димим,
Җиңел димим –
Алга атлыйм.

Мин үтәсен –
Беркем үтмәс.
Мин күрәсен –
Беркем күрмәс –
Читләр белмәс.

Авыр чагын
Сабыр үтәм.
Җиңел чагын
Җырлап сүтәм –
Шатлык көтәм.

Миңа язган
Бу язмышым.
Авырлыгын,
Җиңеллеген
Үзем беләм.

Сагышланам

Шигырь яздырыйм диепме,
Сагыш чорный күңелне.
Сагышларым моңнар булып
Инде күпме түгелде?!

Сагышлана никтер күңел,
Әле җәй бит югыйсә.
Җанымның иң төпкеленә
Инде көзге җил исә.

Сагышланам ничә көннәр,
Сагышларым – сап-сары.
Сагышларым эретәме –
Эри күңелнең кары.

* * *

Җил-давылда алмагачның
Алмалары өзелә.
Күңелемнең җимешләре
Алма кебек җил-давылдан
Өлгереп тә, өлгерми дә,
Бер-бер артлы туктамыйча
Өзелә дә өзелә,
Шигъри юлга тезелә.

Синең тавыш

Синең тавыш
Колагымда,
Уйларымда
Һәм җанымда
Синең тавыш.

Тавышыңның
Бар төсмере,
Бар төсләре,
Бар хисләре
Миңа таныш.

Синең тавыш
Ягымлы да,
Кайчак кырыс,
Кайчак йомшак...
Күптән таныш...

Синең тавыш
Җырдай моңлы,
Айдай нурлы,
Үзе серле,
Әллә сагыш?!

Синең тавыш
Яңгыравык,
Чишмәдәй саф,
Колакка наз –
Үзе табыш.

Синең тавыш...
Күптән таныш:
Әле сагыш,
Әле табыш –
Синең тавыш.

Җаныңда сакларсың

Син мине эзләрсең,
Эзләрсең, күзләрсең
йөземне,
күземне,
сүземне,
эземне –
үземне.

Эзләрсең, күзләрсең...
Күзләрсең, тапмассың
йөземне,
күземне,
сүземне,
эземне –
үземне.

Күзләрсең, тапмассың,
Җаныңда сакларсың
йөземне,
күземне,
сүземне, эземне –
үземне.

Минем әле...

Минем әле бәхетләргә тулган
чагым,
Минем әле бәхетләргә чумган
чагым.

Минем әле бәхеткә юл ярган
чагым,
Минем әле бәхетемне язган чагым.

Минем әле күгем аязланган чагым,
Минем әле шундый нык назланган
чагым.

Минем әле бары язларымда чагым,
Минем бәхет кошым ярларымда
чагым.

Керим димә

Керим димә йөрәгемә
Моңнар булып,
Болай да моң тулы күзләрем.

Керим димә йөрәгемә
Сагыш булып,
Болай да сагышлы йөзләрем.

Керим димә йөрәгемә,
Кермә, кермә!
Болай да авыр бит көзләрен.

Алмалар исенә исердем

Алмалар исенә исердем,
Яшьлегем хисләрен кичердем.
Кулымда кып-кызыл алмалар:
Яшьлекне исемә төшердем.

Алмалар исенә исердем,
Яшьлекне уемнан кичердем.
Үзәкне ничә ел өздереп,
Алмадай ул ярны ник сөйдем?!

Алмалар исенә исердем,
Яшьлектә калган син бер серем.
Алмалар тәгәрәп киттеләр:
Язмышым сызыгын күчердем.

Кояш баешы

Кояш баешы –
Көннең сагышы.
Ай калка икән –
Төннең табышы.
Ай да, кояш та –
Гомер агышы.

Бер генә юл

Бер генә юл язып куйыйм
Дәфтәрем битләренә.
Чәчәк чиккән төсле булыр
Кулъяулык читләренә.

Чәчәк бәйләмнәре кебек
Шигырьдә һәрбер сүзем.
Шатлыклы, изге нур итеп
Кабул итәрләр үзен.

PRESSA.RU



Гүзәл ӘДһӘМ

ТАРТУ КӨЧЕ

(Хикәя)

Яз кояшы җебеткән көпшәк кар кисәк убылып китте дә, кыз тездән карга чумды, тигезлеген саклый алмыйча, җемелдәвек юрганга йөзе белән капланды. Кулындагы бавын әллә ныграк тартып җибәрдеме, тыңлаусыз чана юлдан читкә шуышты. Җылы нурдан эреп, йокымсырап киткән Зариф та, чанасы-ние белән янтаеп, кар өстенә ауды.

Асия каушады, өстендәге карны да кагып тормый, чанага ябышты.

Нишләргә?

Чананы турылап, басу юлына чыгарып бастырды, аннан йөзтүбән яткан Зарифка таба иелде. Егетне биленнән кочып, бар көченә үзенә тартты, кузгатып, чанага утыртырга азапланды. Ир-ат гәүдәсе шулай авыр була микәнни?

Кыз, йөрәксенеп, кабат егеткә ябышты: өстерәде, тартты, йолыкты, ничек кирәк алай егетне чанага утырту җаен тапты.

Яралы кулы җайсыз каерылдымы, Зариф ыңгырашып куйды. Юк, ыңгырашу түгел, ә шуңа охшаш ниндидер бер ым иде бу. Ир-егетнең әлеге халәттәге чарасызлык белән ризалаша алмавы, бәгырьдә кайнаган утлы ялкыннарны яшерергә омтылуы шуннан туган җан иңгерәве иде бу.

Күзләр шунда очрашты... Һәм шул мизгелдә үк бер-берсеннән качарга ашыкты... Аларның инде күптән күзгә-күз төбәп сөйләшкәне юк иде. Теге чактан... Кырык бердән бирле...

Ә хәзер әнә – урамда кырык бишнең язы. Март кояшы күзне чагылдыра, әллә ниләр вәгъдә иткәндәй, күңелне уйната... Йөрәк каядыр ашкына... Каядыр омтыла...

Госпитальдә дә Асия егетнең күзләренә карамаска тырышты, Зариф үзе дә гел читкә төбәлеп сөйләште, Тәзкирә турында да берни сорашмады. Ярый әле сорамады. Кыз аңа ни дип җавап бирер иде?

...Сугыш инде күп нәрсәне оныттырган иде. Укытучы егет Зарифның хәбәрсез югалуы турында хат килү, хатыны Тәзкирәнең районнан килгән вәкилгә кияүгә чыгып, Казанга китүе авылда инде әкренләп онытылып килә иде. Әйтерсең, болар барысы да үткән гасырдагы вакыйгалар булган да, сугыш сөременә уралып, күңелдән җуела башлаган.

Бары тик бер кеше – Асия өчен генә болар бик тә, бик тә яңа иде әле. Мәңге искермәс, хәтердән җуелмас хатирәләр булмыймыни? Кызның бәгырен тырнап, җан яраларын гел яңартып торган хатирәне онытырсың, бар!

...Зариф авылга сугыш башланырга бер ел кала кайтып төште. Бөтен халык шаккатты: егерме беренче елгы ачлыкта ятим калып, Казандагы балалар йортына озатылган сабый, ир-егеткә

әверелеп, авылына кайтсын әле! Авылдашларының исә институт бетергән кешене беренче генә күрүләре иде. Менә нинди була икән ул укыган кеше!

Мәчеттән үзгәртеп корылган мәктәпнең бер почмагына егет өчен бүлмә әтмәлләп бирделәр. Күрше классның зур миче бүлмәнең бер стенасы булып, ул кышны егет җылыга тиенде. Ашау-эчү ягы да әллә ни мәшәкать тудырмады, күрше авыллардан йөреп укучылар өчен оештырылган ашханәдә тамак ялгарга җай чыкты. Укытучылар да, балалар да яратты үзен. Ничә еллар директор йөген тарткан Галимулла шатланып туя алмады:

– Менә дигән кадр! Югары белемле! Минем кебек педучилище гына бетермәгән. Мәктәп тормышын өйрәнеп җитүгә, директор итәбез үзен!

Җитмәсә, егет гармунчы да икән. Кирәк чакта ялындырмый гына тальянын сыздырып җибәрә.

Шул кышта егет Тәзкирәгә гашыйк булды. Чибәр иде Тәзкирә. Авылның иң абруйлы кызы – колхоз идарәсендә хисапчы булып эшли. Идарәгә кемнең генә гозере төшмәс! Кызый үз дәрәҗәсен бик белә, вакыт-вакыт артыгын да белеп җибәрә бугай. Кыскасы, Тәзкирәгә укытучы егетнең игътибар итүе бик ошап куйды. Берәүдән дә оялмыйча, Тәзкирә белән Зариф авыл урамы буйлап култыклашып үттеләр. Ул чакта сала җирендә ир белән хатын да болай йөрми иде. Болар беренче булды, әмма аларны берәү дә гаепләмәде. Чөнки авылда Зарифны яраттылар, үз иттеләр. Аннары – ул бит Казанда институт бетергән егет! Шәһәр кешесенә бар да килешә! Иптәш кызлары Тәзкирәгә кызыгалар, аның бәхетеннән көнләшәләр иде.

Шул кышта авыл яшьләре клубта спектакль куярга булды. Нәрсә куйсыннар инде, билгеле, «Галиябану»ны! Хәлил белән Галиябануны уйнарга менә дигән артистлар да бар. Зариф гармунын сыздырып җибәрсәме? Ә Тәзкирәнең чибәрлеге – коеп куйган Галиябану инде менә! Кызганычка каршы, Тәзкирәсе җырлый белми икән. Тегеләй дә, болай да өйрәтеп карады «Хәлил» үзенең «Галиябануын»... Тик, булмагач, булмый икән ул...

Елап-ярсып, клубтан пырылдап чыгып чапты Тәзкирә. Шул кичтә егет белән кыз беренче тапкыр ачуланыштылар. Зарифның:

– Алайса, ячы карчык булып уйна, син аны булдырасың! – дигән сүзенә Тәзкирә үлә язды:

– Нәрс-ә-ә-ә! Ячы карчык булыпмы? Минме!

...Тамаша башланыр алдыннан сәхнә артына директор Галимулла килеп керде.

– Йә, ничек? Бар нәрсәгез дә җитешме? – дип, яшьләрнең хәлен белеште.

«Артист»ларның төс-кыяфәтләрен тикшергәч, Зарифка карап:

– Хәлил кебек егеткә матуррак күлмәк кигерсәң дә ярыйсы икән, – дип куйды.

Моны исә яшьләр үзләре дә сизенгән иде, тик, нишлисең, авылда шуннан да шәбрәк күлмәк табылмады шул. Галимулла озак уйлап тормады, өстендәге ак күлмәген салып, егеткә тоттырды.

– Мә, ки!

Галиябануны Асия бик килештереп уйнады. Әллә ни чибәр булмаса да, күз-кашларын каралтып, иренбитләрен алсулаткач, бөтенләй үзгәрде кызый, карап туймаслык чибәркәйгә әйләнде дә куйды. Бүтәннәр дә:

– Мондый матур Галиябануны күргән юк иде, – дип тел шартлатты.

Тавышы бик матур иде шул Асиянең. «Сандугачтай өздерә» дип шундыйларга әйтәләрдер инде. Соңгы күренештә, Хәлилнең күкрәгенә капланып күз яшен түккәндә, бөтен клуб аңа кушылып үкседе.

Яшьләр бу кадәр уңышны көтмәгән иде. Күңелләре көр булып, шатлыктан шау-гөр килделәр, тик Тәзкирә генә клубка килмәгән булып чыкты...

Әле ул чакта да Асия Зарифка гашыйк түгел иде. Ничек булсын, ди! «Подручком» йөргән Тәзкирәсе бар бит!

Барысы да соңрак башланды. Директорның ак күлмәгенә «Галиябану» битендәге буяулар шактый бизәк салып өлгергән булып чыкты. Зариф күлмәкне өч-дүрт кат юып та, теге тапларны бетерә алмагач, Асиягә төбәлде. Дөресрәге, күлмәк юып маташканда, Асия аның ишеген үзе шакыды. Директор абыйсы пионервожатый кызны Зарифка йомыш белән җибәргән иде. Күлмәкне, бергәләп, биш-алты кабат юдылар, тик барыбер агарта алмагач, Асия аны кайнатып карарга булды.

Шикәр кебек ак күлмәкне егеткә тапшырганда, Асия аңа гашыйк иде инде.

– Галиябануың юсын! – дип, Тәзкирәнең күлмәкне йөзенә атуын Зариф кызга әйтеп тормаган иде.

Асия исә гыйшкын берәүгә дә сиздермәде, эчтән генә янды, эчтән генә көйде кыз, шулай да теге күлмәк ике арага дуслык күперен салып өлгергән иде. Тик дуслык кына шул... Кыз төннәр буе йоклый алмый борсалана:

– Нинди бәхетле бу Тәзкирә!

...Укытучылар бүлмәсендә икәүдән-икәү генә газета чыгарып утырганда Зариф Асияне шаккаттырды.

– Минем кебек егеткә кияүгә чыгар идеңме син?

Асия бермәл тынсыз торды.

Егет газетага иелә төште:

– Ә менә Тәзкирә чыкмыйм ди!..

Кызга әллә нәрсә булды, кулындагы карандашы да, кәгазьгә төртелеп, «шырт» итеп сынды.

Зариф Асиядәге үзгәрешне сизмәде дә, егетнең үз хәле хәл иде:

– Йортсыз-җирсез, туган-тумачасыз бер килмешәккә чыгарга, син мине кем дип белдең ди.

Асиянең тез буыннары калтырады, егылып китмәс өчен өстәл читенә чытырдатып ябышты. Бары тик иреннәр генә сүзсез пышылдады:

«Мин чыгар идем... Чыгар идем!»

Билгеле, егет аның җан авазын ишетмәде, тырышыптырышып сызык сызуын белде.

Егетне Тәзкирәгә бәйләп торучы кылларның соң чиккәчә тартылуы һәм, бу киеренкелеккә чыдамый, берәм-берәм өзелә баруы әнә шул чакта башланмады микән?

...Ишек алдында кырык бернең җәе чәчәк атты. Уку елы тәмамлану уңаеннан урман аланында укытучылар

PRESSA.RU

өчен бәйрәм оештырдылар. Учак ягып, шулпа пешерделәр, кайнар көлгә бәрәңге тәгәрәттеләр, самавырлары гөжләп кайнап торды. Зариф тальянын тартып җибәрде, җыр-бию, уен-көлке гөр килде.

Көнел ачып туйгач, өлкәннәр ат арбасына утырып кайтырга чыкты. Яшь-җилкенчәк, җырлый-җырлый, тәпиләп кенә авылга юнәлде. Зариф белән Асия арткарак калды.

Ашыкмый гына сөйләшмичә атлады алар. Иңбашлары бер-берсенә орынып киткән мизгелләрдә, Асия, каушап, читкәрәк тартылды. Бөтен тәненең эсселе-суыклы булып чемердәп куюы кызны әллә нишләтә, бу халәтеннән ул үзе дә читенсенә, ояла иде. Егет кыюлана төште, кызның бармак очларыннан тотып, учына кысты...

Учы җылы иде Зарифның, шундый рәхәт, җылы уч...

– Бүген кич клубта кино була... «Цирк» дигән... Барасыңмы?

Кыз ишетелер-ишетелмәс пышылдады:

– Әйе-е-е...

– Мин сезгә керермен... Бергә барырбыз... Бәлки әле чәй дә эчертерсең...

Асиянең йөрәге «жу-у-у» итеп китте.

Казан кебек җирләрдә әллә шулай микән? Йа Хода! Өйгә үк керсә! Бигрәк оят! Тәрәзә пәрдәләрен чайкап эләргә кирәк! Кичкә кадәр өлгерәм үзе... Чәй дә эчертергә туры килсә? Ничек тә сер бирмәскә иде!

Кыз каушады, ни дип җавап бирергә белми тилмерде. Ә «юк!» диясе килми, бер дә килми!

...Ашыгып кайтты да пыр тузып җыештырына башлады. Югыйсә өйләре болай да «ялт» иткән чиста иде. Тәрәзәгә кетер ак пәрдәләр эленеп, идән-сәкеләр кырып юылды. Самавыр да әллә кайчаннан бирле җырлап утыра. Иң матур күлмәген киеп, көзге каршына килде.

«Сөйгәненне көтү» дигән бик ләззәтле дә, газаплы да халәт башланды.

Инде караңгы төшеп, күктә йолдызлар кабынгач та көтте әле ул. Клубтагы кино тавышы монда кадәр ишетелеп торды, әллә нинди таныш түгел матур җыр ачык тәрәзәдән өйгә агылды:

Я другой такой страны не знаю-ю-ю...

Где так вольно дышит челове-е-е-к...

Җыр тынды, халык әкренләп өйләренә таралды...

Түбән очта ук (әллә Тәзкирәләр өе тирәсендә инде?) тальян аваз салды. Болай итеп бары тик Зариф кына уйный белә иде...

Иртәгәсен әнисе урамнан яңа хәбәр ияртеп керде:

– Укытучы Зариф өйләнә икән бит. Иртәгә Тәзкирәне сорарга төшә, ди... Тәзкирәнең әнисе чишмә янында сөйләп торды: «Нык хуҗалыклы, баерак кешегә бирәсебез килгән иде дә, «җаны теләгән – җылан ите ашаган, диләр»...

Асия өнсез калды.

Асия белән Зарифның урамда җитәкләшеп йөрүе турындагы хәбәрнең Тәзкирәгә «чыбыксыз телефон» аша бик тиз килеп ирешүен кыз белми иде.

Ишетүе булган, Тәзкирә Зарифның мәктәптәге теге бүлмәсенә чапкан, ди. Килеп тә кергән, егетнең муенына да сарылган, ди. Яратам, дидең бит! Мин сиңа кияүгә чыгам! Өйлән миңа, дигән ди!

Монысын, «чыш-пыш» итеп, колактан-колакка гына сөйләделәр. Күпмесе дөрес, кайсысы ялган булгандыр – белгән юк! Чыны шул: егерме беренче июнь көнне яшьләр авыл советына барып язылышып та куйдылар.

Икенче көнне килеп ирешкән сугыш хәбәре туй мәшәкатьләрен бик тиз оныттырды. Бер атна үтәр-үтмәс, Тәзкирә дә ирен сугышка озатты...

Сугыш авылны үзгәртте. Үзен дә, кешеләрен дә, уй-фикерләрен, хыялларын да әллә нишләтеп бетерде. Үзгәрмәгән бары бер генә нәрсә калды – Асиянең мәхәббәте.

Кырык бернең августында фронттагылар турында беренче хәбәр килеп иреште. Иң беренчесе – Зариф турында иде... «Хәбәрсез югалды» дигән язу күпләрне аптыраушта калдырды.

«Хәбәрсез югалды»! Ни дигән сүз була соң бу? Кеше югала микәнни? Әллә хат язалмый дигәнне аңлатамы? Үлде димәгән ич, исәндер бит», – дип баш ваттылар.

Соңрак мондый хатлар ешайды. Инде берәү дә гаҗәпләнми башлады. Тагын кем турында «кара кәгазь» килер икән дип, шомлана-шомлана куркып көттеләр.

Тәзкирә исә, колхозга килеп йөргән «уполномоченный» егеткә кияүгә чыгып, Казанга ук китеп барды. Аны берәү дә гаепләмәде. «Хаты-хәбәре юк, үлүе хак булды, ахры», – дип, Зарифны кызганучылар күп булды. Тәзкирә ишек-тәрәзәсенә такта кадаклады. «Әтиәнисен дә сугыш алган кызның бәхете бар икән, нинди егетне эләктерде бит», – дип, көнләшүчеләр дә табылды әле.

Асияне пионервожатый гына димәделәр, ир укытучылар фронтка киткән саен, яңа дәрес өя тордылар. Укыта-укыта, үзе дә остара барды, балалар белән бергәләп, үзе дә өйрәнде.

Инде сугыш бетәр дигән өметләр уянып килгәндә, Тәзкирә исеменә бер хат килеп төште. Хатны иясенә тапшырырга кирәк иде, чөнки конвертындагы кара пичәте, әллә ничек сискәндереп, шуңа ишарә итеп тора. Әмма Тәзкирәнең шул китүдән авылга кайтып күренгәне дә юк. Сораша-белешә торгач, ачыкланды тагын: ире хәзер бик зур түрә икән, ике катлы зур йортның болын кебек бай фатирында яшиләр, ди. Ниндидер йомышы төшеп Казанга баргач, персидәтел Сафаның Тәзкирәләргә кергәне бар булып чыкты. Керү генәме! Тәзкирә язып биргән телефон номеры күлмәк кесәсендә һаман йөри икән.

Теге кәгазьне табып, идарәдәге коммутатор аша Казанга шалтыраттылар. Тиктомалдан, бер хат өчен генә Казан тикле Казанга чыгып чапмассың бит!

– Конвертын ерт та, хатын кычкырып укы! – диде чыбыкның теге очындагы Тәзкирә тавышы.

Персидәтел Сафа, күз күрмәүдән зарланып, хатны идарәгә килеп кергән Асиягә төртте. Хат рус телендә язылган иде. Асия күзләрен генә йөгертеп чыкты да, бугазына нәрсәдер килеп бөялүдән, бермәл тын алалмый, сулышы буылып торды.



Рәсем: Наталья Васильева

– Исән! – диде. – Зариф исән икән! Госпитальдә, ди! Ампутация обеих ног, дигән...

Бу сүзнең мәгънәсен Асия аңламады.

– Ярасы зур, ахры... Военврач килеп алырга кушкан... Арча госпиталенә кайтарганнар, ди! Тәзкирә! Алло! Алло, дим! Тәзкирә! Ишетәсеңме мине?

Теге якта эндәшмәделәр: элемтә өзелгән иде.

Колхоз идарәсендәге хатын-кыз мышык-мышык килде.

– Исән, ди, бит! Менә бәхет! Миңа да шундый хат килсә икән!

Сугышның нәрсә икәнен белгән Сафа гына авыр сулап куйды:

– Да-а-а-а... Җиңел булмас егеткә яшәүләре... Ике аяксыз, ди, бит...

Асиянең тәннәре чымырдап китте. Кышын Арча вокзалында күргән аяксыз солдатны хәтерендә яңартып, кыз өстәлгә сыгылып төште.

Телефон исә тынып калган, Тәзкирәнең хаттагы хәбәрне ишетеп җиткермәве көн кебек ачык иде. Асия кат-кат шалтыратса да, Казан белән яңадан тоташтырмадылар.

Коммутатор кыз:

– Аптыратмагыз инде! Трубканы алмыйлар бит! – дип кычкыргач кына, уеннан кире кайтты ул.

– Эх, белми калды бит! Зарифның исәнлеген ишетмәде бит! – дип өзгәләнде бар хатын-кыз.

Бер мизгелгә барысы да, әллә ни әһәмияте булмаган нәрсәдәй, Тәзкирәнең инде бүтән кеше хатыны булуын истән үк чыгарып ыргыткан лабаса...

Персидәтел Сафа хатны бирергә, хәбәрне җиткерергә кирәк дигән фикергә килде.

– Әдрисе ансат кына иде, чукынмыш... Бауман урамында... кызыл чиркәү янындагы йорт... беренче кывартир... Нумиры истән чыккан, каһәрнең... Нишләмәк кирәк, мин үзем китәлмим... Иртәгә райкомда җыелыш... Бөтен ышаныч синдә, сеңлем... Арчага кадәр минем белән барырсың. Син инде Казанга баручы берәр пуезга эләгү җаен карарсың...

Персидәтел сүзе – закон.

...Эзләде, тапты, Тәзкирәне күрде. Озын ялтыравык халат кигән, корсагы түгәрәкләнеп килгән Тәзкирә үзенә охшаган да, охшамаган да иде. Сүзне кыска тотты:

– Киләсең калмаган. Телефоннан әйттең бит инде... Ни дим... Мин анда барып тормам инде...

– Ул сине көтә бит...

– Көтми. Ирем шалтыратты. Менә шул: мин Зарифка сиңа үч итеп кенә чыктым!

Олы авыр ишек «дык» итеп ябылды.

...Асия Арчага кайтучы поездга утыра алмады, төнне вокзалда үткәрде.

Бик озын, чиксез озын төн булды ул.

Иртәгәсен, Арчага кайтып җиткәндә, ялт итеп кояш чыккан, көн дә җылытып җибәргән иде. Асия башын күтәрде дә, кояшка таба йөзе белән борылып, чытырдатып күзләрен йомган килеш, бераз гына шулай басып торды. Йомык күз белән дә тоемлана алган ниндидер җылы яктылык рәхәт итеп битен сыпырды...

...Шул рәхәт яктылыкта коенып, Асия атлады да атлады. Чанадагы Зарифның сөйләшмәвенә дә әллә ни исе китмәде аның.

«Җанланыр, ул да тернәкләнеп китәр әле. Ничә еллар үткәч, туган авылына тартылып кайткан егет бит ул. Хәзер инде авылы аны бервакытта да ташламас».

Ә Арчадан авылга кадәрге ара әллә ни ерак та түгел – бары тик егерме чакрым гына...

PRESSA.RU

Саубуллашу вальсы

Ак алъяпкычларда ак канат,
Күңел оча, гүя акчарлак.
Ак канат иңнәрдә,
Җилфеди җилләрдә,
Күңел оча ерак җирләргә.

Аерылыр чак җитә, дусларым,
Сизелмәде ун ел узганы.
Хуш, мәктәп, үз күрдең,
Яшәргә көч бирдең,
Канат куеп безне үстердең.

Алда юллар – кайсын сайларга,
Юллар чакыра әллә кайларга, –
Океаннар айкарга,
Очарга айларга,
Тормыш дәрьясында кайнарга...

Алъяпкычың, дустым, ак икән,
Ак булса да, салыр чак җиткән;
Хыяллар – ак җилкән,
Кузгалырбыз иртән,
Ерак юлга чыгар чак җиткән.



Асия МАЛИКОВА



С. Сөләйманова Аскар авылы укучылары белән. 1950 ел.

ЮЛЛАР ЧАКЫРА...

Майның соңгы көннәре иде. Алмагачлар шау чәчәктә. Тирә-юньгә сирень исе таралган. Күңелдә нindидер рәхәтлек, ашкыну!.. Шунда автобус тәрәзәсеннән ак алъяпкычлы кызларны күреп алдым. Үзләре шундый матурлар! Кулларында – чәчәк бәйләмнәре. Тукта, бүген ничәсе соң әле? Мәктәпләрдә соңгы кыңгырау бәйрәме икән бит!

«Ак алъяпкычларда ак канат,
Күңел оча, гуя акчарлак», – дип көйли башлаганымны сизми дә калдым. Җил-җил атлап баручы бу кызлар күңелемне тәмам кузгатып җибәрде. «Саубуллашу вальсы» турында берсеннән-берсе кадерле хатирәләр искә төште...

Бу җырны туганнан бирле беләм кебек. Без яшь чакта радиодан җырланган җыр икенче көн авыл яшьләре «репертуары»на керсә, бик җылы кабул ителде дигән сүз. «Саубуллашу вальсы» белән дә шулайрак булган бугай.

Чыгарылыш кичәбездә аеруча дулкынланып җырладык аны. Дус кызларымның сагыш катнаш шатлыктан балкыган йөзләре гел күз алдында. Әниләре теккән алъяпкычлары да бик килешле иде...

Ә җырның сүзләре дә, көе дә халәтебезгә шулкадәр туры килә! Мондый сүзләрне бары тик мәктәп тормышында кайнап яшәүче укытучы гына яза аладыр дим. Соңрак кына аңладым: аларны, чыннан да, укытучы язган икән бит. Һәм укытучының да нindие әле! Аның үз сүзләре белән әйтсәк, «мәктәп җене кагылганы», «балалар белән саташып яши торганы»! Моның шулай икәнен аңлау өчен Башкортстанның Тәтешле һәм Әбҗәлил районнарында, Минзәлә шәһәре

мәктәпләрендә, Әлмәт нефть техникумында укыткан, шигъриятькә тормыш тәҗрибәсе туплап килгән шагыйрәнең хатларына мөрәҗәгать итү дә җитәдер, мөгаен:

«Мәктәптә эшләр беткәч, биек таудан чана шудык. Кемнәр белән диегез – бишенче классларым белән! Ат җигә торган олы чанага утырып. Монда үгез җигәләр. Мин, мөгаен, акылдан язамындыр. Белмим, кешеләрдә нинди тәэсир калдырды микән бу җүләрлегем. Башка җирдә булса, бу табигый күренеш саналыр иде. Ә биредә һәр адымыңны сагаеп атларга туры килә. Кәефем шәп: котырып биисем, җырлыйсым, өзлексез сөйләшәсем килә», – дип яза ул хатында.

1950 елда Уфа педагогика институтын тәмамлап Башкортстанның Аскар авылына тарих укытырга килгән Сәҗидә Сөләйманова булачак тормыш иптәше Әдип Маликовка әнә шулай яза. Укытучы кыз үзенең киләчәктә танылган татар шагыйрәсе булып китәсен башына да китерми әле ул чакта. Мәктәп, балалар дип җан атып йөри. «Саубуллашу вальсы»нда да аның балачак һәм яшьлек хатирәләре, педагогик күзәтүләре, балаларның эчке кичерешләрен сизү һәм тою чагылып китә.

Шагыйрә Сәҗидә Сөләйманованы беренче булып авылдашым, Казан дәүләт мәдәният институты студенты Шамил абый Кашапов ачты миңа. Ул аның «Туй җыры» шигыренә көй язган иде! Шуннан башланды да инде Сәҗидә апа иҗаты белән кызыксынуым. Кызыксыну гына булдымы икән әле ул?! Шигырьләрен укыган саен укыйсы килә... Һәр юлы артында әллә нинди серләр яшерелгән кебек тоела. Шулар тәэсирендә үзем дә шигырьләр яза башлыйм... Аның шигырьләре миңа каләм тибрәтергә дә, күпмедер вакыттан соң шигырьләр язудан туктарга дә этәргеч бирде бугай. Яшьлек максимализмы булгандыр инде: Сәҗидә ападан соң килгән һәр шагыйрь шигъриятькә, һичшиксез, нindидер яңалык алып килергә, яңа сүз әйтергә тиеш дип саный идем мин. Бераздан мин дә, Сәҗидә апа кебек, укытучы хезмәтен сайлыйм...

Мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укытучысы, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән елларымда «Саубуллашу вальсы»н балалар белән җырлый идек. Бу җырны чыгарылыш укучылары җырлаганда, күңелем тулып, күз яшьләремне яшерергә тырышуларым әле дә хәтеремдә.

Җырны Сәҗидә Сөләйманова үзе эшләгән мәктәптә чыгарылыш кичәләре өчен махсус язгандыр дип уйлый идем. Соңрак, аның гаиләсенә килен булып төшкәннән соң, шагыйрәнең иҗатташ дуслары һәм архив материаллары белән танышкач, үзем өчен җырның язылу тарихын ачыкладым. Аның сүзләрен Сәҗидә Сөләйманова 1964 елда Әлмәт радиокомитетында эшләгән чорда язган икән, ә көйгә салу өчен Мәсгут Имашевка 1966 елда биргән булырга тиеш. Мәсгут абыйга ул елларда Сәҗидә Сөләйманова белән бергә Әлмәт шәһәрендә оешмаларга исем кушу комиссиясендә эшләргә туры килә. «Сәҗидә апа шәһәрдәге язулар-атамалар татарча булсын әле дигән фикерләрне алга сөрә иде. Бервакыт «Восход» кинотеатры исемен «Татарстан»га әйләндердек. Кибет, оешма исемнәрен татарчалаштырдык», – дип искә ала ул.

Мәсгут абыйның Әлмәт музыка училищесы директоры булып эшләгән чагы. «Бервакыт Сәҗидә ханым минем кабинет ишеген шакыды. «Русларның балалар җырлый торган «Школьный вальс» дигән җыры бар, шундыйрак җыр язып булмас микән, Мәсгут? – ди. – Безнең мәктәптә укучы балаларыбызның җырларга җырлары юк бит... Уйлап кара әле, бәлки берәр нәрсә килеп чыгар, – дип, миңа үзе язган сүзләрне биреп калдырды», – дип искә ала ул. «Сәҗидә апа калдырган сүзләрне укып карадым. Алар үзләре үк җырлап тора сыман. Көе дә тиз язылды. Мәктәп балаларына тыңлатып карарга булдык. Үтенеч белән Иске Әлмәттәге 1 нче татар мәктәбе директоры Мирза Каюмовичка шалтыраттык. Ул бик теләп риза булды. Җырны баянчы белән өйрәнеп алдык та, Сәҗидә апа белән мәктәпкә барып, унынчыларга җырлап күрсәттек. Алкышларга күмделәр. Тагын, тагын җырладык», – ди ул.

Әлмәттән Казанга күчеп киткәч, Мәсгут абый җырны радиога алып килә. Олег Лундстрем оештырып калдырган джаз-оркестрга кушылып җырлап, радио өчен яздыра. «Саубуллашу вальсы»н Татар дәүләт опера һәм балет театрының хатын-кызлар академик хоры да башкара, башкалар да... Җыр белән бәйле истәлекләре дә күп Мәсгут абыйның. Башкортстанның Чакмагыш районы Туйнаш авылына танылган журналист Вазыйх Исхаковны искә алырга баргач, укучылар белән очрашу үткәрәләр. «Вазыйх абый сезнең турыда күп сөйли иде, сезне җырчы дип әйтә иде. Берәр җырыгызны җырлагыз инде?» – дип үтенәләр. «Мәктәп турында бер җырым бар, «Саубуллашу вальсы» дип атала. Берәр кеше уйный алмасмы икән?» – дип әйтүе була – мәктәп баянчысы шундук уйнап та җибәрә. Баянга кушылып, беренче куплетны гына җырлый – бөтен зал күтәреп ала! «Тамакка төер тыгылды. Гаҗәеп хәл булды бу: алар җырлый, ә мин елап тик торам. «Эх, Сәҗидә апа үзе ишетсә иде», – дидем ул чакта. Әйтегез әле: кем барып өйрәткән аларга бу җырны? Шул-шул менә: җыр үзе барып җиткән. Сәҗидә ханымга бик рәхмәтле мин».

Мәсгут Имашев белән Сәҗидә Сөләйманованың уртак иҗат җимеше – «Саубуллашу вальсы» яңгырый башлаганга быел 50 ел! Кешеләрнең дә, җырларның да үз язмышлары... Шунысы сөендерә: соңгы елларда «Саубуллашу вальсы»н Мәсгут абый үзенең искиткеч талантлы оныгы Айрат Имашев белән бергә җырлый башлады. Димәк, җыр дәвам итә... Өзелмәсен, туктамасын ул!



Тулы вариантын сайтыбызның «Язмыш» сәхифәсендә укыгыз.

PRESSA.RU

БЕР ГАИЛӘДӘ ДҮРТ БУЫН БӘЙЛӘНЕШЕ – ШАКИРОВЛАР НӘСЕЛЕНЕҢ ГОРУРЛЫГЫ!

Гаймә апаның оныгы – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары Данис Шакиров: «Әбиебез – рухи таянычыбыз. Шакировлар нәселенең иң өлкәне, иң абруйлысы ул. Ә Шакировларның төпчекләре – минем улым Әмир һәм бертуган абыем Нәфиснең улы Ислам. Тормышта буыннар бәйләнешенең матур үрнәге булган бу күренеш нәселебезнең ныклы тамырлары, берегеп, дәвамлы булуын сөйли. Иң мөһиме: барыбыз да исән-имин булыйк, ә әбиемә озын гомер, күңел тынычлыгы телим!» – ди.



ГОМЕР ҺӘМ ТӘКЪДИР

Әтисе Мирзаһит сугышка киткәндә аңа нибары бер генә яшь була. Ул – әнисенең бердәнбер баласы. Балаларны ятим иткән, аналарны гомерлек тол калдырган сугыш Гаймә апаны да ятим итә.

Ул чорда колхозда көнне төнгә ялгап, иртән сәгать өчтә китеп, кичке уннарда гына эштән кайтканнар, кечкенә Гаймәнең әнисе Миңнур да шулай эшләгән. Әле лаеклы ялга чыккач та, түземсез йөрәк 65 яшенә кадәр амбарда эшләгән, билгеле, рәхәттән түгел, ә гаиләне ризык белән тәэмин итү максатыннан. Балаларны да ипи бирәләр, бүләк бирәләр, дип эшләткәннәр. Нәрсәгә көчләре җитә, барысын да эшләгән алар.

Ул заман балалары өчен «уенчыклар» бик үзгә булган. Гаймәнең, мәсәлән, озын, авыр чиләкләр белән су ташу өчен көянтәсе, кар көрәр өчен кечкенә көрәге, салам ташырга олы савыты һәм арбасы булган. Су ташу хатирәсен сөйләгәндә, күзләре яшьләнә Гаймә апаның. Алар суны тау астындагы чишмәдән ташыганнар. Озын-озын чиләкләр, буе зур булмагач, башкалар алдында сынатмас өчен, су буеннан алып менгәндә алар җиргә тимәсен дип, көянтәне куеп торган да, ике кулы

белән башта бер чиләкне яр өстенә менгергән, аннан икенчесен. Шулай итеп көненә бишәр көянтә су ташыган ул. «Анам өчен диеп тырыштым. Безнең авылда бер бабай бар иде, ул кардада эшләде. Шул бабай ятимәләр булганга кызганып булса кирәк, безгә арба ясап бирде, аңа дустым Әминә белән икәүләп бау иштек. Бу арба безгә зур ярдәм булды. Әле шул бабай безгә таң атканда кардага килергә куша иде, без ул биргән арбага читән чуман куеп бара идек тә, атлардан калган саламны өйгә алып кайта идек, аннан әниләр кайтканчы мичкә ягарга чыбыклар җыеп куя идек. Кыш көнендә иртүк торып, мәктәпкә киткәнче басуга барып, эскерт кырыйларындагы карны көрәп куеп, кичен шунда әниләр белән барып салам урлап кайтуларны да искә алсаң, шул вакытта ничек түздек икән дип уйлап куям».

«Сугыш беткән!» – дигән сөенечле хәбәр Гаймә белән әнисе Миңнур өчен зарыгып көткән мизгелләр була, әмма... «И-и, берзаман сугыштан кайта башладылар. Күрше егете дә кайтты, ул өйләнде, аннан соң икенче күрше кайтты, өйләнде. Ләкин әти кайтмады...» Менә шундый минутларда ана йөрәге ниләр кичерде икән?! Берәм-берәм сугыштан исән-сау калып кайткан ирләрне күргәч, үзеңнеке кайтмаячагын аңлап көтүләр, әтиле балаларга карап, кызыгып яшәгән көннәр, ирләре исән калганнарның тормыш авырлыгын урталай бүлеп тартулары, ә толларның әче күз яшьләренә төренгән төннәре һәм көннәре бик артта калса да, 80 яшенә кадәр газиз ирен көтә аның әнисе. «Хәтер» китабы дөнья күргәч, мин урын өстендә яткан 80 яшьлек әнием янына шул китапны күтәреп килдем дә: «Әни, карале, әти кайтты бит! Менә, тот әле бу китапны, әтинең исем-фамилиясе язылган монда», – дидем. «Әй, балам, бу китапта исемен күргәч, әтиеңнең инде кайтмаячагына тәгаен ышандым, аның Ватаныбыз өчен көрәшеп, батырларча һәлак булганын белдем, тыныч күңел белән китәм инде хәзер, рәхмәт», – диде дә, икәү, кочаклашып, озак еладык.

Ятимлек ачысын татып, авырлыкларга түзә-түзә, Гаймә 7 нче сыйныфны да тәмамлый. Шул ук елны колхоз эшенә чыга. 17 яшеннән авылларында депутат була ул. 8 ел депутат булып эшли, яшьлегенең иң кыен вакытлары шул елларга туры килә. «Берзаман районнан безнең авылга описька киләләр икән дигән хәбәр килеп төште. Ул чагында хуҗалыкта булган барлык мал-туарыңны җыеп алып китәләр. Күршеләребезнең берничә сарык асраганын беләм, инде нишләргә? Комиссия, барысын да күрсәт, диячәк. Кичтән әлеге күршеләремә кердем дә, иртән булачак хәлне аңлаттым. Мин аларга сарыкларын түргәрәк ябып куярга, комиссиягә исә өйдә мал-туар тотмыйбыз дип әйтергә куштым. Иртәгесен килеп төште теге комиссия, мине алып авыл буйлап киттеләр. Бик җитди үзләре, каты торалар. «Кемдә нинди мал-туар, кош корт бар, күрсәт», – диләр. Ул чактагы куркуларым! Шулай йөри торгач, безнең күршеләргә дә чират җитте бит. Кердек хәзер. «Нинди хайваннарыгыз бар?» – дип сорыйлар болардан. Мин ут йотып торам. «Мал-туарыбыз юк, аларны асрарга без инде өлкән кешеләр. Хәлебездән дә килмәс иде», – диләр. Минем күңелдә бер генә уй – комиссия чыгып киткәнче сарыклар кычкырмый торса гына ярар иде. Югыйсә... Ул күршеләрем әлеге ярдәмем өчен миңа гомер буе рәхмәт укыдылар».


Тормыш үз агымы белән дәвам итә. Гаймә апа да вакыты җиткәч, авылдаш егетенә кияүгә чыга. Тормыш иптәше Фирдәвес абый белән танышулары, кавышулары да кызык кына килеп чыга. Фермада эшләгән чагында алар бергәләп концертлар куеп йөриләр. Тырыш, ягымлы кызны егет күптән ошатып йөргән була. Әнә шулай бергә концерт куеп йөреп, тормыш сукмагыннан да бергә атлап китә алар. «Кияүгә чыгар алдыннан, мине сорарга килгәч, иптәшемә әйттем: «Мин әнине ташламадым, киләчәктә дә ташламаячакмын», – дидем. «Әниеңне беркайчан да ташламаячакбыз, бергә булыйк», – дигәч, күрше урамга гына чыгам бит, әнием янына көн дә килеп йөрермен дип, кияүгә чыгарга ризалык бирдем.

«Кошның матурлыгы төсенә карап, кешенең матурлыгы эшенә карап».

Фирдәвес абый өйләнешкәндәге вәгъдәсендә тора, авылның икенче очында яшәүче Миңнур апаны хөрмәтләп тәрбиялиләр, аның хәер-фатихасын алалар: «Аллаһка шөкер, әниемә озын гомер бирде, балалар тәрбияләгән кебек карадык аны». Ире белән бергә өч бала үстерәләр. Балалары да үзләре кебек тырыш була. Мәктәпне гел яхшы билгеләргә генә тәмамлыйлар. Ләкин язмыш сынавымы, әллә шулай язылган булганмы – 18 яшьлек төпчек уллары 1985 елны вафат була. 1993 елны 42 ел бергә гомер иткән Фирдәвес абый да бакыйлыкка күчә.


«Баладан бәхетең булса, карт көнеңдә яшь итәр», – дигән борынгылар. Гаймә апаның күңеле, йөрәге яшь. «Өй янындагы бакчага чыгып, бераз эшләп, чәчәкләремә су сибеп, аларны тәрбияләп керсәм, йөрәгемә ял була, бөтен мәшәкатьләр онытыла», – ди ул. Гомере буе Азнакайдан – Кәтем авылыннан чыкмаган Гаймә апа хәзер кызы Фәнисә, кияве Әхсән белән Әлмәт шәһәрендә яши. Улы Фәнис һәм килене Гүзәл гаиләсендә дә һәрдаим кадерле кунак ул. Бүген Гаймә апа үзен бик бәхетле һәм бай саный. Әби, диеп өзелеп торган 5 оныгы һәм 4 оныкчыгы булган кешене бай дими буламыни?! «Бик матур яшибез, туганнарым да, оныкларым да гел хәлемне белешеп торалар. Бик зур рәхмәт аларга. Балаларым яшәгәндә, мин дә яшим», – ди ул. Оныклары да бик хөрмәт итә, ярата Гаймә апаны. Ул тәрбияләп үстергән балалар, оныклар зур тормышта югалып калмаган, нык адым белән атлыйлар.

Гөлшат МӘҖИТОВА-ЗӘЙНЕТДИНОВА



Тулы вариантын сайтыбызның «Язмыш» сәхифәсендә укыгыз.

PRESSA.RU



БӘХТИЯР

ВОЕНКОМАТТАН ПОВЕСТКА КИТЕРДЕЛӘР. БӘХТИЯР ӨЧЕН КУЛ КУЕП, ӘНИСЕ АЛДЫ УЛ ПОВЕСТКАНЫ. БӘЛКИ БӘХТИЯР ҮЗЕ ДӘ АЛГАН БУЛЫР ИДЕ. ӘГӘР...

Ләбиб ЛЕРОН

* * *

Бәби туу – зур шатлык, олы бәхет. Безнең өченче бәбиебез дә зур шатлык һәм олы бәхет булып туды. Түземсезләнеп көтеп алдык аны... Исемен Бәхтияр дип куштык. Бәхтияр – фарсы сүзе, бәхетле дигәнне аңлата.

Димәк, Бәхтияр – бәхет иясе, бәхет иярләүче...

* * *

Туарына бер көн кала, карындагы нарасый Аллаһы Тәгаләдән болай дип сораган, имеш:

– Дөньяга ни өчен барганымны белмим. Мин ни эшләргә тиеш?

Аллаһы Тәгалә әйткән:

– Мин сиңа фәрештә бүләк итәм. Ул һәрвакыт синең белән бергә булыр. Барысын да аңлатыр.

– Мин бит аның телен белмим, ничек аңлармын соң?

– Фәрештә сине үз телендә сөйләшергә өйрәтер. Барлык афәтләрдән дә саклар ул сине.

– Кайчан һәм нинди юл белән мин Синең янга кабат кайта алам?

– Бу турыда да фәрештәң әйтер.

– Минем ул фәрештәмнең исеме ничек соң?

– Исемнәре күп аның. Әмма син аны «Әни» дип йөртәчәксең...

* * *

1991 елның 16 августында дөньяга тәүге авазын салды ул. Хәер, тәүге авазын салды, дип әйтү дөрес түгел, хатын әйтүенчә, чынлыкта алай булмаган. «Ирекккә» чыгуга кычкырып җибәрергә тиешле бәби, киресенчә, «авызына су капкан кебек», беравык тынсыз-өнсез торган. Бу хәлне күреп, акушер хатын тиз генә бәбинең арт шәрифен чәбәкли башлаган. Шуны гына көткән шикелле, нарасый, кинәт, ачыргаланып, чыраийлап кычкырып җибәргән. Шул вакыт бу хәлне читтән генә күзәтеп яткан ана да, акушер ханым да җиңел сулап куйган. Алар янында кайнашкан өлкән яшьтәге татар хатыны исә, бәбине кулына алып: «Гомерең озын булыр, иншаллаһ», – дигән...

* * *

Хатыным Фидания сөйли:

– Тугач та: «Гигант бала бу!» – диделәр. Мөгаен, ярып алырга кирәк булгандыр. Алдагы икесен җиңел генә тапкач, монысын да җиңел табар дип уйлаганнар. Тик бусы катлаулырак булды. Минем көчем бетте. Соңгы чиктә ике шәфкать туташы ике яклап эчемә ятып, баланы этеп чыгарды. Шул вакытта баш миенә зыян килгәндер инде. Икенче көнне баланы имезергә китерделәр. Шулкадәр әйбәт имә. Бишенче көнне өйгә чыгып киттек. Улыбызны бала арбасына салдык та җәяү генә кайттык.

Дүрт айлар тулганда бала аягын тери башларга тиеш бит инде. Бәхтиярнең аяклары җеп кебек асылынып тора. Шуңа игътибар иттем. Аннан гел утка карый. Тегеләй дә борып карыйбыз, болай да... Юк, гел утка карый бу. Шуннан невропатологка алып киттек. Ратнер клиникасына кереп яттык. Сигез тапкыр яттык без анда...

* * *

Табиблар: «Интекмәгез! Сез яшь бит әле! Балагызны интернатка тапшырыгыз!» – диләр...

Күз яшебезне күрсәтмәскә тырышып, сыктыйбыз – күңелләребез елый, йөрәкләребез парә-парә килә. «Ничек инде? – дибез аларга. – Юк! Мондый эшне беркайчан да эшли алмаячакбыз!» Аңлаганы – аңлады, аңламаганы аңлаган кыяфәт ясады. Хәер, аларны гаепләргә кирәкмидер дә. Үзләренчә хәлебезгә керүләре бит, хәсрәтебезне шулай җиңеләйтергә тырышулары...

Безнең алда – очы-кырые күренмәгән билгесезлек. Мин түзәм, түзәргә тырышам. Хатыным да сабыр, Алланың рәхмәте яугыры. Дөрес, кайчакта мендәргә капланып елый. Үксі-үксі елый. Ләкин түзә. Бирешми. Күпмегә түзәр ул? Күпмегә кадәр авыру бала белән изаланыр? Терелерме, савыгырмы улыбыз? Күпмегә кадәр мин түзәрмен? Ахыры еракмы бу интегүләрнең? Аралары яшь тә өч ай гына булган ике кызыбыз да бар бит әле. Аларны да карарга, тәрбияләргә кирәк. Көннәрдән бер көнне сыгылып, сынып төшмәбезне?

Моны бер Аллаһы Тәгалә үзе генә белә.

Ярый әле үз фатирыбыз бар. Анысына мең шөкер. Фатирың да булмаса, «башны салларга салып, китәсе иде агып», дияргә генә кала. Әмма безнең исәп нык: төшенкелеккә, сынауларга бирешмәскә, сыгылып төшмәскә. Без – түзәбез. Түзәчәкбез.

Мин шулай дип әйттем дә әйтүен... Без шулай дип уйлаган идек тә уйлавын...

* * *

«Өмет – иң яхшы табиб», – дигән Александр Дюма.

Безнең өмет – Юлия Николаевна. Ул – массаж ясаучы, Бәхтиярның аякка басуына нык ышанган кешеләрнең берсе.

«Вот увидите, поставим мы его на ноги!» Аның безне канатландырып торган сүзләре бу. Юлия Николаевна олы йөрәкле мәрхәмәт иясе. Аның фамилиясен хәтерләмибез дә инде, әмма өметләндергеч сүзләре мәңгегә исебездә калды.

Бөтенләй диярлек хәрәкәтсез яткан Бәхтиярыбызга кабат җан өрүче булды ул. Вакытын, көчен кызганмады. Аның шифалы куллары, җитез бармаклары нарасыебызның тәнен, аяк-тәпиләрен, кул-бармакларын өзлексез әвәләде, туктаусыз сылады. Баланы тик яткызма, мин юкта да массаж яса, дип, бу эшкә Фиданияне дә өйрәтте.


Управление ЗАГС Кабинета Министров Республики Татарстан

«Менә күрерсез!..»

Аның бу сүзләрен Аллаһы Тәгалә ишетте. Тырышулар бушка булмады, шөкер...

...Көннәрдән бер көнне, чираттагы сеанстан соң, Юлия Николаевна Бәхтиярны палата идәненә иплә̧п кенә бастырган. Һәм – менә сиңа могҗиза! – моңарчы бер тапкыр да мүкәләп карамаган улыбыз, палатадагыларны таң калдырып, тәпи йөреп киткән!

Шушы куанычлы вакыйгадан соң мин безне жәлләп уфтанучыларга: «Менә күрерсез әле, Бәхтияр дүртенче президент булачак!» – дип әйтә башладым. Йа Ходা! Нинди президент, ди, әле ул! Кирәк бит шулкадәр оптимист булырга...

Күз яше аша көләргә тырышуым.

Һәрбер кеше – кемнең дә булса баласы.

Пьер Опостен Бомарше

* * *

Көнхисап дәфтәрдән:

«Бәхтияр йөреп китте китүен, ләкин теле ачылырга ашыкмады. Табиблар: «Баш миенең бер ярымшары эшләми, шул сәбәпле, бала сөйләшми», – диләр. «Кайчан да булса сөйләшәчәкме соң?» – дигән соравыбызга җаваплары мондый:

– Әгәр баш миенең эшли торган өлеше икенчесенең дә вазыйфасын алса, бала сөйләшә алачак!

Андый хәлләр булгалый, дип өметләндерәләр. Тормышта моңа мисаллар бар, диләр. Бу юлы да яхшыга өметләнәбез – башка юл юк...»

* * *

Безнең Бәхтияр әле сөйләшми. Ара-тирә бер-ике сүз әйткәненә дә чиксез сөенәбез. Кәефе булган вакытта, очынып-сөенеп йөргән

PRESSA.RU

чакларында: «Всё!» –дип әйтеп куя. Кайвакыт: «Ма-ма», – ди. «На!» – дип әйткәне дә бар. Без шаяртып:

– Бәхтияр, өйдә урысча сөйләшмә, яме! – дигән булабыз. Авызы җырыла Бәхтиярның, бу – аның без әйткәнне аңлап көлүе үзенчә.

Аңлап, дигәннән… Кешедән яшерә торган түгел: Бәхтияр – акылга зәгыйфь бала. Шулай туды, шулай яши, калганын бер Алла белә…

Вакыт дәвалый… Ләкин ул – ашыгыч ярдәм машинасы белән бер: сиңа бик кирәктә тиз генә килеп җитми…

Бездән еш кына:

– Бәхтияр бераз гына булса да аңлыймы соң? – дип сорыйлар.

– Әйе, аңлый ул, – дибез.

Дөрестән дә, шактый нәрсәне аңлый Бәхтияр. Берәр әйбергә төртеп күрсәтеп:

– Бәхтияр, әнә тегене генә алып бир әле! – дисәң, кәефе булса, карусыз шуны кулга китереп тоттыра. Утны сүндер (яндыр), дисәң – сүндерә (яндыра). Ишекне яп (ач), дисәң – яба (ача). Кайчакта әйткәнне дә көтеп тормый: бүлмәдән чыгуга, утны сүндереп куя. Кайвакыт арттырып та җибәргәли: эшләп торган суыткычның розеткасын без күрмәгәндә алып, дивар белән суыткыч арасына ыргыта. Телевизор белән дә шундый ук хәл еш кабатлана: сине карый-карамый дип тормый, бара да сүндерә. Сүндерә дә, зур канәгатьлек белән: «Всё!» – ди. Мин әйттем, янәсе…

Яраткан шөгыльләре дә бар Бәхтиярның. Мәсәлән, машиналар ярата ул. Чыннарын да, уенчыкларын да. Без алган уенчык машинаның исәбе-хисабы юк. Күбесе бер көннән артыкка чыдамый. Машинаны гына түгел, башка уенчыкларның да тиз арада ватыласын белеп алабыз. Баланы сөендерүдән үзебез дә рәхәтлек кичерәбез. Моны шул хәл-халәтне кичергәннәр генә аңлый торгандыр, шәт!

Җыр тыңларга ярата. Үлеп ярата. Иң яраткан җыры – «Зәңгәр шәл»дән кызлар җыры. «Булат, Булат ка-а-айткан, бүләк алып ка-а-айткан, сиңа да, миңа да…» – дип, мин үземчә җырлап җибәрүгә, Бәхтияр эче катып көлә башлый. Икенче җыруны, әйтик, «Халык улы, ил батыры – Бәхтияр Леронов ул…» – дип җыр суза башлауыма – улыбыз рәхәтләнеп көлә…

* * *

Юыныргa ярата Бәхтияр. Бигрәк тә мунчада. Көн саен юыныргa риза. Шәһәр фатирында мунча юк. Аны ванна алыштыра инде. Ванна – Бәхтиярның чәчен алу урыны да. Ике көнгә бер шушында кырындырам аны: җырласам гына кырындырырга рөхсәт, җырламасам – юк: бер киресенә катса, һич тыңлатам димә. Ваннага керүгә, суда уенчыклары белән уйнап утырган Бәхтиярга карап, җыр суза башлыйм. Җырлый белсәм – бер хәл иде, ләкин нишләмәк кирәк, «халык» соравы буенча җырламас җирдән «җырларга» туры килә.

* * *

Бервакыт Киндерледәге бакчабызга барышлый, кирәк-ярак алырга дип, Дәрвишләр бистәсендәге базарга тукталдык. Аласы әйберләр алынгач, үзебезгә кирәкле автобус туктый торган урынга килеп бастык. Автобус килде. Ишекләр ачылды. Инде утырабыз дигәндә генә – йа Алла! – Бәхтиярыбыз суга төшкәндәй юкка чыкты! Әрле-бирле киләбез – малай юк! Ул арада автобус кузгалды. Шул тирәдәгеләрдән сораштырабыз:

– Шундый-шундый малайны күрмәдегезме? – дибез. Юк, диләр. Безнең борчылу аларга күчте. Эзләшә башладылар.

Базар шактый зур. Фидания бер якка чаба, мин – икенче тарафка. Кабат элекке урынга килеп җитәбез. Юк Бәхтияр!

«Без искәрми калганбыздыр, Бәхтияр автобуска утырып киткәндер!» – дигән уй бөтенләй аяктан ега язды. Автобуста булса, теләсә кайсы тукталышта төшеп калырга мөмкин бит ул! Шашар чиккә җиттек. Бәргәләнәбез, өзгәләнәбез. Үземне үзем белештермәстән, Фиданиягә тозлы-борычлы сүзләр әйтеп ташлыйм. Без ир-ат халкы шулай бит: авырлык-мазар килсә, шундук кемне дә булса гаепләргә ашыгабыз.

Кара кайгыга батып, хәлдән таеп, инде нишләргә, дип торганда… Бәхтияр яныбызда калыкты. Ышанасызмы, кинәт гаип булган Бәхтияр кинәт пәйда булды! Күзләребезгә күренәме, дип торабыз. Берни булмагандай басып торган Бәхтиярне кочаклап алдык та:

– Улыбыз табылды! – дип кычкырдык…

Шулчак безнең хәлне күреп, аңлап, ничек ярдәм итәргә белмәгән кешеләрнең елмаю җәелгән йөзләрен яшь аралаш шәйләп өлгердем…

* * *

…Военкомат ишегалдын
Таптамам, дигән идем…

Шулай дип җырлый идек без яшь чакта.

Бәхтияр исеменә килгән повестка бездә хәрби комисариатта эшләүчеләргә карата коточкыч нәфрәт хисе уятты. Мин исә, запастагы өлкән лейтенант, шәхсән, үземә урын таба алмыйча, шактый вакыт пар чыгардым: военкоматка барсам, тетмәләрен тетеп, ояларын туздырып кайтачакмын, дип тузындым.

Бераздан, ачу басыла төшкәч, үзебездә шаяртырга көч табып сөйләшә башладык. Хатыным Фидания әнисенә шалтырата:

– Әни, никрутлар җырын өйрәнә тор!

– Нигә? – ди әби. – Берәрсе армиягә китәме әллә?

– Әйе! Бәхтиярга повестка килде бит! – ди Фидания.

– Кайбер җыруларны беләм бугай әле, – ди әби, кызы әйткәнне бик үк аңлап бетермәстән. Ул арада шул җырлардан берсен исенә төшереп, телефон аша җырлый башлый:

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китәм, дисең, кайларга?
Бәлки сабырлар итәрсең
Тагын бер-ике айларга…

(*Ахыры киләсе санybызда.*)

ӨМЕТСЕЗЛЕК ҺӘЛАКӘТНЕҢ ЮЛДАШЫ. АДӘМ БАЛАСЫНЫҢ КЫРЫК ШӘМЕ СҮНГӘНДӘ ДӘ КЫРЫК БЕРЕНЧЕСЕ КАЛА, ДИЛӘР. ӨМЕТ КУЗЛАРЫ СҮНЕП БЕТКӘНДӘ ДӘ ШУЛ КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ШӘМНЕ КҮРЕП АЛА БЕЛЕРГӘ ГЕНӘ КИРӘК.



Асия
ЮНЫСОВА

ТАБЫЛДЫК

Бу шагыйрә ханымны күптән беләм. Дәресрәге, шигырьләрен укып барам. Җитмешен узып киткән булса да, шигырьләрендә дәрт шаукымы, мәхәббәт чаткылары бар аның. Үзен бик тә карап, матур итеп йөртә белә ул. Шуңа күрә аның яшьлегендә генә түгел, бәлки хәзер дә ир-атларның күз карашын үзенә җәлеп итә алганлыгына бер дә шикләнми идем.

Редакциягә бер керүендә ул ачылып китәсе итте. «Дөрес фаразлагансыз. Мин мәхәббәт халәтендә яшәдем. Бу дөньяда яшәр өчен Мәхәббәт бик кирәк нәрсә ул. Кайгыларны да күрдем, әмма мине алардан шул мәхәббәт дигән нәрсә исән алып чыкты. Мәхәббәт әле янында юк икән, аны уйлап чыгарырга кирәк. Әгәренки яратудан күзләрең очкынланып яна башласа, чын мәхәббәте дә ерак йөрми аның».

Шул рәвешле башланган сүзебез шагыйрә ханымның тормыш сәхифәләренә, яшәү, иҗат итү рәвешенә барып ялганды. «Кызым еракта – Себердә үк яши. Ул да шагыйрә, тик шигырьләрне русча яза. Әле менә икебезнең шигырьләрдән уртак китап чыгардык Мәскәүдә», – диде ул.

Кызының әтисен бик тә нык яратып кияүгә чыккан булган ул. Мәхәббәт хакында да сөйләштек без.

– Үземнән 10 яшькә өлкәнрәк иде. Очучы иде. Реактив очкычларда очты. Ел да медкомиссия узып торган ирем көннәрдән бер көнне бөгелде дә төште. Бөер дип уйладык. Табиблар буйлап киттек. Бер теше дә ямалмаган, өрлектәй таза адәмдә яман шеш таптылар. Реактив очкыч пилотлары шулай акрынлап радиация белән



зарарлана икән. Ике-өч ай дигәндә ирем шәм сыман сызды да бетте. Малай кебек кенә калды. Октябрь азагында җирләдек. Ул исән чакта ук мәктәп стадионына йөгерергә чыга идем. Ирем очышта чакларда яки төнге очыштан кайтып ял иткәндә, аңа комачауламыйм дип, һаман саен ялгыз гына йөгерәм. Аякларың йөгерә тора, ә башың мәңге бетмәс уйларын уйлый. Минем байтак шигырьләрем йөгергәндә языла иде. Ирем урын хастасына калгач, уемда ул гына булды. Тагын нинди дару табыйм микән, тагын кайсы табиб белән киңәшләшим икән, дип уйлый-уйлый түгәрәк арты түгәрәк әйләнәм. Шулай әйләнә торгач, кулымдагы беләзегемнең төшеп калганын да сизмәгәнмен. Иремнең бүләге иде лә бу беләзек! Аны югалтуны мин начарга юрадым. Димәк, китә ирем, мин аны да югалтам. Юньле фал түгел бу! Инде мин йөгерүдән туктап, кипкән яфракларны, беренче суыклардан укмашкан кар кантарларын аралый башладым. Үзем елыйм.

Бер ир-ат көн саен диярлек миңа каршы түгәрәк ясап йөгерә торган иде. Ул да туктап калды: «Ни булды, ни югалттыгыз, нигә елыйсыз?» – дип сорау арты сорау яудыра. Үзем елыйм, үзем такмаклыйм: «Ирем, беләзек, югалттым...» Ул да эзләште беләзекне, тик таба алмадык. Ирем шул төнне җан бирде. Мин кабат йөгерергә чыкканда яз килеп азаплана иде инде. Минем йөрәктә генә кыш суыгы. Ялгызлык, югалту суыгы. Берзаман йөгереп бара торгач, кемгәдер килеп бәрелгәнемне дә абайламаганмын. «Ханым! Ниһаять, очраттым бит мин сезне. Адресыгызны да сорамаганмын. Менә бит ул! Таптым бит мин аны!» Ни күрим! Йөгерүче ир-атның учында гәрәбә кашлы көмеш беләзегем – иремнең ядкаре ята. Мин тагын елап җибәрдем. «И-и, ханым, мин сезне сөендерим дигән идем, ә сез тагын елыйсыз!» Сөйләп бирдем инде кайгымны. Сабыр гына тыңлап торды. Аннары әйтеп куйды: «Язмыш бу. Бер ел элек мин дә хатынымны җирләгәннән соң чыккан идем бу стадионга. Каршыма һәр кич саен язмышым йөгергәнен генә белмәгәнмен. Тәкъдир түгел микән бу? Табылган беләзек уртак бәхеткә ишарә түгел микән?»

Тиздән без бергә яши башладык. Ул миннән ун яшькә кечерәк булса да, яшь аермасын тоймадык. Шагыйрә итеп тә мине теге ирләрем түгел, нәкъ менә ул – өченче ирем таныды. Тормышымда гармония урнашты дигәндә генә ул яшь хатынга китеп барды. Аның бала атасы буласы килде. Гаепләмим. Умартачы булып китте. Беренче балдан мине авыз иттерә, киңәш кирәк булганда янына килә. Мине һаман яратуын әйтә. Өлкәнәйдем бит инде. Мин шушы табылдык бәхетемә дә канәгать.

PRESSA.RU



КЫТАЙДАГЫ БИШ ЭШЕМ

IBSEN INTERNATIONAL – 2010 ЕЛДА НОРВЕГИЯДӘ ОЕШТЫРЫЛГАН КОМПАНИЯ. АНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ – СӘНГАТЬ, МӘДӘНИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ ХАЛЫКАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР УРНАШТЫРУ.



Сөмбел ГАФФАРОВА

Әлеге компания мәшһүр драматург Генрик Ибсен күтәргән темаларны үстерә, кеше хокуклары, ир-ат белән хатын-кызларның тигез хокуклылыгы өчен көрәшә, шәхес иреге фикерен алга сөрә, экологияне яклый, коррупциягә каршы чыга, глобализациянең уңай якларын күрсәтә. Компания халыкара чаралар – фестивальләр, конференцияләр, перфоманслар, семинарлар, мастер-класслар уздыра. Быел алар Кытайда узды. (Оешманың эшчәнлеге белән таныша аласыз – http://ibseninternational.com/





■ Усянь Гуань храмы.

■ Гуанчжоу телебашнясы биеклеге буенча дөньяда икенче урында тора.

Кытайга барырмын дип уйламаган да идем. Хәтта хыялланганым да булмады. Хыял дигәне сине үзе эзләп таба икән. Былтыр Г. Камал театрыннан хәбәр килеп төште. «Драматурглар! Кытайда һәм башка илләрдә пьесаларыгызны сәхнәләштерү мөмкинлеге туды. Берәр күренешне инглиз теленә тәрҗемә итеп, безгә җибәрегез. Арагыздан берегезне Кытайның өч шәһәрендә узачак өч мастер-класска чакырырлар. Бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз!» Өмет чаткысы, мин узмам инде, дигән пессимистик уйларны читкә тибәрде тибәрүен. Ә менә «бәлки?!» дигәне, котыртып, бу бәйгедә катнаштырды. Гаҗәеп хәл! Норвеглар нәкъ минем пьесамны сайлап алды! Өметнең җиңүчеләр биюен күрсәгез! Алдагы елның нинди вакыйгаларга бай булачагыннан Өметнең хәбәре юк иде әле.

Кытайга барып, мастер-класста катнашу бәхетеннән эйфория гап-гади паника белән урыннарын алмашты да куйды. Беренчедән, гаилә белән барасы түгел. Икенчедән, Мәскәү аша берүземә очасы (монда иң мөһиме – ... хәер, монда һәр сүз мөһим...)

Ширәмәт аэропортында адашмыйча, Кытайга очучы очкычны табу – үзе бер галәмәт!

Беренче күренеш – Пекин

«New text. New stage» – «Яңа текст. Яңа сәхнә» дип исемләнгән мастер-класслар беренче мәртәбә 2013 елда Пекинда узган икән. Ул вакытта аңа дүрт язучы чакырулы булып, ахыр чиктә, ике пьеса сәхнәгә куелырлык дип табылган. Берсе Кытайда, икенчесе – Кытайда һәм Норвегиядә. Ә бу юлы Россиядән Г. Камал театры партнер итеп чакырылган. (Башта ук шулай аңлатасы калгандыр, бәлки. – *С. Г.)*

Кытай халкы бик хисле, сабыйлар сыман елмаючан, ачык күңелле.

Пекиндагы беренче воркшопта (мастер-классны шулай дип тә атыйлар – *С. Г.*) оештыручылар иҗатыбыз, язу стильләребез белән танышты. Моңарчы язылган пьесаларыбызның берәр күренеше турында фикер алышып, тамашачылар өчен сәхнәдә ачык уку әзерләнде. Төрледән-төрле язучыларны үзара таныштыру, оригиналь, яңа текстлар язарга илһамландыру икән максатлары. Бездән сигез универсаль, ягъни дөньяның теләсә нинди почмагында аңлашыла торган, һәркем күңеленә якын булырдай пьесалар китертмәкчеләр. Менә шундый җиргә эләктем мин...

«Ни өчен Кытай?» дигән сорау барыбызны да кытыклады. Җавабы бик гади икән: бүгенге көндә Кытай театр өлкәсендә шактый алга киткән. Биредә театрлар, театраль студияләр бихисап. Яшьләр дә театрга тартыла, тамашачы спектакльләргә яратып йөри.

Без язачак пьесаларның темасы – миграция дип игълан ителгәч, аптырап калдым. Башкаларның күзендә дә шул ук аптырау хисе чайкала иде. Барыбыз өчен дә әлеге тема бик ерак кебек... Нәрсә яза алабыз инде без миграция хакында?! Оештыручыларыбыз исә безне атна буена миграция турында уйлатты. Гаиләләребез-

PRESSA.RU



нең, туганнарыбызның теге-бу җиргә күченеп китү тарихларын искә төшерә башладык. (Әллә нинди искиткеч тарихлар калкып чыкты. – *С. Г.*) Миграциягә (мөһаҗирлеккә) китерүче сәбәпләр турында лекцияләр тыңладык. Шулай итеп, безне бу темага пьеса язарга һәрьяклап әзерләделәр, илһамландырдылар.

Оештыручы-кураторларның берсе Вилма Штритоф (Словениядә театр, телевидение һәм дәүләт радиосында драматургия белгече. Төрле театраль проектларда, фестивальләрдә актив катнаша. – *С. Г.*): «Безнең өчен иң мөһиме – миграция темасына фикер алышып, язучыларны шул темага пьеса язуга илһамландыру. Кешеләр төрле сәбәпләр аркасында бер илдән икенчесенә күчә – кемдер теләп, кемдер мәҗбүр булып...»

Баксаң, дөньябыз үзе үк бертуктаусыз миграция хәлендә бит бүген!

* * *

Пекин буйлап йөргәндә хозурланып туймыйм. Бар җирдә кызыл кытай фонарьлары, ресторан баскычларын бер үк төрле арыслан сыннары бизи. (Арысланнарның берсе – ана, икенчесе ата икән! Берсенең тәпие астында бала арыслан булса, икенчесенекендә – уенчык туп. Ирләр кайда да ирләр инде!)

Шәһәргә чыккач, фотога төшерешергә керештек... тирәбездә кытайлар җыела башламасынмы? Берсе фотоаппаратын суза, икенчесе!.. Бер белмәгән кешеләр белән күмәк фотога төштек – кәефебез күккә менде!

* * *

Яңа танышларымның күбесе Татарстан турында ишеткәне дә юк. Республикам, милләтем турында сөйләп, агарту эшләрен алып барырга туры килде. Ахыр чиктә, мине кунаклар, театрдагы тамашачылар белән таныштырганда, иң беренче итеп Казан, Татарстан исемнәрен яңгыраткач кына, «Россиядән» дип тә куялар иде.

Европалылар бик итагатьле икән. Сөйләшүләре нәзакәтле, әмма төче түгел. Башкаларга карата игътибарлы, үзләрен купайтып күрсәтергә ашыкмыйлар. Башкалар да аларга охшаган дип уйлый башлаулары соңгы арада Европалыларның «нечкә» урыннарына әйләнде. Мәрхәмәтле, игътибарлы, кешелекле Европаны мигрантлар нишләткәнен үзегез беләсез...

Җитәкчеләремнең берсе миннән: «Татарстанда мөселманнар яши дип аңладык. Сездә барлык хатын-кызлар яулык бөркәнеп йөриме?» – дип сорады. «Юк» дигән җавабыма исе китте. «Синең кебек, ягъни Көнбатыш стилендә киенеп йөрү ярый, алайса? Яулык ябу мәҗбүри түгелмени? Белми идем... Татарстанда ирләр хатыннарына эшләргә рөхсәт итәме? Бөтенләй төренеп йөрергә мәҗбүр итмиме? Мөселман ир-атлар хатыннарын кимсетмиме?» Бу сораулары гади кызыксыну гына булмаган. Тормышындагы зур үзгәрешләрен уртаклашты ул минем белән. Кызы Гарәп Әмирлекләренә эшкә китеп, ислам динен кабул иткән, хәзер бер шейхның улына икенче хатын булып кияүгә чыгарга әзерләнә икән. Кызын алтын читлеккә ябмасмы, дип өзгәләнә әни кеше. Бераз читкә китеп, кызының исем тарихы турында да сөйлим әле, чөнки ул миңа бик тәэсир итте.

Әлеге ханым баласы белән йөкле булганда төш күргән. Имеш, кызы аңа аркасы белән борылган килеш басып тора. Әнисе аны «Лина! Лина!» дип чакыруга, кыз борылып караган. Әлбәттә, баласы тугач, әни кеше, гәрчә моңарчы мондый исемне ишеткәне булмаса да, мәгънәсен белмәсә дә, аңа Лина дип исем кушкан. Һәм менә еллар узып, кыз ислам динен кабул иткәч, әнисе аннан: «Исемеңне ниндигә алыштырдың, тәртибе шундый бит?» – дип сораган. Кызы исә: «Кирәкмәде. Лина – гарәп исеме бит», – дип җавап кайтарган. Бу хикәятне тыңлаганда тәннәрем чемердәп куйды.

Гомумән, мөселманнар тормышы, безгә булган караш турында бик еш сораштырдылар. Шулай итеп, минем өчен – Кытай мәдәнияте, Европа халкының холкы, ә алар өчен Татарстан, татарлар зур ачыш булды...

* * *

Бер-беребезгә «Татар драматургиясе ни хәлдә?» дигән сорауны еш бирешәбез. Ә мин кураторым Вилма Штритофтан: «Словения драматургиясе ни хәлдә?» – дип кызыксындым.

– Башка илләрдәге кебек үк, Словениядә дә язучылар өчен мастер-класслар уздырыла. Шулай ук ел саен дәүләт тарафыннан пьесалар бәйгесе дә игълан ителә. Язучылар өчен зур ярдәм һәм мөмкинлек бу. Әмма театрлар драматургик текстларга әллә ни игътибар итми. Проектларның күбесе пост-драматик театраль перфомансларга өстенлек бирә. Һәм шуның белән чын пьеса иҗат итүгә киртә куя. Миңа калса, ике юнәлешне дә бертигез алып бару мөһим. Әмма бүгенге көндә аларның беренчесе искергән, заманча итеп кабул ителми...

* * *

Миграция... Нәрсә язарга? Нәрсә турында язарга? Фикер тупларга, эшләргә өч аем бар әле минем. Аннары, ким дигәндә, берничә күренеш язып, кураторларга кытай теленә (ә минекен әле инглиз теленә дә – *С. Г.*) тәрҗемә итү өчен җибәрергә кирәк.

...Нәрсә турында язарга? Фикер тупларга, эшләргә... ике ай вакытым бар әле...

Тукта... Темам, пьеса геройлары... янымда лабаса! Җаныма күптән тынгы бирми азапласа да, әлегәчә үземдә бу теманы ерып чыгарлык көч тапмый идем. Дәү әниемнең сугышта хәбәрсез югалган 18 яшьлек абыйсы Нәкыйпнең язмышы язарга этәргеч бирде. Пьесамда, концлагерьдан азат ителгәч, ул башка илгә качып китәргә мәҗбүр була... Моңарчы, үземне аяп, концлагерьлар турында берни дә укымый идем. Хәзер Интернетны аркылыга-буйга гизеп, концлагерьда исән калган кешеләрнең истәлекләре белән кызыксындым, документлар белән таныштым, фотоларын карадым. (Хәзер шулар исемнән чыкмый, күз алдымнан китми. Тәэсире көчле булды. – *С. Г.*) Пьесамда коточкыч күренешләр дә, сугыш кыры да юк. Әмма башыннан ахырына кадәр шул чор кешеләрен, алар кичергәннәрне йөрәгем аша уздырып, күз яше аралаш яздым...

3 эш

Кытай таякчыкларын куллана белүем чамалы гына иде. Ә Пекинда беренче мәртәбә өстәл артына утыруга ук шуның кадәр оста итеп уйнаттым тегеләрне! Ач карын әллә нигә өйрәтә ала икән! (Скрипкада да уйнарга өйрәтмәсме? – *С. Г.*) Мәшһүр Пекин үрдәген татып карадым – тәмле! Кыздырган ит, кыздырылган яшелчә – болары да ашарлык. Безнең өчен экзотика булган лотосны да авыз иттек.

Икенче күренеш – Шанхай

Вилма Штритоф: «Чын эшнең беренче адымнары башланды. Язучылар текстларының язган кадәресен алдан җибәрделәр. Аларның фикерләү юнәлеше, стиль, образлылык, язу планнарын күрдек. Кайбер авторларда төзек план, булачак пьесаның тотрыклы структурасы, берничә күренешләре тулаем язылган булса, бүтәннәренә башка юнәлеш бирергә, кабат илһамландырырга туры килде. Барлык язучыларга да пьесаларының көчле һәм йомшак якларын күрсәттек. Сорауларыбызга җаваплар алдык. Язучылар безне ишетерме? Киңәшләребезне истә тотармы?.. Гомумән, без бик канәгать калдык. Эш бара! Уңай нәтиҗәләр буласына шигем юк!»

* * *

Сигез драматургның икесе – ир-ат, алтысы – хатын-кыз. Башта моңа игътибар итмәдем. «Сездә драматург хатын-кызлардан тагын кемнәр бар, алар ни турында яза, аларны нинди проблемалар борчый?» – дип сорагач, уйга калдым. «Бездә драматургларның барысы да диярлек ир-ат» дигән җавап аларны гаҗәпләндерде.

Вилма Штритоф: «Словениядә дә хатын-кыз драматурглар әллә ни күп түгел... Драма ул – проза, шигърияткә түгел, архитектурага якынрак тора дигән гыйбарә ишеткәнем бар. Килешәм. Пьеса – уку өчен генә түгел, иң мөһиме: сәхнәдә куелу өчен языла. Ул – фабула, сюжет сызыгы, авторның фикер агышы гына түгел. Ягъни пьеса язу – зур хезмәт. Драматургиядә хатын-кызның аз булуын нәкъ менә шушы факт белән аңлатып була дип әйтә алмыйм. Ирләр белле-тристикада, шигърияттә, башкада да алда бара бит... Әмма башка өлкәләрдәге кебек үк, бүгенге көндә хатын-кызның авазы көннән-көн көчлерәк яңгырый.

Ким Дэвис, драматург (АКШ): Безнең театрлар барлык авторлар белән дә эшли алмый, алар артык күп. Ә менә ир-ат һәм хатын-кыз драматурглар саны бертигез диярлек. Әмма шунысы хак: ир-ат пьесалары ешрак куела, аларның карьералары да дәвамлырак...

Майк ван Граан (Кейптаундагы Африка сәнгать институтының башкарма директоры): Бездә драматурглар саны арта бара. Хатын-кызлар да җитәрлек. Африка театр җәмгыятендә берничә хатын-кыз язучы бар, ә менә «кара» җәмгыятьтә алар азрак. Соңгы вакытта Кейптаунда узучы пьесалар фестивале драматург һәм режиссерлар арасында хатын-кызлар санын арттырыр дип өметләнәбез.

Драма – сүзләрдән төзелгән уникаль бина. Бу бинаны һәрдаим яңача төзи белергә кирәк.

Өченче күренеш – Гуанчжоу

Вилма Штритоф: «Бу сессия иң җитди булды. Барлык кураторлар язылган текстлар белән танышып чыкты һәм сигез пьесадан әлеге моментка иң яхшы дип табылган өчесен сайлап алды. Шул пьесаларның берәр күренешен махсус чакырылган режиссерлар сәхнәләштерәчәк. Калган пьесаларның да кечкенә кисәкләрен режиссерлар карап чыгарга риза булды».

Өченче сессиягә өч режиссер килде. Кытайдан Фунг Вай Ханг, Германиядән Матиас Йохманн һәм Норвегиядән Йон Томбре.

Миңа Кытай режиссеры билгеләнде. Үзен Бобо дип таныштырды. (Кытайлар кайвакыт үзләрен истә калырлык исем белән атый – *С. Г.*) Бобо: «Үземне түгел, сине, пьесаңны күрсәтергә телим. Шуңа күрә минем өчен текст – беренче чиратта», – диде.

Элек актриса булган режиссерыма кытай актерлары белән шактый эшләргә туры килде. Нигәме? Монда актерлар би-ик эмоциональ шул! Никадәр ныграк кычкырсаң, йөз белән никадәр күбрәк хәрәкәтләр ясасаң, шулкадәр үтемлерәк дип кабул ителгән. Менталитет шундый. Телне белмәгәч, кешеләр сөйләшәме, бәхәсләшәме, талашамы – һич аңлыйм димә... Кыскасы, актерларның эмоцияләрен басарга тырыштык. «Тынычрак... Гадирәк... Кулларны болгамыйча гына...» – Бобо эмоцияләренең градусын киме-

PRESSA.RU



Әлеге күренештә Кытай артистлары татарча бииячәк. (Видеосын сайтыбызда карый аласыз.)

Ризыклары телне йотарлык! Гурманнарга – Шанхайга гына барырлык. Вок-табада пешкән моңарчы күрмәгән яшелчә-үләннәр күп сәяхәт итүче норвегларымның «м-м-м!» дигән сокланулы хуплавын алып торды. Сүз уңаеннан, өйгә кайткач, вок-таба алып куйдык. Хәзер ара-тирә кытай ризыклары белән сыйланабыз.

Оештыручылар рестораннарда безгә ризыкны үзләре сайлады. Югыйсә әллә ниләр ашап ташлар идек! Ә кытайлар үзләре бар нәрсәне дә ашый кебек... Ите генә түгел, бер генә әгъзасы да әрәм булмый. Безне кызганып, чаян-тараканнар, диңгез хәшәрәтләре, дәү әкәм-төкәмнәрне күрсәтеп тормадылар. Ә без аларны барыбер күрдек...

теп торды. Баш рольне башкаручы егеткә дә мин: «Бу вакыйга да, үзең белән булды дип кабул ит. Тормышта ничек әйтер идең, шулай әйт. Ахыргы сүзләрне эмоциягә баетыр өчен тавышны арттырма, киресенчә... кимет. Хис-эмоцияләрең бәреп чыкмасын, аны тыеп тор, ә шул тыелуың, менә, күренсен! Күзеңнән... яшьләр атылып чыгарлык булсын...» – дип өйрәткән булдым. Нишләр инде үзе тагын...

«Кара, безнең көйгә охшаган бит бу!» – диеште актерлар.

4 ЭШ

Ышанасызмы, Бобо татар бию көен табып, актерларны татарча биетеп тә алды бит әле! «Шәп!» – дип, авызымны ерып торганда, режиссерым: «Ә ахырда синең татарча җырлавыңны телим», – димәсенме?! Кытай тикле Кытайда кайчан җырларга туры килер иде әле?! Һәр репетициябезнең ахырында кытайлар «Су буйлап»ны җиренә җиткереп көйләп чыга торган булдылар.

Дүртенче күренеш – спектакльләрнең эскизлары

«Black box» театр студиясе каршысында исемнәребез һәм фотоларыбыз куелган зур баннер тора. Шуның янында, бала-чага сыман төрле кыяфәтләргә керә-керә, фотога төшеп мәш киләбез. Сөйләшәбез, көлешәбез. Эчке дулкынлану хисен ничек тә яшерергә тырышу бу. Менә тамашачылар утырышты. Оештыручылар тарафыннан сәламләү сүзләре әйтелде. Ут сүнде.

Пьесама да килеп җиттек... Соңгы минутта гына туган телемдә җырларга әзерләнәм. Күпме репетиция ясадым, бар да яхшы булачак... Менә... Башладым... «Идел бит ул, тирән бит ул...» Төп героема карасам... Тамагыма төер утырып, тавышым калтырап куйды... Актерның күзләрендә нәкъ мин теләгәнчә – яшь бөртекләре ялтырый иде.

5 ЭШ

Барлык эскизлар уйналып чыккач, иң кызык өлеш – тамашачылар белән фикер алышу башланды. Пьесам кытай тамашачысына бик якын һәм аңлаешлы булып чыкты. Бер кыз сәяси әләк аркасында качып китәргә мәҗбүр булган бабасы турында сөйләми булдыра алмады... Яңа бер пьеса язарлык кеше язмышы иде бу!

Язылачак күренеш

2017 елның көзен көтәргә калды. Шанхайда (ә бәлки, Норвегиянең берәр шәһәрендә – *С. Г.*) театраль фестивальдә сигез пьесаның барысы да уйналачак дигән план корылган. Бу – олы юлыбызның бер нәтиҗәсе. Аңарчы пьесаларыбызны «тарап», ахыргы вариантын кураторларга җибәрергә кирәк.

Ким Дэвис: «АКШта конкуренция бик зур. Шуңа күрә театрга пьесаңны илттең дә, ул тиз генә сәхнәгә куелачак димә. Күп очракта театр җитәкчесе аларга туры килүче пьесаны үзе эзли. Һәм, гадәттә, инде кайдадыр куелганнарын һәм дан казанганнарын сайлый. Яки язучының агенты бу эшне уңай хәл итә ала. Әйе, театраль агент эшне күпкә җиңеләйтә. Кыскасы, агенты булмаган язучыга сәхнәгә менү бик авыр».

Майк ван Гаан: «Мин субсидиягә ия театрда драматург булып эшлим. Пьесаларым шунда сәхнәләштерелә. Бәйсез драматургларга авыр, алар пьесалары куелсын өчен акчаны үзләре табарга мәҗбүр. Хәер, бездә Дәүләт Сәнгать Шурасы бар, ул акча ягын хәл итә. Әмма еш кына яңа әсәрләр төрле фестивальләр, шәхси фондлар акчасына сәхнәләштерелә».

* * *

Безнең эш шуның белән тәмамланды дисәң дә була. Оештыручылар алга таба пьесаларны партнер театрларга таратачак. Пьесаңның башка илдә сәхнәгә куелу мөмкинлеге күңелне кытыклый, әлбәттә... Өмет чаткысы тагын бию халәтендә!..



МИҢНУЛЛИНА Раушания

Казан дәүләт университеты

Кияүдә, ике бала әнисе

Карьера:
«Яз» нәшрияты директоры, Татарстан һәм Казан шәһәре буенча экскурсовод.

Тормыш шигаре: «һәр көнең алдагысыннан яхшырак булсын!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Бәхет өчен күп кирәкми

«Ярдәм» мәчете белән берлектә колясkада утыручы авыруларга хәйрия экскурсиясе үткәрдем. Казан буйлап сәяхәтебезне Тукай музее янынннан башладык. Кабан күле янында туктап, аккошлар ашаттык. Бауман урамына, Әби патшаның каретасы янына кадәр барып җиттек. Дүрт сәгать йөрдек! Арысалар да, шундый бәхетле иделәр. Тәүлекләр генә түгел, атналар, айлар буе өйдән чыкмый, дүрт дивар арасында көннәрен уздырырга мәҗбүр булган кешеләр бит алар. Президентыбыз автобус бүләк итмәсә, мондый чыгулар эләгер идеме икән?!


Матурлык бездә дә җитәрлек!

Язын социаль челтәрләрдәге National Geographic Traveler Россия дигән төркемнән хат алдым: «Казан, Татарстан турында языгыз әле, башка төбәкләрдәге туристлар өчен кирәк бу мәгълүмат», – дигәннәр. Күбрәк табигатьне тасвирларга кушканнар. Зәңгәр күл, Чатыр тау турында яздым, Кабан күле һәм аның серләре турында сөйләдем, Иделебезнең матурлыгын күрсәтергә тырыштым, Кама Тамагындагы мәгарәләрне дә онытмадым... Менә китте кызыксыну, менә китте сораштыру! Шаккаттым! Хәтта чит илләрдән дә хат язып, кызыксынучылар булды. Шулай инде, күрә белсәң, күрсәтә белсәң, үзебездә дә табигатьнең искиткеч почмаклары, елга-күлләр, урман-болыннар бар!

Чын хатын-кызлар шундый була!

Апрельдә Бөекбритания королевасы, Англиянең тере символы Елизавета II гә 90 яшь тулды. Әмма бәйрәм рәсми рәвештә июнь аенда узачак. Аның илне идарә итә башлавына 65 елдан артты! Ул әле дә атлар белән кызыксына, тарихи китаплар укый, Фейсбукта үз бите бар! Тышкы кыяфәте күпләрне сокландырырлык: аның чалбар кигән чагын берәү дә хәтерләми. Ике килене – герцогиня Кэтрин Кембриджская һәм мәрхүмә принцесса Диана Уэльская да барлык хатын-кызлар өчен матурлык, нәфислек, нәзакәтлек алиһәсе булып торалар. Сокланам!

сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

Кая барырга?

Җәй – яллар вакыты. Күпләр: «Быел кайда ял итәргә икән?» – дип уйлыйдыр. Дөнья күрәсе килә бит! Төркия белән Мисыр арзан булганлыктан, халык моңарчы күбрәк шул илләргә йөрде – хәзер менә юллар ябык... Хәер, Төркиягә арзан дип кенә түгел, яратып, күңел тартканга да бардык. Анда – тугандаш халык арасында – үзебезне беркайчан да чит-ят итеп хис итмәдек. Тунис яки Грециягә юллама бәяләре арасында аерма зур булмаса да, нигәдер барасы килми бит. Европа исә безнең хезмәт хаклары өчен шактый кыйммәт.

Үз балаларыбыз үзебезгә дошманмы?!

Балалар БДИ биргәндә ата-аналар исеменнән күзәтүче булып катнашырга туры килде. Күңелем, җаным белән әрнеп кайттым! Без, өлкәннәр, нишлибез, ни кыланабыз?! Укучыларны имтиханга тикшереп, капшап кертү нинди кысаларга сыйсын инде? Бер кыз паспортын онытып калдырган булып чыкты. Бала каушаудан, куркудан калтырый башлады. Әнисе паспортны китергәч тә тынычлана алмады. Ул арада министрлыктан тикшерүче килеп, нидер таптырырга керешге... Балаларның нинди хәлдә имтихан язарга утырачагында беркемнең эше юк – дошман эзлибез...

Үз казаныбызда гына кайнаудан туктарга вакыт!

Чит илдән килгән бер турист, тырышып-тырышып русча сораулар бирде бүген. Үзенә кирәкне барыбер алды, аңлады. Россиягә килер алдыннан гына «ипи-тозлык булса да белим» дип, рус телен өйрәнгәнгә охшаган. Ә мин инглиз телендә гап-гади сүзләрне дә белмим! Курсларга йөреп тә укып карадым – әллә ялкаулык көчле, әллә кирәклеген тапмыйм: башлыйм да тагын ташлыйм... Эш түгел бу! Әллә без алардан кимме? Булдырмыйбызмы?

PRESSA.RU

16+

БЕЗ ЧИБӘРЛЕККӘ ГАШЫЙК!



Айдар САДЫЙКОВ,
Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты,
«Миллениум» радиосы алып баручысы, ВИП-тамада.
өйләнгән;
Өч бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Теләсә кайсы ир-ат иң элек хатын-кызның буй-сынына игътибар итәдер дип уйлыйм: күкрәкләренә, аякларына... Оча тирәсе киң икән, димәк, ир-атка бу бер хәбәр – мондый хатын-кыз дөньяга сау-сәламәт бала китерәчәк. Дулкынланып торган озын чәчләргә шулай ук күз төшә: андыйлар һәрвакыт башкалардан аерылып тора. Толымнарын җилгә таратып та җибәрсәме?!.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Бөтен нәрсә өчен дә гафу итәргә була аны: машинаны бәрдергәнен дә, ашы тозлырак булганын да... Әмма нидер укыганда бүлдерсәләр яратмыйм мин.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәт! Якын кешесенең үзенә хыянәт итүен ишетүдән дә авыр хәбәр юктыр ир-атка. Бәхетем – мин моны кичермәдем.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм аңа өйдә комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Бу уңайдан минем үземә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән аның җәмәгате арасындагы мөнәсәбәтләрне күзәтү бик кызык. Әйе, ул – лидер. Сәкинә ханым күп вакыт аның күләгәсендә кала. Әмма рәсми булмаган чараларда Минтимер ага һәрвакыт иң элек сүзне хатынына тапшыра. Үз-үзен тотышы, күз карашы, хәрәкәтләре белән ул аны ни дәрәҗәдә хөрмәт иткәнен гел күрсәтеп, сиздереп тора.

Хатыны эшләргә, ниндидер уңышларга ирешергә омтыла икән, ире аңа, һичшиксез, ярдәм итәргә бурычлы. Мин үземнекен белемен күтәрергә Мәскәүгә дә җибәрдем, фоторәссамнар курсына да йөрттем. Машина йөртергә дә ул миннән алданрак өйрәнде.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Ничек дус кына булсын, ул бит – саклаучы фәрештәң! Хатыным – һәрнәрсәдә иң беренче киңәшчем. Аннан башка аватарка өчен фоторәсем дә сайламыйм.

Туйлар, юбилейлар күп үткәрәм бит, күрәм: башка ир-атлар да миннән әллә ни аерылмый. Зур-зур генераль директорлар, министрлар юбилейларын ничек уздыруны иң элек хатыннары белән киңәшләшә. Туйларда да шул ук хәл. Бәйрәмнең 90 процентын – кәләшләр, калганын кияүләр һәм әти-әниләр оештыра. Сорауларны гел кәләшләр яудыра. Кияү егете бу вакытта баш кагып кына утыра...

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– ...Мин аны инде иртүк эшкә озата бара идем. Ул күздән югалып биш минут үтүгә шалтырата башлыйм: тавышын ишетәсем килә. Кичке сәгать биштә мин кабат аны ишек төбендә каршы алам. Бар да булды безнең: чәчәкләр дә, конфетлар да, көнләшүләр дә... Ничекләр итеп көнләштем мин! Акылдан шашам дип торам!

Берсендә аны көтеп тукталышта ике сәгать басып тордым! Ул чакта туңуларым! Азрак җылыныйм дип, урам җыештыручыга әллә никадәр кар көрәштем. Соңыннан ачыкланды – эштән ул көнне иртәрәк кайтып киткән икән. Гашыйк булганда, яратканда организм допамин дигән матдә эшләп чыгара: андый чакта, яраткан кешесен күрмичә кеше тынычланмый, диләр. Минем белән дә шулай булды. Бәхеткә каршы, безнең хисләр уртак иде. Ә кайда таныштык дип уйлыйсыз? Әлбәттә, туйда инде! Ул кәләшнең дус кызы иде, ә мин, гадәттәгечә, алып баручы. Бер күрүдән дә гашыйк булырга мөмкин икән... Миңа ул чакта – 43, аңа – 20 яшь... Ул көннән соң дүрт ел узды инде менә. Улыбыз Арслан үсә. Мин тагын кызыбыз, аннан тагын бер улыбыз тууын телим. Калганын – киләчәк күрсәтер.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?

– Абый белән мине әни ялгыз үстерде. Әтисез калганда миңа җиде генә яшь иде. Шуңа күрә әни минем өчен кадерле дип кенә әйтү дә аз... Бәндә хаталардан хали түгел – аның кайбер нәрсәләрдә ялгышуын күрсәм, үзем хәтта тәнкыйтьләсәм дә, әнидән берәүгә дә ялгыш та кыек сүз әйттерәсем килми. Кайчак ир-атларга әниләренә берсүзсез буйсыну кыенлык та тудыра. Әни «тозагыннан» котылып, хатыным белән икебезгә генә кагылган сорауларны үзебез генә чишә башлау, яшермим, миңа да җиңел булмады.

Күптән түгел бер туйны алып бардым менә. Бер ай да үтмәде, яшь килен елап шалтырата: «Кайнанам улын гел миңа каршы котырта. Ирем – зомби кебек: көн саен әнисе янына бара, ул нәрсә куша, шуны гына эшли...» – ди. Сер түгел бит, әйе, әти-әниләр, бигрәк тә, әниләр, балаларын гел үз кубызларында гына биетергә тели. «Мин сине таптым... Үстердем... Бөтен тормышымны сиңа багышладым. Ә син?» – диләр. Әмма сиңа бит хатының белән көн итәсе – аны рәнҗетергә ирек куярга ярамый.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Беренче хатынымның миннән күбрәк акча эшләгән чаклары бар иде. Бик күпкә! Үртәлә идем... «Нигә болай? 25 яшьлек көче ташып торган ир-ат бит мин!» – дия идем. Аннан менә, бәхеткә каршы, иҗатка кереп киттем. Һәм барысы да үзгәрде!

9 Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Һәрнәрсәнең үз вакыты шул, бик озак сайлансаң, көтеп кенә утырсаң ялгыз калуың да бар. Кызлар беренче адымны үзләре дә ясый белергә тиеш. Минем үземә дә беренче хатыным мәхәббәтен башлап үзе аңлаткан иде. Горурлык булды ул минем өчен!

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Кыя кебек дивар артында ир-атның шактый нечкә күңеле яшеренүен күрсен иде алар. Саксыз кагылсаң, аны бик тиз яраларга мөмкин икәнен аңласыннар иде. Мактау сүзләрен кызганмасыннар иде. Хәтта ул хаклы булмаганда да, учакка май өстәмичә, ирнең тынычлануын көтсеннәр, аннары гына үз фикерләрен әйтсеннәр иде.

Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Чибәр кызлар белән танышудан беркайчан да курыкмадым. Якыннан аралашып китәбез икән – бик әйбәт, кире борсалар да, бернәрсә югалтмыйм... Шуңа күрә хатыным яшь тә, чибәр дә минем!

11 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар сезнеңчә бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Без аналитик акылга ия, фикер йөртүебез – колачлырак, ә хатын-кызда интуиция көчле, алар безнең уйга да кермәгән нәрсәләр хакында төпченергә сәләтле. Клиентлар арасында миллиардерлар, «Форбс» журналы әгъзалары да бар. Эшкуарлар, сәясәтчеләр, министрлар... Алар аш-су мәсьәләсендә дә шактый хәбәрдар, артистларны да таный. Шуңа күрә юбилейлар әзерләгәндә төп сүзне алар үзләре әйтә. Әмма түрдәге өстәлгә куелачак чәчәк бәйләменә заказны һәрвакыт хатыннары бирә!

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Тыныч юл белән хәл итеп булмаган проблема юк ул. Зур-зур дәүләтләрнең дә сәясәтчеләре уртак тел таба. Ә гаилә шул ук дәүләт инде ул... Мин – юл куя белә торган кеше. Әмма арага боз салкынлыгы керә, сине кеше буларак хөрмәт итми, күрми башлыйлар икән, юлларның аерылуы хәерлегә генәдер. Мондый вакытта дөньяга карашлар да, без үзебез дә үзгәрәбез. Һәм бу үзгәрешне никадәр тизрәк сизеп аласың, аңлыйсың, шулкадәр әйбәтрәк. Аннан инде бөтен ихтыяр көчеңне туплап: «Аерым яшәү синең өчен дә, минем өчен дә дөресрәк булыр», – дип әйтү кирәк...

Без, татар ирләре, күп вакыт үзебезне дөньяның кендеге дип саныйбыз шул. Без – хуҗа, шулай булгач, нишләсәк тә, үзебезне ничек тотсак та килешә, янәсе! Мәҗлестән соң, юбилейны оештыруда ярдәм иткәне өчен бер җитәкченең хатынына рәхмәт әйтә башлагач, ул мине шунда ук туктатты: «Хатын-кызны мактарга ярамый!»

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...


– Улыбызга ике яшь кенә әле. Бәләкәй бала белән каян әләксен ул диванда ятып торулар?! Тәгәрмәчкә эләккән тиен сыман мондый вакытта хатын-кыз... Ә инде ятып тора икән, димәк, чынлап та, бик арыган яки авырып киткән. «Роллар гына китертик», – дип мин аңа үзем үк тәкъдим итәчәкмен.

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Ялгыш фикер бу. Минем хатыным, мәсәлән, күпкә алданрак җыенып куя. Ә мин каһвә эчәм, интернеттан яңалыклар карыйм, тагын каһвә пешерәм, аннан кабат интернет... Минем үземне юлга, гомумән, кечкенә баланы җыендыргандай әзерләргә кирәк: ашау-эчүне кайгыртырга, күлмәгемне үтүкләргә...

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Иң ошаган бүләк? Еш кына мин үземә нинди бүләк кирәген алдан ук әйтеп куям. Гадәттә, сәнгать буенча берәр затлы китап була ул: яхшы кәгазьдә басылган, рәсемнәр белән бизәлгән, аз тираж белән чыккан... Антиквар әйберләрне дә бик яратам. Әмма иң яхшы бүләк – үз кулы белән эшләгәне: теккән, бәйләгән әйберләр. Ир-атка хатын-кызның иң зур бүләге исә – балалар! Минем алар өчәү!



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



СӨННӘТЧЕ БАБАИ КИЛӘ!..



Рәшит БАЙБИКОВ, Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре кандидаты, балалар хирургы, уролог-андролог.

Сөннәткә утырту тарихы

Сөннәткә утырту безгә ата-бабаларыбыздан калган йола. Соңгы елларда, дин иреге килгәч, халык аңа аерата зур әһәмият бирә башлады.

Сөннәткә утырту операциясе моннан 15 мең ел элек – палеолит дәверендә үк ясалган: таш кыяларда сакланган рәсемнәрдә ул ачык күренә. Борынгы Мисырдагы фиргавеннәр төрбәләрендә, папирусларда сакланган мәгълүматлар да бу процедураның безнең эрага кадәр ике мең ярым ел элек үк эшләнүе турында сөйли.

Сөннәткә утырту операциясе дин күзлегеннән, гигиена максатыннан чыгып һәм медицина таләпләре буенча дөньяның барлык почмакларында, илләрендә ясалган һәм ясала. Бүгенге көндә Американың 75 процент ир-аты, чисталыкны саклау максатыннан, үзләре теләп бу процедураны узган. Дөрес, төрле штатта төрле елларда саннар берберсеннән 20 проценттан алып 80 процентка кадәр аерыла.

1948 елга хәтле Британиядә бу операция туучы балаларның өчтән беренә ясалган. Хәзерге көнгә анда ирләрнең бары 9 проценты гына шушы максат белән хирург пычагы астына ята. Канадада бу саннар – 20 процент, Австралиядә исә 10 процент тирәсе. Үткән ел Германиядә стажировкада булып кайттым – анда да сөннәткә утырталар. Кайбер Европа илләрендә һәм Америкада бу операцияне онанизм, мастурбация белән көрәш алып бару өчен пропагандалыйлар.

Сөннәт нигә кирәк?

Ир балаларның, ир-атларның тышкы җенес әгъзаларының башын каплаучы тире – медицина теле белән әйткәндә «җенес органы каплавычы» (яки «сөннәтлек») дип атала. Сөннәтлек»тә бик күп сизгер рецепторлар, эррекция вакытында тартыла торган тире запасы, смегма барлыкка китерә торган бизләр бар.

Кайберәүләрдә – тумыштан, ә кайбер балаларда шул «кырый тире» еш ялкынсыну сәбәпле сидек юллары тараеп, кече йомышын үтәргә комачауларга мөмкин. Ул чагында балага игътибар итегез: көчәнеп, тукталыптукталып, өзеп-өзеп симиме? Кайвакыт сигән чагында «сөннәтлек» шар кебек кабарып тулырга мөмкин. Үсә башлагач, эррекция вакытында тире тартылып җенес органының башы ачылмаса, тагын проблемалар барлыкка килә. «Сөннәтлек»тә кисталар, сөялләр үсәргә дә мөмкин.

Сөннәткә утырту вакытында шул «җенес органы каплавычы» кисеп ташлана, кан агуы туктатыла һәм яра тегелә. Шул ук көнне бала өйгә кайта. Атна-ун көн эчендә яра төзәлә.

Ничә яшьтә сөннәткә утыртырга?

Корьәндә сөннәт турында да һәм ничә яшьтә сөннәткә утыртырга кирәге хакында да берни әйтелмәгән.

Бүгенге көндә ислам илләрендә бу операция балаларга төрлесендә төрле яшьтә ясала: Төркиядә – 8-13 яшьтә; Иранда – 3-4 яшьтә; шәһәрдә яшәүче гарәпләрдә – 5-6 яшьтә; авылда яшәүчеләрдә – 12-14 яшьтә.

План буенча, наркоз белән эшләнә торган операция буларак, без исә сөннәтне балаларга 3 яшь тулганда яки тулгач кына ясыйбыз. Кайбер гаиләләр иртәрәк тә ясатырга тырыша, әби-бабайлары ашыктыра, наркозсыз гына ясауны таләп итәләр. «Бала бит кечкенә чагында хәтерләми, авыртуны да сизми», – диләр. Ләкин дөньяга яңа гына килгән сабыйга нигә тагын шок ясарга? Авырта дип әле әйтә белмәсә дә, онытса да, балада ул тирән эз калдырырга, киләчәктә бу үзен сиздерергә мөмкин. Өй шартларында яки лицензиясе булмаган клиникаларда гына ясалган андый операцияләрдән соң кан китү, төрле катлауланулар белән балаларны еш кына Республика балалар клиник хастаханәсенең урология бүлегенә алып киләләр. Кайбер очракта «сөннәтлек» киселеп бетмәгән, ә кайбер чакта операция, гомумән, дөрес ясалмаган була – яңадан ясарга туры килә.

Биш-җиде минутлык операциянең наркозы куркыныч түгел. Заманча аппаратлар һәм наркоз бирү өчен елдан-ел җиңелрәк препаратлар кулланыла. Әмма иң мөһиме, әлбәттә, тәҗрибәле белгечләр.

Тагын балага сөннәтне аның яше так санга туры килгәндә, әйтик, 3, 5, 7 яшьтә ясатырга кирәк дип әйтү бар. Кайбер ата-аналар, вакыт җитте, безгә 3 яки 5 яшь тулды дип килә. Кайберләре балага 2 тулып 3 белән барганда яки 4 тулып 5 белән барганда да, диләр. Без – хирурглар өчен аерма юк: кем ничә яшендә ясатырга тели һәм моңа күңеле белән өлгереп җитә. Кырык яшендә генә мөрәҗәгать итүчеләр дә бар, 99 яшьтә генә өлгереп җитүчеләр дә.

Операция ел фасылына бәйлеме?

Элек әби-бабайларның: «Казлар йомырка басканда сөннәткә утыртырга ярамый», – дип әйтүләре хәтердә. Нигә болай әйтүләрен табиб буларак бүген аңлата алам. Язын, сөннәткә утырту кебек пластик операцияләрдән соң, тән ярасы келоидлы җөй белән төзәлергә мөмкин. Ләкин 23 ел эшләү дәверендә андый куркыныч килеп туган очракны белмим. Шуңа күрә ата-аналар кайчан мөрәҗәгать итсә дә, бу операцияне ел дәвамында ясыйбыз.

Ничек әзерләнергә?

Беренчедән, баланы белгеч – уролог-андролог карарга тиеш. Кайбер очракларда бу операцияне балага бөтенләй ясарга ярамый яки ул соңрак ясалырга тиеш. Чөнки балада тумыштан төрле тайпылышлар булырга мөмкин: мәсәлән, гипоспадия, эписпадия, яшерен җенес әгъзасы һәм башкалар. Кайбер балага бүтән операция планлаштырылган булса, икесен бергә ясаган очраклар да бар.

Сөннәткә утырту өчен нәкъ башка операцияләргә әзерләнгән кебек үк әзерләнергә, шундый ук анализлар тапшырырга кирәк.

Сөннәткә утыртыр алдыннан һәм операциядән соң ата-аналарга хирург барысын да аңлата, операциягә әнисеннән дә, әтисеннән дә рөхсәт алына.

Ә сөннәткә утыртмасаң?

Сөннәткә утыртмау нинди аяныч хәлләргә, авыруларга китерергә мөмкин соң? Алдарак әйтеп узганымча, сидек юллары тараюы, бөер һәм сидек юлларында барлыкка килгән инфекцияләрнең сәбәбе булырга мөмкин. Ачылмаган «сөннәтлек» эчендә барлыкка килгән смегмада бактерияләр җыела һәм үрчи: инфекциядән тыш, алар төрле онкология авырулары китереп чыгарырга да мөмкин. Сөннәтсез ирләрнең хатыннарында аналык муентыгында яман чир очраклары күбрәк. «Дерматология архивы» дигән журнал үткәргән тикшеренүләр күрсәткәнчә, сөннәткә утыртылган ирләр арасында венерик авырулар (сифилис, гонорея) өч тапкыр кимрәк, СПИД афәте алты тапкыр азрак очрый.

Әти-әниләргә киңәш

- Сөннәткә утырту – җенси тормышның сыйфатын һәм озынлыгын арттыру өчен иң яхшы ысул дип санала.
- Баланы сөннәткә утыртырга уйлагансыз икән, адым саен ачылган, кайвакыт хәтта лицензиясез дә эшләүче шәхси клиникаларга бармыйча, анализларга нигезләнеп эш итүче белгечләргә мөрәҗәгать итсәгез иде. Бабачылар заманы артта калды. Бик ярлы илләрдә генә бүген дә сөннәткә бабачылар, хәтта чәчтарашлар утырта. Фарсы култыгындагы илләрдә әнә бу мөһим процедураны бары тик профессиональ хирургларга гына ышанып тапшыралар һәм стационар шартларда гына ясаталар.
- Бу операция нинди максат, нинди таләпләр белән ясалса да, әлеге көн бала өчен дә, гаилә өчен дә истәлекле бәйрәм булып калсын иде.

PRESSA.RU



Әйдәгез, бераз үзебезне дә кайгыртыйк әле. Күптәнге танышыбыз Зөлфия СӘЛИМҖАНОВА безгә җәй өчен бик матур муенса үрергә тәкъдим итә. Чын ташлардан, беркемдә дә булмаганны! Җәйге күлмәкләр белән бик килешәчәк ул. Зөлфия үзе аларның төрледән-төрлеләрен үрә. Күргәзмәләрдә хатын-кызларның иң яратып алган әйберсе икән бу муенса. «Сөембикә» укучыларын үз итеп, муенса үрү серен ул безнең белән уртаклашырга булды. Рәсемдәге мастер-класста беләзек үрү үрнәгә күрсәтелгән. Муенса да нәкъ шулай ук үрелә, аермасы – озынлыкта гына.



Мастер-классны Зөлфия СӘЛИМҖАНОВА үткәрә.

ҖӘЙГӘ НӘФИС МУЕНСА

Кирәк

- 1 уч авантюрин ташы (яшел төстә ул);
- 1 уч аметист (ачык шәмәхә төстә);
- ташлар төсенә ярашлы сәйләннәр. Бу очракта кытай сәйләне бик яхшы. Аның эреле-ваклы булуы уңайлы;
- каптырма ясау өчен фурнитура (ике катлы боҗра, лобстер, штифтлар, каплавычлар (колпачки дип йөртәләр), пин, кыска чылбыр);
- 3 дәнә түгәрәк авантюрин ташы, диаметры 8 мм;
- 2 нче санлы ыргак;
- сәйлән энәсе;
- 0,2 мм калынлыктагы үтәкүренмәле кыл (2-3 м чамасы кирәк булыр);
- түгәрәк башлы каргаборыны (круглогубцы).





Эш барышы:

■ сәйләннәрне, ташларны бергә катнаштырып, бер савытка салабыз. Сәйлән энәсенә кыл саплап, башта төрле төстәге 6-7 сәйлән, аннары берәр таш эләктерәбез. Янә сәйләннәр, аннары таш – шул рәвешле 1 м чамасы булганчы (муенса өчен 2,5-3 м) сәйләннәр белән ташларны аралаштырып, кылга тезеп чыгабыз. Ниндидер бер эзлеклелек сакларга кирәкми.

■ Сәйләннәрне кирәк кадәр җыеп бетергәч, кылны өзмичә генә, шушы сәйләнле кылдан ыргак белән чылбыр үрүгә күчәбез. Ул буш күзләр (воздушная петля) белән үрелә. Һәрбер күзгә 1 яки 2 сәйлән кертеп



калдырыла. 2 сәйлән белән матур-рак: бер сәйләнне күзнең уң ягына, бер сәйләнне күзнең сул ягына авыштырасың. Мөһим әйбер: чылбырны буш итеп үрергә, күзләрне тарттырмаска кирәк.

■ Беләзекнең озынлыгы беләзек сөягә әйләнәсенә тигез. Хәтта 1 см чамасы җитми калса да ярый, югыйсә кулдан төшеп китә торган булыр.

■ Йомшак өслеккә 2 энә кадап куябыз. Аларның арасы беләзекнең озынлыгы кадәр. Чылбырның бер очын бер генә җебеннән энәләрнең берсенә эләктерәбез, икенче энәгә беләзекнең икенче очы эләктерелә. Чылбырны беләзек озынлыгы кадәр генә калганчы – 5-6 кат җыябыз.

■ Энәгә эләктерелгән күзләрнең һәрберсен озын штифтка күчерәбез. Икенче энәдәге күзләр икенче штифтка күчерелә. Түгәрәк каргаборыны белән штифтның бер башын бөгеп, боҗра ясыйбыз. Икенче башын бөгәргә керешкәнче, штифтка башта каплавыч, аннары бер түгәрәк авантюрин кидереп калдырабыз. Каргаборыны белән штифтның ул башын да боҗралап бөгеп куябыз, артык калган өлешен өзеп алабыз. Беләзекнең икенче очы да нәкъ шулай ясала.

■ Беләзек әзер дип әйтерлек. Аның бер очына – ике катлы боҗра һәм лобстер, икенче очына ике катлы боҗра кидерәбез. Беләзекнең озынлыгын көйләргә мөмкин булсын өчен, әлеге боҗрага кыска чылбыр эләбез. Чылбыр очын да авантюрин белән бизибез. Ул чылбырга пин – бер башы йомры булган кыска кадак – ярдәмендә беркетелә. Ташны пинга кидереп, буш калган очын карга борыны белән боҗралыйбыз. Шушы боҗра ярдәмендә авантюринны чылбырга эләктерәбез.

Ташлар сихәте

■ Авантюрин – эчендә көмешсу ком бөртекләре җемелдәшкән сары, яшел, күрән төстәге таш. Кәефне күтәрү, күңелне алгысыту, зиһенне ачу куәтенә ия. Хуҗасын бозымнан саклый. Яшел авантюрин кешенең аурасын чистарта, хисләрне тынычландыра.

■ Аквамарин – яшькелт-зәңгәр төстәге үтәкүренмәле таш. Гаилә бәхете сагында торучы булып санала. Суда чакта бәла-казалардан саклый. Хәвеф-хәтәр буласын алдан сизә – төсе үзгәрә.

■ Аметист – шәмәхә төстәге кварц. Императорлар ташы диләр аны. Хуҗасына уңыш, байлык китерә. Күз күремен, ашказаны эшчәнлеген яхшырту үзлегенә ия. Яңа мәгълүматны истә калдырырга ярдәм итә.

■ Ай ташы – гашыйклар ташы. Гаиләдәге тугрылыкны, өлфәт мәхәббәтне саклый. Хуҗасына «тел ачкычы» бирә – әйтәсе килгән фикерне башкаларга җиңел аңлатырга булыша.

■ Гагат – кара төстәге яшма. Озакка саубуллашасы кешегә бүләк итәләр. Күңел төшенкелеген бетерә, күз тиюдән саклый. Баш сызлавын басу үзлеге билгеле. Күңелдәге үпкә, рәнҗүләрне куа.

■ Гәрәбә – күңел сизгерлеген арттыра, бик күп авырулардан шифасы бар. Гәрәбә тагып йөргән хатын-кыз тиз картаймый, күңеле тыныч, шат була. Өйдә дә гәрәбәдән ясалган берәр әйбер тотарга кирәк – ул ут хәвефеннән, караклардан саклый.

■ Гематит – бик көчле талисман дип санала. Аны элек солдатларга такканнар. Куркуны җиңә, тәвәккәллек өсти. Канны чистарту, гемоглобинны күтәрү, сөяк җелеген яхшырту, кан басымын көйләү кебек сихәте бар.

■ Гранат – гашыйклар талисманы, дуслык ташы. Хуҗасына күңел көрлеге, шатлык хисе бирә. Организмдагы ялкынсынуларны җиңәргә ярдәм итә, салкын тигәннән шифасы бар.



Тулысынча сайтыбызда «Белмәсәң – бел» сәхифәсендә укыгыз.

PRESSA.RU

– Кунакка килгән дус-ишне нәрсә белән сыйларга, диючеләргә миндә шәп тәкъдим бар! – дип куандырды безне үзе җырчы да, үзе телевидениедә тапшырулар алып баручы да, үзе бәйрәмкичәләр оештыручы да Зөлфәт ЗИННУРОВ, мастер-класс әзерләү хакында сүз чыккач. – Шашлыкны бөтен кеше кыздыра, әйдәгез, парлама пешерик! Мәктәптән үк «Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясендә эшләгән Зөлфәт Зиннуровның беренче пешергән ризыгы торт булган икән. Тугызынчы сыйныфта укыганда бер дусты белән 8 Мартка торт пешереп, кызларны сыйлаган алар. «Ир-ат пешергән ризык нигә тәмле була?» – ди Зөлфәт. Төрле фикерләр әйтеп карыйбыз. Аның исә үз версиясе: «Пешергәндә ир-ат шушы ризык хакында гына уйлый, ә хатын-кызның башында меӊ төрле уй. Шуңа күрә безнеке тәмлерәк чыга». Хак әйтә, күрәсеӊ, парламасы бик тәмле иде. Сез дә пешереп карагыз әле.



ДУСЛАРГА – ПАРЛАМА!



Кирәк:

- 700 г чамасы ит. Без сөякле сарык ите, казның баш-аягын, бүтәкәсен кулландык.
- 7-8 бәрәңге;
- 2-3 баш суган (суган күбрәк булган саен яхшы);
- 1 кишер;
- 1-2 помидор;
- 1 баллы борыч;
- 4-5 тырнак сарымсак;
- аз гына лимон суты (мәҗбүри түгел);
- тәменчә тоз-борыч.



■ Парламаны учакта пешерү өчен махсус торбасы кирәк булачак. Сатуда күренми, алтын куллы ир-ат ясап бирсә генә. Озынлыгы 50-60 см, диаметры 25-30 см булган калынрак торба кисәгеннән гыйбарәт ул. Эчке ягында урта сызык буйлап ике якка тимер «угольник» ябыштырылган. Таба шуларга шудырып кертелә. Таба дигәч тә, анысы да түгәрәк таба түгел. Парлама торбасына сыешлы итеп калайдан ясалган махсус таба. Торбаның бер башы бөтенләй томаланган, икенче башында уртада тар гына капкач ясалган. Торба эченә 4-5 л су салына. Учак өстендәге аркылы тимергә элеп кую өчен элмәкләре бар. Ә инде рецептны бүген үк сынап карарга теләүчеләр әлегә аны целлофан «җиңгә» тыгып, духовкада пешереп карасыннар.



Эш барышы:

■ Итне юып, эрерәк кисәкләргә турыйбыз да, таба төбенә тезеп чыгабыз. Аннары ит өстенә тәгәрмәчләп туралган бәрәңге тезәбез. Бәрәңге өстенә суган бөҗралары салабыз.

■ Эререк итеп туралган помидор белән борычны да табага «озатабыз». Инде чират кишергә – анысын ярымтәгәрмәчләп турыйбыз. Сарымсакны исә башта тактага салып пычак яны белән изәбез. Шулай итсәң, кабыгын әрчү җайлы аның. Аннары инде урталай гына ярып, башкалар янына кушабыз. Түбәнчә тоз-борыч сибәбез.

■ Лимонны урталай ярып, бер яртысының сутын бәрәңге өстенә сыгабыз. Теләгән кеше башка төрле тәмләткечләр дә куша ала. Ләкин Зөлфәт үзе аларны кирәксенми. «Болай тәмле була ул», – ди.

■ Инде бакчага чыгып, учак ягып җибәрик. Безгә аның күмере төшкәнен көтәсе юк. Торба эченә 4-5 л су салырга да онытмыйбыз. Бу ризык парда пешә, шуңа күрә аңа май да салынмый. Исеме дә юкка гына парлама түгел! Табаны тыгып, капкачын ябабыз да, торбаны учак өстенә элеп куябыз. Эчендәге су кайнап чыкканчы, ялкыны куәтле кирәк, аннары инде утыннарны кырыйгарак күчереп, талгын гына утта пешереп бетерәбез. Парлама 2 сәгать пешә. Аңынчы башка эшләрегезне карарга да өлгерәсез әле.

Ашларыгыз тәмле,
җәйләрегез ямьле булсын!

Бәйге



Журналыбызның март санында «Салават күпере» журналы белән берлектә «Әниләр һәм нәниләр» гаилә рецептлары бәйгесе игълан иткән идек. «Сөембикә» журналының syuyumbike.ru сайтында онлайн тавыш биру нәтиҗәсендә ачыкланган җиңүчеләребез түбәндәгеләр:

■ 1 нче урын – Ясминә Галләмова, әнисе Регина белән (Азнакай);

■ 2 нче урын – Әдилә Хәнәфиева, әнисе Рузия белән (Кукмара);

■ 3 нче урын – Илсөяр Зиннурова, әнисе Рәсимә белән (Яшел Үзән).

Җиңүчеләрне Казанга бүләкләү тантанасына чакырып, «Салават күпере» һәм «Сөембикә» журналларының истәлекле дипломнарын, бүләкләребезне тапшырдык.

PRESSA.RU

КӨРӘШҮ БАШЛАНА



Июнь ае – бакчада чүп үләннәре һәм корткычлар белән көрәш ае. Үземнекен үстереп ашыйм дигән кешегә бакчада ял юк аңа. Май аенда утырткан үсемлекләребез, хәзер тамыр бикләп, кояшка үрелә. Чүп үләннәре дә алардан калышмый. Чүп үләннәрен утап та котылырсың, корткыч бөҗәкләр белән көрәш кискенрәк: йә син – аларны, йә алар – син утырткан яшелчәне.

Суган кыяклары баш төртергә дә өлгермәде, суган чебене кара эшен инде башлап та җибәрде. Суган уңышыннан колак какмыйк дисәк, тиз арада чарасын күрик:

- 10 л суда бер стакан тоз эретеп, суган өстеннән бөркибез. Тозлы суның туфракка зарары да юк түгел, шуңа күрә тозны чамалап кулланырга тырышыгыз (бу чара помидорлардагы фитофторадан да үтемле);
- бер чиләк суга 200 г тузганак тамырын турап салабыз да, бер атна төнәтәбез. Аннары сөзеп, һәр 14 көн саен түтәлләргә сибәбез (бу чараны киләсе ел өчен саклап куегыз, быелга инде өлгермәбез, мөгаен);
- куе төстәге марганцовка эремәсе дә сибәргә була. Аны һәр ун көн саен сибәләр. Ул суган чебенен дә, кишер чебенен дә куа;
- бер стакан көл, берәр чәй кашыгы тәмәке тузаны белән төелгән кара борычны бергә кушып, суган араларына сибеп чыгабыз;
- 200 г тәмәке тузанына 3 л кайнар су агызып, ике тәүлек төнәткәннән соң, 1 чәй кашыгы зәһәр борыч, 1 аш кашыгы сыек сабын өстибез дә, яхшылап болгатып, суган өстенә бөркибез;

Чебеннең әле суганны гына түгел, кишерне зарарлый торганы да бар. Аның зарарын киметү өчен берничә кагыйдә:

- кишер белән суганны янәшә утырту;
- кишерне сирәк утырту, рәт араларын киң калдыру;
- сирәкләү эшен кич башкару – сирәкләгән вакытта кишернең исе таралып, чебеннәрне җәлеп итә;
- кишер чебене торф исен яратмый – түтәлне торф белән мүлчәлибез. Рәт арасына тәмәке тузаны яки коры горчица сибеп чыгарга да була;
- кишер түтәлләренә чыршы яки нарат ылысы түшәүчеләр дә бар;
- чебен кортын юк итү өчен помидор сабакларыннан агулы төнәтмә ясарга мөмкин. Моның өчен: 1 кг кипкән сабакларны 10 л суга салып, 4-5 сәгать төнәтәбез, аннары 2-3 сәгать талгын утта кайнатабыз. Кишергә сипкәндә, ярты чиләк төнәтмәне 1 чиләк суда сыеклап, 50 г кер сабыны кушабыз.

Кәбестә кортыннан:

1 кг зәһәр борычны 10 л суга салып, 1 сәгать кайнатырга, сөзеп, салкын урында сакларга. Бер ел буе саклана ала. Кәбестәләргә сибү өчен 1 л төнәтмәне 10 л суда сыеклап, 40 г уылган кер сабыны салырга. Әйбәтләп болгатып, үсемлекләр өстеннән бөркергә.

Фитофторага каршы:

- атна саен помидорлар өстенә агач көле бөркергә мөмкин. Бу – ашлама да, дәва да;
- 10 л суда 2 аш кашыгы бакыр купоросы эретеп, помидорлар чәчәк аткан чорда сибәләр;
- 10 л суга 1 л майсыз сөт (сепаратор сөте) һәм 15 тамчы йод салып, помидорларга ике атна саен сибеп торырга;
- 1 л суга 1 л әче су (кем сары су ди, ә кем – катык суы) кушып та сибәргә була. Моны көн саен башкаралар;
- авыру билгеләре күренә башлаганда 10 л суга 100 г чүпрә туглап сибәләр.

Яшелчәгә – кычыткан «ашы»

«Усал» дип даны таралган кычыткannан калийлы-фосфорлы ашлама ясыйк. Моның өчен полиэтилен чиләккә дыңгычлап кычыткан тутырабыз да, өстеннән су коябыз. Капкач белән каплап, ике атна кояшлы җирдә әчетәбез. Яман исен бетерү өчен валерьяна төнәтмәсе яки бер уч юл тузаны кушарга була. Түтәлләргә сипкәндә 1 л әчеткене 10 л суга кушып сыеклыйбыз. Фасоль, борчак, суганнан тыш, барлык яшелчәләр өчен дә файдалы бу ашлама.


Кучкар. Вакыйгалар бик тиз алмашына. Тормыштагы үзгәрешләрне җиңелрәк кичерер өчен гаиләдәге мөнәсәбәтләрне ныгытыгыз. Ялкауланмасагыз, яңа мөмкинлекләрдән файдалана белсәгез, уңыш казану өчен яхшы нигез булдырырсыз.



Үгезбозау. Гадәти генә эшләргә дә галәмәт зур көч түгәргә туры килер. Шуңа күрә бу айда катлаулы эшләргә алынмый торсагыз хәерле. Мәсьәләләрне минутында хәл итәргә омтылуыгыз, хәлне катлауландырачак кына.



Игезәкләр. Күңелле яңалыклар көтелә. Үзегезне күрсәтү, уңышка ирешү өчен менә дигән вакыт. Экспериментлардан һәм яңа идеяләрегезне тормышка ашыра башлаудан курыкмагыз. Яңа эшкә күчү форсаты килеп чыгар.


Кысла. Хыялларыгыз чынга аша торган ай, ләкин бер шарты бар: чынга ашардайлары хакында гына хыялланыгыз. Эшегездә зур үзгәрешләр юк, бар да үз көенә бара. Әллә кайчаннан бирле төгәлли алмый торган мөһим эшкә нокта куярсыз.


Арыслан. Күңел бушлыгы тоярсыз. Кирәкмәгән артык йөктән арыну теләге туар. Плутон планетасының тәэсире бу. Фатирда гына түгел, уйларда да тәртип урнаштыру өчен яхшы вакыт. Хезмәттәшләрегезнең көнләшүен сизәрсез.


Сөмбелә. Рухи күтәренкелек ае. Бик күп яңалык ишетерсез, тормыштагы күп нәрсәләргә карата фикерегез үзгәрер. Яңа мөнәсәбәтләр кору, ярдәм сорау, юридик мәсьәләләрне хәл итү өчен бик кулай чор, файдаланып калыгыз.


Бизмән. Көч-куәтегез барысына да җитәрлек. Яңа эшләр башлау, якын көннәргә планнар кору өчен әйбәт вакыт. Кайчандыр аңламаган нәрсәләрнең асылына төшенерсез, күңел күзегез ачылыр.


Чаян. Шәп ай. Күңелегез бөтен, гаиләгездә татулык, рәхәтлек. Күптәннән күрешмәгән танышларыгыз белән очрашырсыз. Моңа кадәр ачылмаган сәләтегез ачылыр. Иҗат эше белән шөгыльләнүчеләргә уңыш елмаячак.


Укчы. Мәшәкатьле вакыт. Тоткан юнәлешегезнең дөреслегенә шикләнерсез, фикер каршылыклары туар. Үзегезне кулда тотар өчен күп көч сарыф итәрсез. Бернинди яңа эш башламагыз, айны сабыр гына уздырып җибәрергә тырышыгыз.


Кәҗәмөгез. Барлык мәсьәләләр дә җиңел хәл ителә торган ай. Теләсә нинди катлаулы эшне дә ерып чыга алачаксыз. Башланып та, төгәлләнмәгән эшләр «калкып» чыгар. Көтелмәгән җирдән керем алу ихтималы бар.


Сукояр. Моңарчы ни теләгәннәрен белеп гомер иткән Сукоярларны икеле-микеле уйлар бимазалар – Плутон тәэсире. Көчегезне нindидер бер яңа шөгыльгә юнәлтегез – уңышка ирешеп, өстәмә керем булдырырсыз.


Балык. Ару-талчыгу үзен сиздерәчәк. Ял итү мөмкинлеген ычкындыра күрмәгез, сезгә бик тә кирәк ул хәзер. Бернинди дә яңа эшкә алынмагыз. Шәп тәкъдимнәрегез булса да, әлегә аларны белгертми торуыгыз хәерле.

Чит илләр, Россия, Татарстан. ИЮНЬдә кабынган йолдызлар


Галия Булатова (24.06.1906–13.09.1985) – **Татарстанның һәм Россиянең халык артисты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены иясе.**

Әлки районы Әлки авылында туып-үсә. 1926 елда Татар театр техникумын тәмамлап, берара төрле театрларда эшли. 1965 елга кадәр – Татар академия театры сәхнәсендә. Тамашачының мәхәббәтен казанган атаклы артистларыбызның берсе. Халык хәтерендә бик чибәр, зифа буйлы, зыялы кеше булып саклана. Иҗат итү дәверендә башкарган рольләре бихисап. Иң уңышлылары дип саналганнары арасында – Шәмсекамәр (М. Әблиев, «Шәмсекамәр»), Зифа (Н. Исәнбәт, «Зифа»), Миңлекамал (М. Әмир, «Миңлекамал») рольләре дә бар. Казанда Николаев урамындагы ул яшәгән 5 нче йортка мемориаль такта элengән.


Алена Яковлева (2.06.1961) – **Россиянең халык артисты.**

Чын исеме – Елена. Мәскәүдә туа. Тамашачыларга «Ирония судьбы» фильмындагы Ипполит роле аша яхшы таныш Юрий Яковлевның кызы. Мәскәү университетының журналистика факультетын һәм Щукин исемендәге Театр училищесын тәмамлый. 1985 елда Сатира театрына эшкә урнаша. «Интердевочка» фильмы чыкканнан соң, аны бу фильмда төп рольне уйнаган Елена Яковлева белән бутый башлыйлар. Ахырда исемен алыштыра. Киноэкраннарга беренче тапкыр режиссер Геннадий Воронинның «Два берега» фильмы белән чыга. «Возвращение мушкетёров», «Всё включено», «Мальчик и девочка», «Русский перевод», «Адвокат» кебек фильмнарда уйный.


Мэрилин Монро (1.06.1926–5.08.1962) – **актриса, җырчы.**

Лос Анджелес шәһәрендә туа. Чын исеме Норма. Монро – әнисенең кыз фамилиясе. Әтисенең кем булуы билгесез. Акчага һәм сәламәтлеккә туймаган әнисе аны ике атналык чагында ук чит гаиләгә асрамага бирә. Соңрак кыз ятимнәр йортына эләгә. 16 яшендә Джеймс Доггертига кияүгә чыгып, авиация заводында эшли. Чибәр кызны фотографлар монда да күреп ала: матбугатта фотолары басыла башлый. 1946 елда «Двадцатый век Фокс» киностудиясе аның белән килешү төзи. 1948 елда Мэрилин Монро катнашында «Хористлар» фильмы дөнья күрә. Бу аның беренче уйнаган фильмы була, ә инде 1954 елда ул «Иң популяр актриса» исемлегенә керә.

PRESSA.RU





РӘСЕМНӘРДӘН – ШИГЫРЬ

Елена Васильева рәссам белемен Мәскәү педагогика университетының сәнгать графикасы факультетында ала. Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы. 1997 елдан Чаллыда яшәп иҗат итә.

Рәссам-график Васильева, беренче чиратта, китаплар бизәүче профессионал. Ул шрифтларны сайлый, китапны үзенчә күреп бизи. Мондый белгеч күнекмәләре өчен классик таләпләр билгеле инде – гравюралар һәм литографияләр иҗат итү, рәсем ясау, коллаж техникасы белән эш итә белү.

Иҗади эшчәнлеге чорында Елена Викторовна, районның яшьләр эшләре белгече буларак, туган шәһәре Минзәләдәге сәнгать мәктәбендә рәссамнар бүлеген оештырып җибәрә. Хәзер дә талантлы яшьләр өчен старт мәйданчыгы булып торган «Артсалон-21» аның методикасы буенча эшләвен дәвам итә. Ә үзе шактый вакыт «Стержень» китаплар нәшер итү йортында бизәүче рәссам булып эшли.

Образ, форма, фактураны Елена Васильева үзенчә, үз алымнары белән бирә. Алар чәчмә әсәрләрдә һәм шигърияттә чагылган хис-тойгыларны тулыландыра, тагын да көчәйтә. Бер генә китап та башкаларына һич охшамаган, һәркайсының үз хисси образы – аерым бер халәтне чагылдырган үзенчәлекле характеры бар. Рәссамнар арасында бизәүче рәссамнар аерым бер урын тота. Әсәрне үз кичерешләре аша үткәреп, үз карашлары яссылыгында бизи алар.

Атаклы Микеланджело Буанароттидан ничек иҗат итүе белән кызыксынгач: «Мин мәрмәр кисәге алып, артык җирләрен кыеп ташлыйм», – дигән. Елена эшләрендә дә бер генә артык әйбер дә юк. Болай чагыштырып, арттырып та җибәрәбездер, бәлки. Ләкин Елена Васильева иҗатындагы колачлылык, тәэсир көченә ия декоратив композицияләр аша аның стиленә хас төсмерләр күзаллана. Графика рәсем сәнгатенә нигезләнгән, әмма ул үз эченә рәсем, гравюра, литография тармакларын да ала. Графика сынлы сәнгатьнең башка төрләреннән җыйнаклыгы, шартлылыгы, сурәтләү чараларын сак куллануы белән аерылып тора. Графика сәнгатен шигърияткә тиңлиләр. Җәмгыятьтәге актуаль вакыйгаларга тиз арада үз мөнәсәбәтеңне белдерү хас бу жанрга.

Елена Васильеваның сизгер калып белән бер тында ясалган эшләрендәге геройларны әйләндереп алган тиңәлек декоратив элементлар, чәчәкләр орнаментурасы белән тулылана.

Рәссам, әйтерсең, Византия чыганакларыннан илһам җыйган. Хәтта Венеция сынлы сәнгате дә озак еллар Византия икона язуларын кабатлаган ич! Елена Викторовна – чын мәгънәсендә рәссам. Графикада гына түгел, рәсем сәнгатенең һәр өлкәсендә үзен сынап карый ул. Киндергә майлы буяулар белән картиналар яза. Интерьер дизайны белән мавыга.

Аның ирекле стильдә язылган картиналары рәссам-графикның җыйнак-тыенкы эшләреннән берникадәр аерыла. Тамашачыга алар хәл-халәтне генә түгел, картинага салынган холыкны да җиткерә.


1998 елдан Елена Васильева бик күп шәхси, төбәкара, халыкара күргәзмәләрдә һәм конкурсларда катнашып килә.

Аның графикасы шигырь кебек: нәзберек, үтемле, хисле, кабатланмас.

Рәмзия КАШАПОВА









ЕЛЕНА ВАСИЛЬЕВА

PRESSA.RU

ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002



ЯРТЫЕЛЛЫККА ЯЗЫЛЫРГА ӨЛГЕРМИ КАЛУЧЫЛАР КИЛӘСЕ АЙНЫҢ 15 НӘ КАДӘР ЯЗЫЛЫП, ЖУРНАЛНЫ КИЛӘСЕ АЙДАН АЛДЫРА АЛА!

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә языларга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (www.syuyumbike.ru).

16+